«Юлдаш» газетасы китапханәсе

МӘКТӘП УКУЧЫСЫНА ЯРДӘМЛЕК

РИФӘ РАХМАН

# ҺӘР СЫЙНЫФТА — СОЧИНЕНИЕ



5-11

КАЗАН
«РАННУР» НӘШРИЯТЫ
2003

УДК 821.512.145
ББК 83.3 (2) я7
Р 28

«Юлдаш» газетасының баш мөхәррире
***Ранис Рәхимҗан улы Газизов* редакциясендә**

Рифа Рахман
СОЧИНЕНИЕ ДЛЯ КАЖДОГО КЛАССА
*(на татарском языке)*

Редакторы ***Ранис Газизов***
Техник редакторы ***Нурания Газизова***
Бизәлеш редакторы ***Фирая Газизова***
Версткалаучы ***Булат Гарфиев***
Җыючы ***Сәвия Фәйзрахманова***
Корректорлары ***Кадрия Маликова***
***Гүзәлия Шакирҗанова***

**Рахман Р.**
Р 28 Һәр сыйныфта — сочинение. — Казан: «Раннур» нәшр. 2003. — 176 б.
ISBN 5-900049-10-8

Җыярга тапшырылды 20.08.02. Басарга кул куелды 22.11.02.
Форматы 84х108. Офсет басма өчен газета кәгазе 48,8 гр.
«Школьная» гарнитурасы. Офсет басмада. Нәшер-хисап табагы 5,5.
Заказ С 51. Тиражы 20 000 данә.

«Раннур» нәшрияты. 420066. Казан, а/я 365. Тел.: 43-70-91.
Нәшрият эшчәнлегенә лицензия № 191 (19.06.97).

ДУП «Полиграфия-нәшрият комбинаты»нда басылды.
420503, Казан шәһәре, Бауман ур., 19.

**ISBN 5-900049-10-8**
**© «Раннур» нәшрияты, 2003**

## АВТОРДАН

*Бу китап ата-аналарның, укучыларның, мөгаллимнәрнең үтенечләрен тыңлап язылды. Аннан файдаланучылар язма эшләрне сүзгә-сүз күчермәсләр, нәкъ алардагыча фикер йөртмәсләр, хезмәтне бары тик гап-гади үрнәкләр җыелмасы итеп кенә санарлар дигән өметтә калабыз.*

*Кайбер язма эшләрдә әдәбият буенча дәреслек авторларыныкына туры килмәгән карашлар уздырылды. Бу исә башкача да уйлап булганлыкны күрсәтү өчен кирәк иде. Кайвакыт мин үз-үзем белән килешмичә, эчемнән генә бәхәсләшеп тә эшләдем. Хөрмәтле укучым, онытма: һәр хезмәт, беренче чиратта, үзенчәлекле булуына карап бәяләнә.*

*Без сочинениеләрдә галимнәр күреп яисә әйтеп бетермәгән фикерләр барлыгына сөенәбез, чөнки кулланма гамәлдәге дәреслекләрне тулыландыру, баету эшен дә башкарачак.*

*Матбугатта кайвакыт мәктәп укучылары өчен үрнәк эшләр басыла. Аларда еш кына темага кагылышсыз урыннарның, стиль хаталарының күплеге, ә инде иншаларның озынлыгы күзәтелә. Автор бөтен белгәнен, эзлеклеме, кирәкме-юкмы, менә мин булдырам дигәндәй, бер эшкә тутырып калдырырга тырыша. Әлеге сочинениеләрнең кайберләрен каләм белән күчереп язсаң, берничә дәфтәр кирәк булыр иде.*

*Югары уку йортларына имтихан тапшыручыларга да нибарысы өч куш бит кәгазь бирелә, шуннан да арттырмаска тырышуларын сорыйлар. Кемдер шуның өч кенә битен файдалана. Берәүнең ул да кулыннан килми... Бер үк фикерне әле болай, әле тегеләй әйләндерә... Озынлыктамыни хикмәт?! Фикер йөртә белүеңне күрсәт син!*

*Хәтта чыгарылыш сыйныф укучыларының да бик сирәкләре генә тирән фәнни эчтәлеккә ия зур күләмле*

иншалар яза ала. «Артык акыллы» хезмәтләрдә исә гыйльми әдәбият белән яхшы таныш кеше еш кына кайбер җөмләләрнең башкалардан (кайвакыт хәтта сүзгә-сүз!) алынганлыгын күрә һәм үзен алдангандай сизә.

Чыгарылыш имтиханнарын фәнне йомшак үзләштерүче дә, уртача укучы да, белеме белән иптәшләреннән нык аерылып торганнар да тапшыра, шунлыктан темалар да төрле катлаулылыкта тәкъдим ителә. Сочинение китапларын әзерләгәндә, без моны онытып җибәрәбез. Кайвакыт укытучылар да һәр укучыдан бердәй эш таләп итә, шунлыктан аны ата-ана да, күрше апа да языша. Мәктәптә сочинениеләренә гел «5» алып килгәннәр дә, укырга кергәндә, көтелмәгән авырлык алдында торгандай, югалып калалар. Күчереп булмый, сорарга укытучы юк, язышырга апа-абый янда түгел, чыганаклар карарга да рөхсәт ителми...

Укучы өч җөмлә теркәсә-теркәсен, әмма ул аның үзенеке, һич югы укыган хезмәтләреннән истә калдырган юллардан файдаланган эш булсын иде. IX-XI сыйныфта белем бирүчеләр мәктәптә, бала алдына китаплар тезмичә генә, инша яздырырга вакыт тапсыннар иде.

Безгә, тормыш тәҗрибәсе туплаганнарга, кечкенәләрчә фикер йөртү шактый кыен, шуңа күрә түбән сыйныфларга аталган бүлеккә, балаларга якын булсын дип, кызым Таңгөл эшләрен урнаштырдык, кайбер сочинениеләрдә ул язганнардан аерым өзекләр, җөмләләр китердек.

Бигрәк тә беренче бүлеккә төрле мәктәп укытучылары яздырган сочинение темалары сайланды һәм дәреслектәге биремнәр дә искә алынды. Алар сезгә балаларның бик кызык уйлау үзенчәлеген күрсәтер. Зинһар, укучыларны кече яшьтән үк үзегезчә генә сөйләргә, катгый план буенча гына язарга мәҗбүр итмәгез. Күңелендәгесен ачып салырга курыкмаган, көлкесен дә, кайгылысын да, олылар яшергәнне дә яза алган баладан гына зур шәхес, иҗат кешесе чыга.

Алда әйтелгән фикерне тагын бер кат ассызыклыйсы, киңәйтәсе килә: бигрәк тә бишенче, алтынчы сыйныфларда һәм хәтта әле җиденче сыйныфта да тирән эчтәлекле, күләмле сочинениеләр язу зур күпчелек өчен бик авыр. Язма эшләрдә аларның аерым бер образга бәя бирүләре, әсәр укудан туган тәэсирләре белән уртаклаша алулары да җиткән дип саныйм мин. Китерелгән хезмәтләр исә матур язу осталыгына һәм мөстәкыйль фикер йөртү сәләтенә ия балаларга хас биеклектә дип уйлыйм. Ул эшләр башкаларга, укытучыларга иҗат итү юлларын күрсәтсә, бик шат булачакмын.

Без тема буенча бөтен фикерләрне әйтеп бетерүне максат итмәдек, калган фикерләрне икенче төр башламлы эшләр өчен калдырдык. Әле укучының да үз сүзен әйтәсе яисә безнекен үз белгәннәре белән тулыландырасы, дәвам итәсе бар бит. Тәкъдим ителгән хезмәтләр — нигездә, дәрестә үткән материалны, әдәбият теориясеннән белемнәрне ныгыту юнәлешендә.

Бүгенге әти-әниләр, сигезьеллык (тугызъеллык) мәктәпне тәмамлаганда, ана теленнән сочинение язалар иде. Бу вакытка инде балаларның күпчелеге чын мәгънәсендә мөстәкыйль, фәнни фикер йөртергә өйрәнә, аның тормышка үз карашы формалаша. Алдагы сыйныфларда без аларда, зур тырышлык куеп, әкренлек белән язма сөйләм күнекмәләре булдырабыз. Әлбәттә, еллар узган саен, баланың мөстәкыйль язу осталыгы арта, ныгый, ә карашлары тагын да киңәя, кызыграк була бара.

XI сыйныф укучылары әдәбияттан чыгарылыш имтиханнары тапшырачак. Шуны күздә тотып, без 2002 елда тәкъдим ителгән темалар буенча да сочинение үрнәкләре китердек. Алар төрле сыйныфларга таратылды, дәрес темалары белән бәйләнештә, яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, төрле күләмдә һәм тирәнлектә башкарылды. Бер үк тема буенча алтынчы сыйныфта укучы язган эш һәм мәктәпне тәмамлаучыныкы бер дәрәҗәдә булмавын истән чыгармасагыз иде. Шул

ук вакытта алтынчыда укучы сәләтле баланың эше югары сыйныфның фәнне йомшаграк үзләштерүчесенекеннән яхшы да була ала бит! Кыскасы, бу китапка нindидер катгый таләпләрдән чыгып башкарылган хезмәт дип карарга кирәкми.

Кайберәүләр, мин изложениене бик җиңел язам, сочинениене бик авыр ерып чыгам яисә бөтенләй яза алмыйм, дип зарлана. Әгәр шулай икән, бу — әсәрне игътибарсыз укудан, аны аңламаудан, уйларга иренүдән килә. Язма сөйләмнең шулай ук башта туган фикерләрнең бер чагылышы булуы берегездә дә шик тудырмаска тиеш. Сүзсез чагылдырылган уй юк. Димәк, әзер фикер бирсәләр — язабыз, бирмәсәләр — уйлап баш ватмыйбыз булып чыга. Калдырган хаталарыбыз исә тел кагыйдәләрен белүебезне, аны куллану күнекмәләренең нык түгеллеген күрсәтеп тора. Бу урында шуны да искәртәсе килә: соңгы елларда чыккан сүзлекләрдә, дәреслекләрдә сүз язылышларында аерма бар, шунлыктан без элеккеге чыганакларга таяндык, әмма киләчәктә галимнәр, уртак бер фикергә килеп, аларны билгеле бер нормаларга буйсындырырлар дигән өметтә калабыз.

Укучының язма эшкә сәләте остазына да бик бәйле. Әгәр ул сыйныфның хикәя-повестьны, романны аңлавына ирешмәсә, язу эшләренә сәләтсез, стиль хаталарына тоемсыз булса, үз ихтыярына калдырылган бала ничек үссен, җитешсезлекләрен ничек күрсен ди?!

Минем мөгаллимнәргә әйтәсе килгәнем шул: теманы балаларга тәкъдим итәр алдыннан һич югы күңелегездә бернichә вариантта язма эш тудырыгыз. Әгәр аны башкару үзегезгә дә бик авыр икән, сезнең күзегезгә карап торган баладан ни көтәргә һәм аннан ничек таләп итәргә?!

Ана телебезне бозмыйча, матур итеп сөйләшкән, язган, озак еллар узгач та, рәхмәт хатлары юллаган укучыларыгыз булуын телим мин сезгә, дөньяның иң авыр, иң җаваплы бурычларын үз өстегезгә алган хезмәттәшләрем!

# V сыйныф

ГҮЗӘЛ ГАМЬ

## Безнең кенәри

Туган көнемә абыем кенәри бүләк иткән иде. Моны күргәч, әти бик матур читлек алып кайткан. Без аны аш бүлмәсенә куйдык. Әни көннәр буе шунда кайнаша бит. Мин дә аның янында торырга яратам. Рәхәтләнеп җырласын, әниебезнең күңелен ачсын әле, дидек.

Кенәри, чыннан да, бик җырлый торган кош булды. Аш бүлмәсендә сөйләшә башласак та, телевизорны кабызсак та, чут-чут сайрарга керешә. Ул үзе белән сөйләшәләр дип белә, ахрысы. Мин кайвакыт аны юри генә дә сайрата торган булдым. Янына киләм дә берәр көй сызгырынгалыйм.

Әнинең генә аның сайравына исе китмәде. Ул аны читлектә яшәве өчен бик тә кызганган сыман тоелды миңа. Зәңгәр кошчыкка еш моңаеп карап торуының сәбәбен сорагач, әни:

— Улым, кенәри ялгыз булганга сайрый, пары булса, болай ук илерә-илерә җырламас иде, — диде.

Безнең сөйләшүне әти дә тыңлап торган икән. Шул көнне үк ул кенәриебезгә пар алып кайтты.

## Көнбагыш

Көнбагыш ишек алдының түренә үк барып яткан да, койрыгын уйнатып, безне күзәтә. Шаян да, ялкау да пескәебезнең бер күзе йомылган, икенчесе кысык кына ачык.

Күктән, каршы ягыннан елмайган кояш бераздан күршеләребезнең алмагачы өстенә кунаклар. Көнбагыш та туфракка сеңеп утырган ап-ак ташларның икенчесенә барып ятар. Кояш белән бергә күчenеп йөргәнгә, Ринат абыебыз аңа Көнбагыш дип исем кушты да инде.

Көнбагышның акылы бер дә юк. Ул да безнең кебек — бала гына. Көне буе уйный, эшкә гамьсез. Ялгыш кына тычкан тотса да, ашарга ашыкмый: көннәр

буе туп урынына тәгәрәтепме-тәгәрәтә. Әбием: «Үскәч, оста аучы була ул», — ди. Аныңча, балалар уйный-уйный эшкә өйрәнәләр.

Көз җиткәндә, Көнбагыш дәү булыр. Күзләре инде хәзер үк өлгергән көнбагыш орлыкларына охшаган.

## Яраткан укытучым

Мин бөтен укытучыларымны да бик яратам. Кем турында гына язсам да, икенчеләрен үпкәләтермен шикелле, шулай да сыйныф җитәкчесе Чулпан апа турында сөйләрмендер.

Чулпан апа безне инглиз теленнән укыта. Русча да, татарча да бик матур сөйләшә үзе. Ул биергә, җырларга ярата. Артык нечкә күңелле: берәребез нинди дә булса авырлыкка тарса, тәмам кайгыга бата. Хәсрәт сүзе ишетсә дә, менә-менә елап җибәрер шикелле. Мин үзем аны һич кенә дә борчымаска тырышам. Кушкан эшләрен тыңлыйм, дәресләремне хәзерләп йөрим. Аның турында менә мондый шигырь дә чыгардым:

Бик тә, бик тә яратам мин
Чулпан Шамилевнаны.
Ул да яратсын дисәгез,
Үпкәләтмәгез аны!

Әйткән сүзләрен тыңлагыз,
Ул — әни кебек кеше.
Бәләкәй генә булса да,
Бик дәү эшләгән эше.

## Әбием

Җәйне авылда уздырдым. Әниемнең әнисе шунда яши минем. Ул инде олы яшьтә, беркайда да эшләми. Гомерен балаларга белем биреп уздырган. Кара зур күзләре кечерәеп, җыерчыклар эченә батып калган. Буш вакыт табып, кулына китап алганда, борын очына гына тимер кысалы күзлеген элеп куя. Әби китапны кычкырып, сәнгатьле итеп укырга ярата. Газетада язылган хәлләр белән дә безне күбрәк ул таныштыра.

Әби һаман да — чын укытучы инде менә. Әз генә кыек

эш эшләдеңме, шунда ук күреп ала. Орышып та куйгалый, аркабыздан сыйпый-сыйпый, гаебебезне дә аңлата, кайчак килешмәгән гамәлебезне көлеп кенә дә уздыра.

Әбине без әнидән, әтидән дә ныграк тыңлыйбыз. Ул бит — аларның да укытучылары. Әллә шуңа күрә, әллә дөрес санаганга, әллә әбиебезне бик яратканга, алар да аның сүзеннән бервакытта да чыкмый, каршы эндәшергә дә кыенсыналар.

Әбинең урыны — һәрчак түрдә. Без аннан башка чәй дә эчмибез, телевизор да карамыйбыз, кунакка да бармыйбыз. Өйдә ялгызы гына моңаеп утырмасын дип, бәйрәмгә дә үзебез белән ияртәбез.

Әби әби инде ул! Укытучы әби — әбиләрнең дә әбисе! Һич белмәгән эше юк! Бөтенебезне ярата, барыбызның да яхшы кешеләр булып үсүен тели.

## Пилмән

Әни белән пилмән бөгәбез. Итен күбрәк салыгыз, ди әтием. Камыры юка булып, тишелмәсен тагын, ди әбием. Кунаклар да киләсе, күбрәк салырсыз, дип өсти бабам.

Әни белән пилмән бөгәбез. Мин берне ясаганчы, ул икене өлгертә. Камыр кисү эше — абыйда, җәем җәю эше — әбидә. Әти белән бабай, хатын-кыз шөгыле дигән булып, читтән генә карап тора. Мин беләм: бөксәләр, бездән уздырачаклар. Ә бит пилмәнне алардан да күбрәк яраткан кеше юк!

## Мин чәчәкләр яратам

Хуш исләре белән җан шатлана,
Нурларыннан күзләр камаша.

*Мәҗит Гафури*

Мин чәчәкләр яратам. Бакчада үскәннәрен дә, кырда тирбәлгәннәрен дә, урман ышыгына качканнарын да, күл төбенә яшеренгәннәрен дә, акрын аккан сулар өстендә дулкынланганнарын да, тау битләрендә җилдә иркәләнгәннәрен дә...

Нәркисләр миңа язның сары күзләре кебек тоела. Бакча уртасында кызарышкан ал, кызыл лаләләрнең ачылмаганнарында ниндидер серлелек бар шикелле.

Аларның аска иелгән башлары күңелдә моңсулык уята.

Розаларны өзәргә кызганам. Туфракта бик озак яши алган ул гөлләр вазада көязләнергә теләми: сулалар, корыйлар.

Без бүләк ителгән розаларны төнгә ваннага салабыз, әмма күзгә йокы керми. Иртәнгә алар эчкән судан бүртенгән, хуш исләнеп киткәндәй була. Бу — үз-үзеңне, аларны алдау, чәчәк яшәвен вакытлыча гына озынайту. Алар гомере мәңгегә өзелгән инде.

— Ваннада йоклый торган чәчәк, — ди әнием аларны кулларына алганда, авыр сулап.

Соңгы елларда тырнак гөлләргә, резидәләргә игътибар бетте. Алар да якын миңа. Тыйнаклыклары өчен дә яратырга була икән гөлләрне!

Кашкарыйлар озынрак гомерле, артык нәзберек түгелләр. Күрәсезме, чәчәкләр дә кешеләр шикелле. Төрле холыклы. Төрле язмышлы. Талымчан, көйсезләре азрак яши, җилләргә, салкыннарга чыдамнары кадерсезрәк булсалар да, соң көзгә кадәр бакча түрендә утыралар.

Мин чәчәкләрне өзмим. Ризык саналмаган үләннәрне — әлеге матурлыкны өзү мәҗбүриме?! Гөнаһсыз чәчәкләрне нигә елатырга?!

## Якын дусларым

Мин беркемне дә икенчесеннән аерып куймыйм: һәр сыйныфташымны якын дустым итеп саныйм. Авылда да бар андый иптәшләр. Кирәк чакта сине коткарган, сиңа ярдәмгә килгән кеше дус була бит инде.

Сыйныфташ дусларым турында сөйлим әле. Олылар арасында алар кечкенә генә гномикларга охшап торалар. Тыштан җитдиләр, эчтән алай да түгелләрдер әле. Йөзләре кайвакыт шат, кайвакыт гүзәл, кайвакыт уйчан булып күренә. Ачуны китерсәләр, усал да тоелалар инде!

Алар тыз-быз гел йөренүдә. Нәрсәдер эшләгән гномиклар кебек. Тәнәфестә нәрсә эшләсеннәр инде... Шаяралар, уйныйлар, күченәләр. Кемдер кемнедер ега, кемнеңдер чәченнән тарта, сумкасын яшерә, аркасына язу ябыштыра.



Дуслар андый булмый дисезме? Минем дуслар шундый. Үзем менә андый түгел. Орышып та куйгалыйм, дәшми дә уздырам, шаярууларыннан көлгән дә булам. Гномикларга үпкәләп буламыни? Шаяру дуслыкка комачаулыймыни? Төрткәләшү — сугышу түгел лә ул. Дусларча сугышу дисәң дә була. Нәкъ шигыремдәгечә минем дуслар:

Дусларымны күрүгә,
Йөздә шатлык кабына.
Һәрбер уку елында
Яңа дуслар табыла.

Матур, чибәр дусларым —
Танырсың бер күрүдә.
Үртәшүдә, төртешүдә —
Алар шау-гөр килүдә.

## Габдулла Тукай һәйкәле янында

Остазларым иңбашына басып,
Заман үрләренә карадым.
*Гамил Афзал*

Һәр елның апрель аенда шигырь сөючеләр Тукай һәйкәле янына җыела. Сыйныфыбыз белән без дә барабыз. Монда танылган шагыйрьләрне, артистларны очратырга мөмкин, яңа дуслар табарга була.

Казан үзәгендә Тукайга ике һәйкәл булса да, ул туган көндә Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры янында җыелу гадәткә кергән. Монда транспорт йөрми. Һәйкәлнең каршы ягындагы калкулыктан сөйләүчеләрне бик яхшы күрергә мөмкин.

Апрель ае күп вакыт җилле, яңгырлы була. Һава торышы бик шәптән булмаган елларны да халык яраткан Тукаен онытмый, чәчәкләр алып, шигырьләрен өйрәнеп, һәйкәл янына килә.

Мин үзем бигрәк тә шагыйрьләр сөйләгәнне тыңларга яратам. Тукай бүләгенә лаек булган олы шәхесләрнең һәммәсе үзләрен аның каршысында бик кечкенә тоюларын, аны остаз санауларын әйтә.

12 Тукай — һәрберебезнең остазы. Бәйкәл каршысында ул язган әсәрләрне артистлар башкаруында тыңлаганда, әйткәннәренең тугрылыгына, фикерләренең тирәнлегенә шаккатасың.

## Туган ягым табигате

Мин Башкортстанда туганмын. Казан аннан бик ерак булганлыктан, бик сирәк кайтам, әмма, кайткан саен, табигатенең матурлыгына, байлыгына сокланып киләм.

Бабамнар Бакалы районының Бишкаен авылында яши. Дөрес, авылдашларым аны күбрәк Саскүл, Сазкүл дип йөртәләр.

Бишкаен Ык елгасы ярына урнашкан. Бабамнарның бакчасы башында ул икегә аерыла. Елга тармаклары арасында — юалы болын. Каршы як тауда да юалар үсә. Иртә язда кайтсаң, болын буйлап юа тәмләп атлыйсың.

Ыкның ярларын тал-тирәкләр каплаган. Шомыртлыклар язын чәчәккә күмелә, борын кытыкларлык хуш ис бөрки.

Бишкаен урманнарында балан, бөрлегән, җир җиләге бик уңа. Сазлыклы урыннарда мин белмәгән әллә нинди чәчәкләр үсә.

Башкортстан кешеләре умарта тотарга һәвәс. Безнең бакчабызда да әллә ничә баш оя утыра. Бал кортлары күч аерганда, бакча тирәсен әйләнеп узарга тырышам.

И-и, ул Ыкта балыкның күплеге! Минем ише кармакка юньләп җим киертә белмәгән шәһәр кызларына да эләгә хәтта.

Кичләрен, тау башына менеп, ерак-еракларга карап утырырга яратам. Уйсулыклар, юллар буйлап йөртеп, күземне рәхәтләндерәм. Ул юлларның һәрберсе аша узып, Казаныма барып була дип сөенәм.

## Мин шофер булырга телим!

Мин бары тик шофер гына булам. Танк та йөртмим, пароходлар, самолетлар да кирәк түгел миңа. Әтием кебек, машина йөртәчәкмен.

Миңа кырлар буйлап сузылган юллардан офыкларны артка чигерә-чигерә бару ошый. Яңгыр юган асфальт-

лардан су чәчрәтеп узарга яратам. Елгаларны эх дигәнче аркылы кичү дә — шәп!

Мин бары шофер гына булам. Укытучылар, билгеләрең яхшы, югары уку йортларына кер, дип кыстый. Шофер да белемле булырга тиеш, минемчә. Машинасы ватылгач, башкалардан ярдәм сораган ир кеше буласым килми минем. Мин үз автомобилемнең йөрәген үзем төзәтәчәкмен, аны үзем генә юачакмын, аны үземнең дустыма әйләндерәчәкмен.

Машина җене кагылган миңа. Бик яхшы. Мин шофер булачакмын!

## Туган йортым бусагасы

Ерак юллардан кайтышлый, Казанга таба якынлашканда, йөрәк сикерә. Менә-менә кайтып җитәчәгеңне белү алгысыта. Казан тирәсендәге бакчалар янында: «Бусагага килеп җиттек», — дип уйлап куясың.

Казанга Арча ягыннан кергәндә, Компрессорлар заводы алдындагы каенлык әлеге бусаганың соң өлеше кебек тоела. Моннан инде Казанның үзе башлана. Дәрвишләр бистәсе — аның бусагасы гына әле...

Казан. Киң урамнары, биек йортлары, күперләре, эреле-ваклы күлләре, зур елгалары — барысы, барысы белән дә яраттыра ул үзен. Монда төрле уку йортлары, музейлар, театрлар бар. Монда олуг шәхесләр күмелгән зиратлар саклана.

Казан. Синдә мин яшим. Синдә — дусларым, туганнарым, милләттәшләрем. Син үзең исә — Туган йортымның бусагасы.

## Яз килде

Яз килде. Җылы. Рәхәт. Күңел шат. Гәүдәләр җиңеләеп калды.

Яз килде. Урамнан керәсе, дәрес хәзерлисе дә бик үк килми башлады. Кирәк. Кирәклеген беләсең, хәзерлисең.

Яз килде. Тәрәз каршындагы агачлар төн эчендә яфрак ярды. Тирә-якны ураткан сыек кына яшеллек күзләрне иркәли. Куелык капламаган агачлар аркылы узган кояш күзне чага.

Яз килде. Иртән тәрәзәләрне ачып куйсаң, кошлар-

14 ның сайраганына чыдар хәл юк. Болынга төшсәң, су тавышын тыңлап сихерләнәсең.

Яз килде. Бакча эшләре башланды. Әти, лапас түбәсеннән көрәк-тырмаларны төшереп, бакча капкасына сөяп куйды. Эштән кайтып хәл алгач, җир казып, йомшартып маташа. Без дә аның тирәсендә кайнашабыз.

Яз килде. Бик акрын килә дә бик тиз узып та китә шул ул...

## ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

### Җиде — бәхет саны

Борынгы әкиятләрдә җиде саны бик күп кулланыла. Геройлары нинди генә авырлыкка юлыкса да, әнә шул җиде саны аларга ярдәмгә килә. Димәк, безнең бабаларыбыз җиде санын бик яраткан, бәхет китерә дип исәпләгән.

«Җилбикә белән Сылубикә» әкияте: «Борын-борын заманда җиде тауның артында, җиде суның янында, җиде юлның чатында...» дип башлана. Әкияттә сүз җиде ир туганның иркәсе Җилбикә турында бара. Бәхет артыннан киткән абыйларын җиде ел көткәннән соң, ул төшендә аларны эзләргә тотына. Бер атна (җиде көн!) узгач, ул ниндидер тау тишегенә килеп чыга. Бер бабайның кушуы буенча, җиде канатлы арба ЭНЕЛӘТӘ. Юлга алырга дип, җиде күлмәк, җиде ыштан, җиде сөлге хәзерли.

Шуннан соң өнендә, күрше кызы Сылубикә белән бергәләп, дөнья гизәргә чыгып китә Җилбикә. Җиденче таңда агымсу буена туктаганнар алар. Җиденче көн дигәндә, кызның абыйларын да тапканнар.

Үгилектә үсеп икейөзлегә әйләнгән Сылубикә киртәләр корса да, Җилбикә теләгәненә ирешкән: абыйларын тапкан. Алар исә бәхеткә юл ачкан: кызларны һөнәр мәктәбенә биргәннәр. Җиде саны кызларны бәхет капкасына илткән.

### Җиде кат үлчә, бер кат кис

Әдәбият дәресендә мәкальләр өйрәнә идек. Әлфия тыңлап утырмаганны күргәч, укытучы кисәтү ясады:

— Әлфия, теманы аңламыйча каласың бит!

— Апа, мин мәкальләрне болай да беләм, — диде Әлфия.

Дәрес бетте. Хезмәт бүлмәсенә җыелдык. Гөлфия Кирамовна үлчәм алырга, алып килгән тукымалардан өлгеләр кисәргә өйрәтте. Әлфия тагын шаярып утырды.

Һәрбер кеше үз эшенә бирелгән бер вакытта Әлфия өстәле куелган почмактан мышык-мышык елау тавышы ишетелде. Бераздан ул:

— Апа, тукымамны боздым. Әнием орышыр инде, — дип пышылдады.

— Җиде кат үлчә, бер кат кис, — диде укытучы. — Синең ул мәкальне ишеткәнең юк идемени?

Әлфия дәшмәде.

### Эш беткәч, уйнарга ярый

Г. Тукай әсәрләр язганда халык авыз иҗаты үрнәкләрен файдалана. «Эш беткәч, уйнарга ярый» шигыренең атамасы — мәкаль. Шигырьнең эчендә ул юк, әмма шагыйрь шул фикерне башкачарак итеп әйтә. Дәрес хәзерләп утыручы сабый башта — Кояшка, аннан — Сандугачка, аннан Алмагачка, дәресен тәмамламый торып, уйнарга чыкмаячагын белдерә.

Сабыйның акыллылыгын табигать тә бәяли: Кояш аңа көлеп карый, Алмагач аңа җимешен суза. Сандугач шатланып җырлап җибәрә. Һәрбер агач бала алдында баш ия.

## ӘДӘБИЯТ

### Су анасы сабагы

*(Габдулла Тукайның «Су анасы» шигыре буенча)*

Безнең һәммәбез белән төрле-төрле хәлләр булып тора. Көтелмәгән вакыйгалардан акыллы кеше гыйбрәт ала. Ничек итеп дөрес яшәргә өйрәнә.

«Су анасы» шигырендәге малай хакында без карак дип әйтә алмыйбыз. Ул төнге хәлләрдән сихерләнеп калгандай тоелды миңа. Су анасының алтын тарагын күрсен дә, нинди бала кызыкмасын инде! Аның белән мактанырга, икенче көнне иптәш малайларны шакка-

тырырга да була ич. Таракны күрсәтмәсәң, әле сиңа ышанмаячаклар да!

Шулай да әкият герое үзенең дөрес эш эшләмәгәнен алдан ук белә. Беренчедән, таракны тирә-ягында кеше булмаганнан файдаланып ала. Икенчедән, куып җитмәсеннәр өчен, ул бик нык ашыга. Өченчедән, әнисенә дә, алтын таракны таптым, дип әйтә.

Шул ук вакытта малай булган хәлләрне иң якын кешесенә түкми-чәчми сөйләп тә бирә.

Малай алтын таракка бәйле вакыйгалардан үзенә гомерлек сабак алуы хакында әйтә. Ул инде, иясе юклыкка шиге булмаганда да, кеше әйберләренә тими. Ә бит шагыйрь язган әкият үзе дә безнең барыбызга шул сабакны бирә.

## Татар йорты

*(Әхмәт Фәйзинең «Тукай» романы буенча)*

Ә. Фәйзинең «Тукай» романыннан өзек укып чыккан идем, күнем шуның тәэсирендә үтте. Әдипнең узган тормышны яхшы белүенә таң калдым. Ул бабаларыбызның яшәү рәвешен минем күз алдыма да китереп бастырды.

Менә Вәли абзыйларның өй эче тасвиры. Түрдәге киезле сәке өстендә — сары белән чуптарлап чиккән киҗеле ашъяулык. Ул — Газизә апаның бирнә бүләге. Аның уртасындагы күк ямау да бер бизәк булып кына күренәдер. Бик килешле һәм пөхтә салынгандыр.

Җиз самавырсыз өстәл өстәл түгел. Ул һәрвакыт кайнап, пар пошкырып утырса, килгән кунак өй хуҗасының юмартлыгы, киң күңеллелеге турында уйлый. Ашъяулык өстендә чынаяклар, шикәр, калын телем рәвешендә киселгән икмәк тора. Төн караңгылыгын җиделе лампа яктырта.

Ат туарып кергән олаучының камыт белән эшлеяләрне ишек ягына сөяп куюыннан без андый әсбапларның урыны шунда икәнлекне чамалыйбыз.

Габдуллага урынны сәкегә җәяләр. Ул кояш яктысы иңгән, бик күп тәрәзәле озынчарак кечкенә бүлмәдә уяна. Тәрәзә төбендәге чүлмәкләрдә татар хатыннары әле дә бик яратып үстергән гөлләр утыра. Тамчылы гөл, кына һәм яран гөлләре алар.

17

Ян тәрәзә янындагы кечкенә тәбәнәк өстәл өстенең эш кораллары белән тулганлыгы хуҗаның һөнәрле кеше булуы хакында сөйли. Шүрлеккә күз салгач, без аның читек-кәвешче икәнлегенә төшенәбез. Вәли абзый аларны төрле калыплар, күн кисәкләре, чүкеч, пычак, игәүләр ярдәмендә ясый булса кирәк.

Газизә апа Габдуллага чуклы кәләпүш вәгъдә итә. Икенче бер шүрлектә яисә башка бер җирдә чигү җепләре, эреле-ваклы мәрҗәннәр, бәрхет тукымалар, башлык калыплары торадыр дип уйлыйм мин.

Һәрбер татар һөнәрчесенең өе элекке заманда якынча шундый булган булса кирәк. Ул анда яшәгән, йоклаган һәм эшләгән дә. Бер үк вакытта йорттагы һәр почмакны аерым бер эшкә көйләгән.

## Кыр казы

*(Мәҗит Гафурының «Кыр казы» әсәре буенча)*

М. Гафуриның «Кыр казы» әсәреннән иң истә калган образ кыр казы булды. Дәреслеккә урнаштырылган өзек күл тасвирыннан башлана. Язучы аны түгәрәк көзге белән чагыштыра. Кич җиткәндә, тирә-ягында үскән камышлар арасыннан су кошлары тавышы килеп торуын әйтә. Ак күл исә яктылык сирпегән бер хозурлык почмагы булып күңелгә уела.

Кошлар — теләсә кайсы күлнең бизәге. Күл аларны, үз чиратында, туендыра, йоклата, яман күздән саклый.

Без Ак күлне аеруча кыр казларының үз иткәнен күрәбез. Болыт кебек һавага күтәрелгән казлар әсәр героена да бик якын. «Анда һәр көн дөньяның бер чигеннән икенче чигенә бара торган кыр казларының тезелешеп килеп кунарга төшүләрен карап торам һәм, аларның матур тавышларын тыңлап, аларны читтән карап, төрле уйларга чумам», — ди ул.

Малай кыр казларын бик бирелеп күзәтә, аларның дөнья гизүенә көнләшеп карый. Бервакыт күлдә ялгызы калган кыр казына тап була ул. Очарга талпынса да, кыр казы, бик хәлсезләнгәнлектән, сыңар канатлы гына калганлыктан, күтәрелеп китә алмый.

Малайның атасы, кошны интектермәс өчен генә, башта

суймакчы да була, әмма яшьле күз белән әйткән үтенечкә ризалык бирә.

Кыр казының портреты укучы күзләреннән дә яшь тәгәрәтерлек итеп тудырылган. Анда ашау кайгысы да юк, бер почмакка сыенган да тик тора. Йорт казларын күрү генә аны уятып җибәргәндәй була. Хуҗа кошлар чит-ятны бик тиз танып алалар һәм һөҗүмгә үк ташланалар.

Тора-бара каз тернәкләнә, йорт ризыкларын ашарга күнегә, малайга да ияләшә. Кышка кергәндә, ул инде канатларын аркасына салгалый башлый.

Бакча иркенлегенә чыккан кыр казы малайны аеруча куандыра. Кыш узуга, кош тәмам сәламәтләнә. Язын үткән ел аерылып калган иптәшләренә кушыла.

Кечкенә генә бер өзектә язучы кошлар язмышын, алар кичергәнне, алар холкын бөтен нечкәлекләре белән тудыруга ирешкән.

Гаҗизлектә көн иткән җан иясе, соңгы сәламен җиткереп, күккә күтәрелә. Малай «аның тарлыкта, кеше кулы астында яши алмавына, киң дөньяны артык күрүенә хәйран» кала.

## Батырлыктан туган матурлык

*(Фатих Кәримнең сугыш чоры иҗаты буенча)*

«Батыр бул син, абый», — дигәнсең,
Ефәк җепләр белән чиккәнсең.

*Фатих Кәрим*

Ф. Кәримне сугыш чоры талантлы шагыйрь, батыр сугышчы итеп таныта. Фронтның авыр шартларында ул рухи күтәренкелек ташып торган «Кыңгыраулы яшел гармун», «Тимер һәм тимерче» кебек поэмаларын иҗат итә. Аның җырлап торган зур күләмле әсәрләре укучыны ялыктырмый, образлары үзенчәлекле булып күңелгә уела.

Батырлык темасы Ф. Кәрим иҗатының үзәгендә тора. Аның төрле яшьтәге, төрле холыктагы геройларын Туган илне ярату, кыюлык, дусларга тугрылык һәм башка сыйфатлар берләштерә. Бу сыйфатлар сугыш кырларында бик кирәк.

«Пионерка Гөлчәчәккә хат» поэмасының төп герое —

солдат. Ул үзенең кызга язган хатын җырга тиңли. Әлеге җырның Гөлчәчәктәй матур булуын, тау чишмәсе кебек чылтырап торуын тели. Без дә аны хат-җыр дип укыйбыз.

Хатны Гөлчәчәккә юллау — шагыйрь сайлаган бер алым гына. Гөлчәчәк ул — сугыш чорының теләсә кайсы баласы. Шул ук вакытта син дә, мин дә хатны үзебезгә адресланган дип саный алабыз.

Шигырьнең икенче бүлегеннән без солдатның разведчик икәнлеген аңлыйбыз. Вакыйгаларны сөйләүче Гөлчәчәк исемле кыз җибәргән яулыкның, халык хисе булып, төнге окопларга килгәненә сөенә. Анда исә — батырлыкка чакыру юллары. Димәк, ир-егет каһарманлык күрсәтүне халык алдында бурыч үтәү дип саный.

Өченче бүлектә героебыз батырлык эшләү шартына куела. Безне шундый вакытта ул үзен ничек тотар дигән уй борчый. Герой өметебезне аклый: урман буйлап яшь бер кызны куып килгән ике фашистның гомерен өзә.

Разведчик коткарган кыз партизаннар ярдәмчесе булып чыга. Ляля-Ләйлә аның кулына бик мөһим бер хат тоттыра.

Бу вакыйга сугыш вакытында сабыйларның да зур батырлыкларга сәләтлелеген күрсәтә. Гөлчәчәк җибәргән чигүле яулыкның файдасы тия. Егет аның белән Ләйләнең яралы башын бәйли.

Ф. Кәрим бу шигырьдә батырлыктан туган бер матурлык хакында сөйли. Сугыш кырларында турыдан-туры катнашкан лирик мин белән Ләйлә генә түгел, хәтта алар өчен төннәрен чигү чиккән Гөлчәчәк кебек йөзләгән, меңләгән илебез кызлары әнә шул матурлыкның үрнәкләрен күрсәтә.

## Осталык — иң зур байлык

*(Шәүкәт Галиевнең «Алтын куллар» шигыре буенча)*

Ш. Галиевнең «Алтын куллар» шигырендә һәр нәрсәне булдыра ала торган кеше куллары турында сөйләнелә. Андый куллы булу теләсә кемнең кулыннан килә, моның өчен һөнәргә өйрәнергә, белем алырга һәм бик тырыш булырга кирәк.

Җир шарын кеше хезмәте бизи. Кеше бакчалар үстерә, чүлләрне терелтә, шәһәрләр төзи. Космонавтлар, юл

салучылар — безнең апа-абыйларыбыз ул. Шагыйрь, алар турында сөйләгәндә, бу балалар да белем алсыннар, хезмәткә өйрәнсеннәр дип теләгәндер, шуңа күрә ул әсәрен:

Әйтим шунсын —
Ул кулларда
Юк сер, тылсым...
Алтын түгел,
Гади куллар —
Синдә дә бар
Андый куллар! —

дип тәмамлый. Дөнья матур булсын өчен, син дә, мин дә үз өлешеңне кертергә тиеш. Нинди дә булса осталыкка ия булуың — зур байлыгың ул. Кешеләр сине шул осталыгың буенча бәяләрләр.

# VI сыйныф

ГҮЗӘЛ ГАМЬ

### Минем тормышымда матур әдәбият

Мин китапсыз яши алмыйм. Нинди темага язылган булсалар да, укыйм мин аларны.

Айгөл исемле дус кызым бар. Ул, минем белән бер яшьтә булса да, гел мәхәббәт китаплары гына укый. Дус малаема гашыйк булдым, аны ничек үземә каратырга өйрәнәм, дигән була.

Марат исемле сыйныфташым детективлар ярата. Дәресләр башланганчы, безне үзе укыганнарны сөйләп, туйдырып та бетерә.

Әнием шигырь китапларын сөя төшә. Үзе дә шагыйрә булгангадыр инде.

Мин менә төрле китаплар яратам. Матур әдәбият дигәннәре матур гына булсын! Язучы абый-апалар бу сүзләрне каян табып бетерәләр микән дип шаккатам. Укыганнарымны тормыш белән чагыштырам. Кайвакыт язылганнарны чынга охшатмыйм да китапны, ахырына кадәр укып чыкмыйча, кырыйга алып куям.

Кышын сәгатьләр буе китаптан баш күтәрмәгән чаклар

була. Әнием әйтмешли, китап тәмен беләм мин. Ул миңа һава, су кебек кирәк. Мин укымыйча яши алмыйм. Шуның сәбәбен дә аңламыйм.

### «Китап укып елый алганнарның Күңелендә булмый каралык»

*(М. Әгъләмов)*

Апа Хәсән Туфанның «Кайсыгызның кулы җылы?» шигырен укыганда, партадашым Фаилнең күзләрендә яшь иде. Беркемне рәнҗетми, беркемгә авыр сүз әйтми торган малай ул — Фаил! Безнең якка да әллә кайдан, ерактан, Төрекмәнстан ягыннан кайтып төшкән. Фаилнең анда туганнары, абый-апалары, әтисе калган.

Фаил кайтканда татарча бик авыр аңлый иде. Без аның белән җәй буе бергә уйнадык, балыкка, җиләккә йөрдек. Тора-бара ул мине уздырып сөйләшергә өйрәнде.

Фаил, урманлы якта яшәмәгәнгәме, үләннәргә дә кызганып кына баса, бездәге җиләс һавага, су сипмичә дә үскән агачларга, яшелчәләргә шakkата.

Фаил, безнең авылны бик яратса да, туган, үскән ягын сагына, туганнары белән очрашырга тели.

Ул моңа кадәр Хәсән Туфан исемле татар шагыйренең барлыгын белмәгән. Апа аның сөргеннәрдә йөрүен, хатынын югалтуын сөйләгәч, шуның артыннан әлеге шигырьне дә укып биргәч, Фаил чын-чынлап кайгыга батты.

Хәсрәтле кеше генә башкалар хәсрәтен чын-чынлап аңлый шул. Миңа Фаил үзе дә:

— Кайсыгызның кулы җылы? — дип карагандай тоелды.

Фаил, нинди генә китап укыса да, уйга кала, юк кына вакыйгалар өчен дә борчыла. Менә шуннан соң аның күңелендә ни өчен каралык булмавын аңлыйсың инде. Китапта язганнарны да чындагы кебек кичергән кеше тормышта булган вакыйгаларны йөрәгенә тагын да якынрак ала торгандыр.

### «Кеше өчен иң әүвәле намус дигән...»

*(Мөнәҗәттән )*

Намус сүзен төрле кеше төрлечә аңлый.

Кайберәүләр башкаларны чит өлешкә керүдә гаепли,

намуссыз дип атый, шул ук вакытта үзе дә эш урыныннан ни дә булса эләктереп кайтырга гына тора.

Троллейбус йөртүче билет алмаучыны пыр туздыра, үзе исә, иске билетларны җыеп, яңадан сатуын намуссызлыкка санамый. Ишектән чыкканда, тикшерүчеләр билетсызларны эләктереп алалар да алар сузган акчаны кесәләренә салалар.

Намуссызлык безне һәр урында сагалый. Кемдер синең хакта дөрес булмаган сүз сөйли. Кемдер, синнән күчереп кенә, яхшы укый. Кемдер, башкалар эшләгәндә, өйрәтеп, карап тора... Шулай да, андыйлар барлыгына сылтап, намуссыз булырга ярамый. Кеше үз сыйфатлары өчен үзе генә җавап бирә.

### «Җир йөзе шундый киң, күңелле һәм якты»

*(М. Җәлил)*

Мин үземне бик бәхетле сизәм. Әтием — янымда, әнием исән, әби-бабам да аякларында йөреп, йорт тирәсен караштырып тора.

Мәктәптә бишле алсам да, берәр нәрсә бүләк итсәләр дә, дус-ишләрем кунакка килсә дә, дөнья тагын да киңәебрәк киткәндәй, өй эчебез нурга күмелгәндәй тоела, күңел яктыра.

Иртән торышыма әни тәмле ризыклар пешерсә дә, кич ятканымда әти аркадан сыпырса да, мәчем аягым очыма ятып йокласа да, сөенәм. Эчемнән, мин нинди бәхетле, җир йөзе нинди киң, яшәвем нинди күңелле дип кабатлыйм.

### Туган як

Апа-абыйлар, минем туган ягым — Тукай ягы, я булмаса, мин — Каюм Насыйри туган авылдан, дип мактана. Кайберәүләр, без — минзәләлеләр, мин бит — мишәр ягыннан, дип сөйләшә. Ерак Башкортстаннан килгән татарлар, зурдан кубып, без — башкортстанлылар, дип сөйли. Кем белән, кайда сөйләшүләренә карап, туган як кечкенәя дә, зурая да. Каникулдан килгәннән соң, дусларым әби-бабайлары торган як белән мактаныша. Аларның кайберләре кайтып йөргән авылларын хәтта туган як дип саный.

Авылга кайтсам, күршеләр:

— Казан малае кайттымыни? Бәрәңгене сагынганмыни? — дип шаярта. Инде Казанга килсәм, әти белән әни:

— Безнең авыл малае да кунакка килгән, — дип көләләр. Шулай булгач, минем туган як кайда соң?

Минемчә, Казанда тугач, туган җирем дә Казан буладыр инде. Аны туган як дип атасаң да ярый. Әбиләрем Арча районында яши минем, Казан арты диләр аны. Туган якны зур итеп күз алдына китерсәң, аны да туган як дип атарга була ич!

Шәһәрдә мин кино-театрларга йөрим, ял көннәрендә паркка чыгам, Аккош күленә су коенырга барам. Казанбашка кайтсам, тизрәк болынга йөгерәм. Елгабыз әллә ни тирән дә түгел үзе, әмма безнең ише малайларга Казансу тирәнлеге генә җитә!

Миңа Казанбашка сабантуй бәйрәменә кайту ошый. Ат ярышын гына карый алмыйм. Җиңелгән атларны күргәч, күзгә яшь килә. Әле ярый безнең якта бер матур гадәт бар: иң соңыннан килгән атка бик күп бүләк бирәләр. Сабый бала шикелле, ул да тынычланып калгандай була.

Казаныма мин үзем дә сабантуй яулыклары, сөлгеләре алып кайтам: туган ягымның яшел болынында көрәшәм, йөгерәм, уеннарда катнашам.

## Туган авылым минем...

Минем туган авылым Түбән Өскебаш дип атала. Еракларга кунакка барганда, әлеге исемне әйткәч, башның аскысы белән өскесе буламыни, дип көләләр. Үз аңлавымнан чыгып әйтәм: Өске авылы, Өске елгасы бар, шул Өскенең башы бар, алар исә икәү булганнар да, су агымына карап, берсен — Югары, берсен Түбән Өскебаш дип атаганнар.

Хәер, исемдәмени хикмәт! Безнең якта авыл саен — икешәр исем! Югары Өскебашны барыбер Казаклар дип йөрибез без, ә безнеке Өскебаш кына булып кала.

Мин туган авылымны ягымлы кешеләре, урман-кырлары, як-яктан әйләндереп алган урманнары өчен яратам. Әле һәр җирнең исемен дә белеп бетермәсәм: дә, Караңгы тауда каен җиләге уңганын, Каршы як ур-

24 манда кура, гөмбә күплеген, Тау якныкында төрледән-төрле чәчәкләр үскәнен, шуңа күрә печәненең хуш исле икәнлеген беләм.

Урманда печәнлегебез бар. Аның уртасында кемнәрдәндер уелып калган тирән чокыр хәзер күлгә әйләнгән, печәнгә төшкәч, шунда су коенабыз.

Безнең урманнарда еланнар да очрый. Куркам да инде шулардан! Очрасам, алны-артны карамый чабам.

Бик каты сусаганда, поши эзләреннән су эчәбез, якында булса, урман чишмәләре суы белән сихәтләнәбез без.

Урман юллары авылларга чыга, алар сине адаштырмый. Авылыбыз урманлы дип сөенә минем әти. Минем авыл шул ул!

## ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

**«Сүз күңелдә очкын булып көйри,**
**Сүз арыслан итә йөрәкне»**

*(Г. Афзал)*

Халык җырларын тыныч кына тыңлый алмыйм. Аларга халкыбызның бөтен хәсрәт-шатлыгы салынгандыр кебек тоела миңа. Тыңлап туймаслык көйләр бар безнең халыкта!

Җыр авыр вакытта тынычландыра, шатланганда хисләреңне тагын да көчәйтә ала.

Эш эшләгәндә дә, уйнаганда-шаярганда да, ял иткәндә дә, сугышка киткәндә дә, җыр җырлаганнар.

Кызыл армия, гражданнар сугышы, хезмәткә алыну турында җырларда Туган ил белән аерылу хәсрәте дә, яшьлек хыяллары да, өмет һәм өметсезлек тә бергә кушылган.

Халык җырлары һаман да языла әле. Безнең авылда егетләрне Армиягә бергәләп озату гадәте бар. Андый вакытта кызлар-егетләр төрле җырлар чыгаралар, берберсен үртиләр яисә егетләрне батырлыкларга өндиләр. Абыем хезмәткә алынганда:

Моннан киткәч, төннәр буе
Окопларда ятырсың.
Туры атсаң, тиз йөгерсәң,
Яллар алып кайтырсың, —

дип җырладылар.

Бәйрәмгә абыйның яраткан кызы да килгән иде. Аның җыры бигрәк тә истә калган:

Кулымдагы балдагымның
Исемнәре Габделнур.
Мин көтәрмен, инде үзең
Җаен табып кайтыр бул.

Абыемнар әле китеп тә өлгермәгән, аларны инде сагына ук башлаганнар диярсең. Ә бит, чынлыкта да, шушы җырны исендә калдырган абый бик яхшы хезмәт итәчәк, медальләр тагып, берәр елдан ялга да кайтып җитәчәк! Юкка гына, сүз йөрәкне арыслан итә, димиләр.

**Ай былбылым**

Бу җыр — бәйрәм табыннарының күрке. Аны белмәгән кеше юк. Аны һәркем үзенчә аңлый, үзенчә ярата.

Ай былбылым, вай былбылым,
Агыйделнең камышы.

Күз алдыма җәйге таң, тирән күл, камышлык килә. Иртәнге таң җилләрен уятырлык итеп, сандугач сайрый. Былбыл — шул сандугач бит инде ул.

Былбыл сүзе бик күп халыкларда бар диләр. Хәтта руслар да урман кошларының бер төрен шушы сүзгә охшатып атый икән.

Таңнар ата. Өзелә үзәк,
Җырлата да елата, —

ди «Ай былбылым»ны чыгарган кеше. Әйе, моңсу чакта җырлыйбыз шул без.

Ә җырчы нәрсә өчен хәсрәтләнә?

Синең хакта серләремне
Сөйлим сандугачларга, —

ди ул. Димәк, җыр — ярату, сөю-сөелү турында. Бәлки, ул — аерылу сагышы турындадыр?!

Ә бәлки, җырны чыгарган кеше сөйгәненә аны ярату турында әйтә алмагандыр?! Әллә кыз шул яратуны кабул итмәде микән?!

Хәер, җырның кем, нәрсә хакында чыгарылган булуы шул кадәр үк мөһим дә түгел. Син бит аңа барыбер үз уйларыңны, үз көеңне кушасың.

26

**«Күзге ачы җилләрдә»не укыгач...**

Беренче бөтендөнья сугышы елларында иҗат ителгән әлеге җырны ни өчен һаман да яратып тыңлыйлар? Тыңлыйлар, дип язам, бу җырны дөрес, моңлы башкаруны барыбыз булдыра да алмыйдыр шикелле.

Җыр текстының беренче юллары ук бәхетсезлекне чагылдыра. Күлгә барсам да, балык эләкми, дип җырлаучы, безгә бәхет елмаймый, дип әйтәдер шикелле миңа. Ни өчен шулай боега, авыр хисләргә бирелә соң ул? Алдагы юлларда бу сорауга җавап бар шикелле. Туган иленнән аерылган икән лирик герой.

Шуннан соң әлеге аерылу сәбәбен ачыклый башлыйсың. Хәсрәтен җырга салучы сугышка киткән икән шул. Шул ук вакытта ул бу аерылуда патшаны, хаким сыйныфларны да гаепли шикелле. Патшаны ул кирәксез үк саный. Заманы өчен бик кыю җыр булган бит «Көзге ачы җилләрдә»!

Илеңнән, өеңнән ерак булсаң, җиле дә үзәккә үтә шул аның. Мин сугыш юллары буйлап узган яралы, ач-ялангач солдатлар хакында уйлыйм. Җыр бу юлларның озынлыгын, сугышның тиз генә бетмәслеген сөйли, шуңа күрә аның көе дә авыр, сузынкыдыр кебек. Ул миңа комлы ярга таба авыр кораблар тарткан бурлаклар җырын хәтеремә китерә.

ӘДӘБИЯТ

**Г. Камалның «Беренче театр» комедиясендә Бибинең башкалар белән мөнәсәбәте**

«Беренче театр» әсәрендә Хәмзә бай һәм яңалыкны яклаучы яшьләр арасында барган конфликт башкаларның үзара мөнәсәбәтенә игътибарны киметә. Шулай да нәкъ менә пьесада катнашучыларның бер-берсе белән аңлашулары комедияне кызыклы итә, аңа урын да күбрәк бирелгән. Ул-кызларын, кияү-киленнәрен куркытып торган Хәмзә бай пьесаның ахырында гына пәйда була, һәм шуннан соң моңа кадәр яшерелгән бөтен серләр дә чишелә.

Элекке тормышны тасвирлаган кайбер рус әсәрләрендә дә, татарча китапларда да асрау кызлар надан, ахмак

27

итеп тасвирлана, аңгыралыклары аркасында гына кемгәдер хезмәт итә кебек фикер туа. «Беренче театр»дагы Биби дә — кислотаны киез катадан аера алмаган бер кыз. Шул ук вакытта аны дөм юләр дип тә булмый. Бибинең һәр эшләгән «ахмаклыгы» — үз файдасына. Аңламавыннан туеп беткән хуҗаларның эшне җиңеләйтәчәген белә ул.

Әсәр башында Биби, артык сүз сөйләп, Вәлине йөдәтә. Аның йомышын һаман үзенчә аңлый. Соңрак башка геройларның да аның белән аралашудан башы ката.

Бибигә һәрвакыт нәрсәне ничек башкарырга икәнне төгәл әйтергә кирәк, югыйсә эшне бозачак. Ә бәлки, ул махсус шулай эшлидер? Әнә бит Вәлиләрнең чыгып китүен генә көтеп торган кебек, Биби серне Факиһәгә сөйләп ташлый. Ул исә аннан үзен озак ирештертергә теләми, шуңа күрә «Күп телеңә салынма», — ди.

Фатих белән сөйләшкәндә, Бибинең шаяртканы ачык күренеп тора. Биби тагын үзен «акыллы ахмак» кебек тота: Фатихның, хатынлыкка алам, дип юри генә әйткән сүзе дә уйга сала аны.

Бибине беркем дә кешегә санамый. Бай абзасы бигрәк тә. Туктаусыз әрләп кенә тора. Бу хәлләр Бибидә үч алу уе тудыра. Аларны да орышсын әле, дип, театр турындагы серне чишә.

Биби белән хуҗалар арасында бер-берләреннән туйганлык, бер-берләрен яратмау барлыгы күренеп тора.

## С. Рәмиев иҗатында авылга мәхәббәт

Әй, авыл, син мең шәһәрдән
Мең кабат ямьле вә хуш, —

дип яза шагыйрь «Авыл» шигырендә. Шагыйрьнең авылның ямен, матурлыгын аңлавы бик үзенчәлекле: ул аны урамнарының тынлыгы һәм бушлыгында күрә.

Авылның караңгы төннәрен болытлы көнгә тиңли шагыйрь. Ни өченме? Минемчә, аны дөнья түрендәге бер якты почмак итеп күрсәтергә тели.

Шагыйрь безгә ай яктысында ачылган авыл матурлыгын аңлата. Төнге күктә балкыган тулы айны яшькелт төстәге кыйммәтле таш белән чагыштыра ул. Без исә айны ак, сары дип тасвирларга күнеккән.

28

Кыйммәтле ташларның нур сибеп балкуы табигый. Авыл ае да бөтен дөньяны балкыта. Урманнар, таулар, кырлар яктырып киткәндәй була.

Шагыйрь авыл турында язам дип уйласа да, шигырендә урамнарның, йортларның, бакчаларның тасвиры юк. Күз алдыбызга авыл кырлар иркенлеге, күкләр серлелеге, гөлле болыннар булып килә. Анда туган, яшәгән кеше күңеленә авыл, чыннан да, табигате белән кереп кала шул. Үзен тугайлары, урманнары белән яраттыра.

**Татар әдәбиятында Тукай образы**

*(Әхмәт Фәйзинең «Тукай» романы буенча)*

Ә. Фәйзинең «Тукай» романы — халык шагыйре турында беренче күләмле әсәрләрдән икән. Гадәттә, әсәр кайсы герой исеме белән аталса, шул герой вакыйгалар үзәгенә куелган була.

Сапый абзыйның өй кешесенә әйләнгән Габдулланың тышкы портретын Ә. Фәйзи менә шундый итеп тудыра: урта тирәсеннән билбау белән әйләндерелгән авыр бишмәт эченнән аптырап карап торган сабый. Чишенгәч, кулларын бер алга, бер артка селкеп йөреп китә ул.

Язучы әйткәннәрдән Габдулланың чит кешеләр янында бераз каушый торган булуы, үзен якын иткәннәргә ачылып китүе, белем алырга хирыслыгы, хезмәтчеләрне үз итүе аңлашыла.

Бераздан шәкерт Габдулланың үзе белән танышабыз. Ул инде гаделсезлекләрне күтәрә алмаучы, тирә-якка авырлык белән ияләнүче, бераз ялгызрак үсмер булып күренә.

Габдулла иптәшләренә кул күтәрүдән тапкырлыгы белән котылып кала, аларның хөрмәтен казана. Ул белемлелектә дә — беренчеләрдән.

Ә. Фәйзи Тукайның үз көче, үз тырышлыгы, үз мөмкинлекләре аркасында башкалардан аерылып чыкканын күрсәтә. Егет надан, холыксыз, укучыларына гадел мөнәсәбәт күрсәтмәгән Шәпеш хәлфәне яратмый, аңа карата башкаларның да күзен ачарга тырыша һәм аның белән конфликтка керә.

Без дәреслектә китерелгән өзектән генә дә кечкенә Габдулланың ничек итеп олыгая, белем, әдәбият дөньясына атлый баруын күрәбез.

29

**Хәсән Туфан шигырьләрендә чор сулышы**

Хәсән Туфан — озын гомерле шагыйрь. Ул революция, күмәкләштерү еллары, сугыш афәтләре һәм башкалар аша уза. Аны чор, халык кичергәннәр шагыйрь итә.

«Каеннар сары иде» шигыре сагыштан йөзе саргайган бала турында сөйләүдән башлана. Без әле бу хәсрәтнең сәбәбен белмибез.

Табигать тасвиры бала күңеленә аваздаш итеп тудырыла: гөлләр кыраулы, каеннар саргайган, көз җиткән. Димәк, бала күңелендә дә — көз. Суыкта шәлләргә төренеп утыра ул.

Аннан соңгы юллар әти кешенең сугышта булуын хәбәр итә, исән-сау дисәләр дә, күңелдә шик кала, чөнки аннан балага хатлар килми.

Бала, шкафка сугылган кызыл пичәтнең ни икәнлеген аңламаса да, күңеле белән үзеннән ишерелгән серләрнең ни хакында икәнлеген тоя. Аны шигырьне укучы да сиземли: бу бала ятимдер инде... Әсәрдә әни, әби, апа кебек сүзләр язылмагач, ул безнең алдыбызга тулы ятим кебек килеп баса.

Шагыйрь сабыйга, күбрәк кызларны назлап әйтелә торган сүз белән, гүзәлем, дип дәшә, әйтерсең, аның хәлен шул сүз белән җиңеләйтергә тели.

Бер караганда, Хәсән Туфан бу шигырьдә сугыш китергән ачыны сабый язмышы аркылы тасвирлый. «Сугышта йөри диләр...» кебек юллардан соң куелган күп нокта, шагыйрь язмышындагы кайбер вакыйгалар аның эчтәлеген безгә башкача да ача. Без аны тоткынлыктагы Туфанның үзе, кызы турындагы шигыре дип тә уйлыйбыз.

**Илсөяр миңа ни өчен ошады?**

*(Гариф Гобәйнең «Маякчы кызы» повесте буенча)*

Илсөяр — табигать кочагында үскән кыз. Ул ямьле Агыйдел буйларын таң калып күзәтә. Аның әтисен, бабасын яратканлыгы күренеп тора. Ул инде дөньяны аңлый, аны Кәмәш әби сөйләгәнчә генә күз алдына китерми.

Илсөяр әтисенә бертуктаусыз сораулар бирә: күп белергә тели. Кечкенә генә булса да, ишкәк ишә ул, партизаннарга, бабасына ярдәм итә.

30 Илсөярне тәмле телле, яхшы күңелле әти, бабай тәрбияләп үстерә. Ул начар була да алмый. Алар кебек үк, яманны яхшыдан аера, яхшылыкка шәфкатьлелек белән җавап бирергә тырыша.

Кызның исеме дә бик мәгънәле: илен сөюче дигән сүз. Эшләгән эшләре исеменең җисеменә туры килүен күрсәтеп тора.

Илсөяр олылар сүзен бик тыңлый. Алар кушканны җиренә җиткереп башкара. Әнә шундый сыйфатлары өчен бик ошаттым мин аны.

### «Йолдыз кашка турында баллада» да конфликт

*(Илдар Юзеевның шул исемдәге балладасы буенча)*

И. Юзеев балладалар остасы икән. Әгәр ул кешеләрне табигать предметларына, кош-хайваннарга охшата алмаса, табигатьнең үзен бөтенләй аңламаса, баллада яза да алмас иде.

«Йолдыз кашка турында баллада»ның геройларыннан булган елдым ат иярендә батыр генералны йөртә. Без аның хуҗасына бирелгәнлеген, сугыш вакыйгаларын аңлаганын күрәбез: ул фашист илбасарына буйсынмый, шуның аркасында аны тотарга теләгән дошман солдатлары белән конфликтка керә. Генералларга гына тиң торырлык ат булганга күрә, шагыйрь аңа, иясез калгач, инде немец генералының күзе төшкән итеп күрсәтә. Димәк, ул үзенә тиңнәргә каршы тора.

Шагыйрь атны агач, тимер белән чагыштыра. Гомумән, бу әсәрдә И. Юзеев тимер эпитетын күп куллана, чөнки ул — ныклык билгесе. Ат тимердән дә ныграк булып чыга: явызлар каршысында сынмый. Дөрес, алар аны шул ук тимер боҗра белән кысрыклыйлар, тимер ядрә белән аның гомерен өзәләр. Бу әсәрдә фашист солдатлары Йолдыз кашканы буйсындырырга алынган, аның хуҗасын үтергән, иленә басып кергән явыз көч булып тора. Немец генералы исә — туларның берсе. Без Йолдыз кашка кебек атларның да бик күп булганлыгын беләбез, шуңа күрә конфликт илен саклаучылар белән илбасарлар арасында бара дип тә әйтә алабыз. Аны Явызлык белән Яхшылык арасындагы конфликт дип тә билгеләргә мөмкин.

Үзенә хезмәт иткән ул-кызларын гына түгел, хәтта атларны да олылый икән халык. Йолдыз кашка узган юллардан аның хакында җыр ишетелә. Ул — аңа һәм сугышны аның белән бергә кичкән генералга һәйкәл һәм аларның бу сугышта өстен булып чыгу, җиңү билгесе дә.

**«Мәүлия нигә көлде?» әсәрен хикәяләүче**

*(Ибраһим Газиның шул исемдәге хикәясе буенча)*

Ибраһим Газиның «Мәүлия нигә көлде?» хикәясен сөйләүчене мин озак еллар буе Мәүлияләр гаиләсе белән аралашып яшәгән яисә аларның гаилә әгъзасы ук булган кеше итеп күз алдына китерәм, чөнки ул Мәүлия белән кечкенә чагында булган хәлләрне үк тасвирлый һәм аларны нәкъ үзе күргән кебек сөйли.

Хикәяләүче вакыйгаларга катнашмаса, аның хакында мәгълүмат булмаса, аны авторның үзе дип санайлар һәм ул җиткергән сүзләрне автор сөйләме дип бәялиләр икән. Укыган китапларымнан чыгып, мин күпчелек әсәрләрдә вакыйгаларны автор үз исеменнән җиткерә дигән фикергә килдем.

Минемчә, бигрәк тә балалар хакында язылган әсәрләрдә авторның геройларга, вакыйгаларга мөнәсәбәте ачык сизелеп тора. Борынгылар әйтмешли, алмагачның алмасы бик ерак төшми икән, ди язучы. Ә бит автор борынгыларның нәкъ менә Мәүлиягә туры килгән сүзен сайлый, шулай булгач, бу мәкальгә аның кыз хакында фикере салынган, әмма ул шуның белән чикләнә.

Байтак нәрсәләрне автор сөйләсә дә, аларны Мәүлия авызыннан чыккан кебек кабул итәбез, чөнки язучы кыз күңелендә туган уй-хәрәкәтне, башкаларга кычкырып әйтелмәгән сүзләрне җиткерә. Без, әйтерсең, Мәүлия белән бергә урам буйлап барабыз, әби булып күренгән бозауга сәлам бирәбез, бишле алып кайтып киләбез. И. Гази хикәяләүче сөйләмен геройныкы белән бергә кушкандай була, әнә шуңа күрә автор Мәүлия кебек уйлаган юлларына кызга карата мөнәсәбәтен кертеп җибәрә алмый, нәтиҗә чыгаруны укучыга калдыра. Минемчә, олы кеше акыл өйрәтеп язмаганга, гыйбрәтле итеп сөйләгәнгә күрә, шундый хорафатларга ышанучан балаларның да хикәяне укыйсы килеп торачак.

32

## Өч Мәхмүт

*(Ибраһим Газиның «Өч Мәхмүт» әсәре буенча)*

И. Газиның «Өч Мәхмүт» әсәре тормышта киң таралган күренешне тасвирлаудан башлана. Сыйныфта бер исем белән берничә кеше булдымы, аларның һәрберсенә кушамат тагасыларын көт тә тор! Без 6 Б ларның да бер иптәшләрен Кәтүк дип атаулары турында укыйбыз.

Укытучы булгач, Мәхмүт абыйның бәхете бар — кушаматсыз. Хәер, бик сирәк күренеш... Хикәяләүче малай башта аны иптәшләре һәм укытучы белән чагыштыра. Буе кечкенә, көче юк, мускуллары сизелми дә... Әмма Мәхмүтнең башкалардан бер өстенлеге бар (сөйләүче малай аны шуның өчен яратмый да!): бөтен сораугa җавап бирә ала ул.

Минемчә, Кәтүк Мәхмүт эшкә дә булдыра, чаңгыда да ярыйсы гына йөри, әмма иптәшләре генә моны күрергә, танырга теләми.

Укытучылары Мүтәй — Мәхмүт турында хикәят сөйләгәч, әллә өченче Мәхмүт улмы икән дип уйлап куйган идем, ялгышканмын. Аның хакында сөйләү башкаларга гыйбрәт бирү өчен кирәк булган икән.

Авыр сугыш елларында олылар белән бертигез эшли Мүтәй, солдатка да алына. Тормыш аннан бер дигән ир кеше ясый. Кайчандыр иптәшләре Мүтәй дип йөрткән малайның хезмәт укытучылары, спортчы гәүдәле укытучылары икәнлеге беленгәч, алтынчы сыйныфлар аптырап кала.

Өченче Мәхмүт исә хикәяләүче герой үзе булып чыга. Бу герой тора-бара үзгәрә, чын дуска әйләнә, иптәшен дә кушамат белән атамый башлый, әмма мактанчыклыгыннан гына котылып бетә алмый.

Минем үземә өч Мәхмүт тә ошады. Кешеләр, исемнәре бер үк булганда да, бервакытта да бер-берсен кабатламый.

## «Наил һәм Фаил» повестенда хикәяләүче герой

*(Ләбибә Ихсанованың шул исемдәге әсәре буенча)*

Л. Ихсанованың «Наил һәм Фаил» повестен бер сулыш белән укып чыктым. Аның хикәяләүче герое

Фаилне бик яраттым, чөнки ул, шәһәрдә үссә дә, безнең авыл малайларына охшаган. Тикшермәгән, кызыксынмаган нәрсәсе юк! Үзе шук, үзе шаян, үзенең укуга әллә ни исе китми, әмма эчендә бернинди начарлык та йөртми. Аңа бәйләнмәсәләр, дөньясы ал да гөл! Әләк-чәләкне яратмый, андыйлардан үчен дә ала килә.

Әнә шул беркемнән курыкмаган Фаил Сәвия каршысында җеби дә төшә. Аңа Сәвиянең бөтен кыланышлары ошый. Әллә ул бераз Светлананы да ярата микән? Аның хакына «фокус»ын туктатырга ризалаша ич!

Еш кына орыш алса да, Фаил начар малай түгел. Башкалардан аерылып торасы, кызларны яраттырасы килгәнгә, укуда бик үк алда бармаганга гына, төрле эшләр эшләп ташлый бит ул!

## Р. Миңнуллин шигырьләрендә лирик мин

Р. Миңнуллинның без укый торган шигырьләрнең исеменнән үк сүз лирик миннең игътибар үзәгендә булачагы аңлашыла. Әлеге атамалар лирик мин әйтергә теләгән төп фикерне чагылдыралар. Аның бер герое: «Энекәш кирәк миңа!» — дип әйтсә, икенчесе батырлык эшләргә теләк белдерә, өченчесе эт турында хыяллана. Болар алдан ук аңлашылгач, шагыйрь нәрсә турында язар инде дип уйлыйсың.

Юк, иҗатчы сүзгә керми. Лирик миннең тәүгесе булачак энекәшенең тышкы кыяфәтен сурәтләсә, икенчесе үзе күргән этне сыйфатлый, өченчесе батырлык эшләр юллар эзли.

«Батырлык эшләр идем» шигыре «Әни мин көчек күрдем»нән шаянлыгы белән аерылып тора, аның лирик герое да бераз мактанчыграк, бераз беркатлырак һәм әле шактый кечкенә бала булып күз алдына килә.

Энекәш теләгән малай да, елап торган этне кызганган сабый да киң күңелле, ялгызлыкны яратмый торган балалар дип уйлыйм мин. Эчтәлекне безгә җиткергән геройлар үзләрен әнә шундый итеп таныта.

## Р. Миңнуллин шигырьләрендә юмор алымнары

Төрлечә көлдерергә була. Кайвакыт, көлдерсәләр дә, кызыгын тапмыйсың. Р. Миңнуллин язганнардан, кәеф килгәндә, рәхәтләнеп көләм мин.

34

«Әйбәт тә минем әби!» шигырен укыганда, башта бер дә кызык тоелмады, чөнки безнең әбиләребезнең ярдәмче булуы, һәр эшкә осталыгы сер түгел. Алай да, малайның мактануы күпкә киткәч, төймә тагу, ертык китапны ябыштыру бу укучының үзенең кулыннан да киләдер инде, дибрәк уйланасың.

Бераздан әбинең бары тик малай-шалай ваткан-җимергәнне генә төзәтүе беленгәч, хәл көлкерәк күренә башлый.

Лирик герой аның саең арттыра: инде мәктәпкә әбисен генә йөртергә дә риза.

Соңгы строфа, чыннан да, бу әбинең башкалардан яхшырак икәнлеген раслый. Хикәяләүче геройның бөтен китаплары да сумкасында килә, ә менә «әбисез» малайлар оныткалый. Шигырьнең иң күңелле җире — аның нәтиҗәсендә. Кычкырып көлдермәсә дә, аның яшерен мәгънәсе бик кызык, дөресрәге, сабак бирә торган.

## Мин сезгә яраткан героем турында язарга телим

*(Чыңгыз Айтматов иҗаты буенча)*

Һәркемнең беренче мөгаллиме була. Ул бар кешедән дә матуррак, акыллырак, сине генә яратадыр, сине уйлап йокыларга китә алмыйча ятадыр кебек тоела. Әмма укытучылар, чынлап карасаң, бер-берсенә бөтенләй охшамаган ич! Мөгаллимгә хас балаларны ярату аларны синңа изге кеше итеп күрсәттерәдер инде.

Чыңгыз Айтматов иҗат иткән Дүшән образында да без белгән укытучыларга охшаш сыйфатлар бар: башкаларга үрнәк булырдай яши, җанын балаларга бирә, көне авыр хезмәттә үтә. Ул начарлык эшли дә белмидер шикелле.

Барлык укучыларга охшаш булган өчен, Дүшәнне аңларга, якын итәргә мөмкин. Ярату өчен, кешенең башкаларга охшамаган сыйфатлары булу да кирәк.

Дүшән — безнең заман кешесе түгел. Ул — күпчелек халкы укый-яза белмәгән җылы якныкы. Укытучылыкка укымаган булса да, башкалардан белемлелеге белән аерылып тора. Дала кешеләре арасында ул сәер бер җан булып күренә. Аларның үзләренә бигрәк тә шулай. Авыл халкы күңелендә өмет-ышаныч уяткан беренче

мөгаллим әкренләп үзен яраттыруга, белемнең кирәклеген аңлатуга ирешә.

Гап-гади бер укытучы далада үскән, җәберзолым күргән кызга зур юллар ача. Алтынай академик дәрәҗәсенә ирешә. Мин Дүшәнгә Алтынайга киләчәген күрсәтеп бирә алган өчен гашыйк.

# VII сыйныф

<u>ГҮЗӘЛ ГАМЬ</u>

**«Җир шарын васыять итик балаларга!**
**Сакласыннар, олыларның ышанычын акласыннар!»**

*(Н. Хикмәт)*

Назыйм Хикмәт шигыренә тирән мәгънә салынган. Монда сүз Җир язмышының киләчәктә бүгенге буыннар кулына калачагы турында бара.

Буын арты буын алмашына. Аларның һәрберсенең — үз холкы, үз яшәү рәвеше. Шул ук вакытта әти-бабаларның гамәлләре, уй-фикерләре дә еллар аша киләчәккә уза. Бу гамәл һәм максат-теләкләргә мин сугышларсыз яшәү, табигатьне саклау, кешеләр сәламәтлеген кайгырту, халыкның мәдәниятен үстерү һәм башкаларны кертәм.

Шигырьдә сүз олыларның балаларга ышаныч күрсәтүе хакында бара. Баласының тәрбия дәрәҗәсен белгән ата-ана гына аңа ышаныч күрсәтә ала. Әлбәттә, безнең арабызда халкыбызның гасырлар дәвамында формалашкан гореф-гадәтләренә туры килмәгән гамәлләр кылучылар да бар. Кече яшьтән үк аракы эчкән, тәмәке тарткан, белем алуда һәм эштә гаме булмаган укучылар юкмыни?! Шунысы сөендерә: алар әлегә күпчелек түгел.

Казанның мин укыган Ш. Мәрҗани исемендәге икенче гимназиясендә аерып күрсәтерлек бер генә тәртипсез бала да юк. Минем сыйныфташларыма әти-әнине тыңламау, тәмәке тарту кебек шөгыльләр — бөтенләй ят нәрсә. Татар иленең киләчәге әнә шундый яхшы мәктәпләрдә укыган, милли телдә белем алган, халкын сөйгән балаларда булсын иде дип телим мин.

Милләтпәрвәр дусларым сәнгатьне дә үстерәчәк, халыкның тормышын да кайгыртачак, мәгънәсезгә алып барылган сугышларга да каршы төшәчәк, табигатьне бетерүгә дә юл куймаячак. Н. Хикмәт тә әнә шундыйларга ышаныч белдергәндер кебек тоела миңа.

## Мин сезгә яраткан шагыйрем турында сөйләргә телим

Сез Рафис Корбан исемле балалар шагыйрен беләсезме? Аның хакында ишеткән булу гына әле белү дигән сүз түгел. Рафис Корбан — минем яраткан шагыйрем. Мин аның нәкъ менә балалар өчен язган шигырьләрен яратам. Әйдәгез, бергәләп аның иҗатына сәяхәт итик.

Алдымда — «Куркуын җиңгән куян» китабы. Менә шул җыентыкка, мин нәрсә турында уйласам, Рафис абый да шул турыда язган. Мин бәйрәмнәр яратам, чөнки ул көнне тәмле әйберләрне дә кызганмыйча ашаталар, бүләкләр дә бирәләр. Шагыйрь дә шулай ди.

Аның бу китабындагы шигырьләре күбрәк сабыйлар өчен. Мин, аларны укыганда, үзем дә сабый булып калам. Җиләклектә туйганчы җиләк сыптырам, бакчада гөлләр арасында йөрим.

Рафис абый безнең кебек бала-чаганың бөтен кызык якларын күреп алган. Каюмның, аю-бүредән куркып, урманга бармавыннан көлә ул бер шигырьдә һәм аны куркак куян белән шул рәвешле чагыштыра:

Куян — куркак,
Диләр дә,
Курыкмый бернидән дә,
Шул урманда тора бит,
Үзе куян гына бит.

«Авыл исе» шигыре дә бик ошый миңа. Чыннан да, җәйге авыл шомырт, җиләк, юкә чәчәге исләре белән үзенә тартып тора. Җәйләрен анда кайтмаган кеше, бәлки, аны аңламыйдыр да. Ә мин — нәкъ шагыйрь язганча:

Мин шәһәргә үзем белән
Төяп киләм авыл исен.

Мин шагыйрьләрдән шигырь язарга өйрәнәм. Бу образларны, бу сүзләрне найлардан гына табып бетерделәр микән дип шаккатам. Кышкы кырның йокыга талуы турында кем генә язмаган! Рафис абый исә безгә шул ук нәрсәләрне инде башка сүзләр белән җиткерә:

Ужымнар калын
Юрган астында
Тирән йокыга
Талды барсы да.

Ул тузганак агын койган фасылны кыш белән чагыштыра, чыпчыкның миләш ашавын витамин икәнен белгәнгә дип шәрехли. Сабыйларны, шулай итеп, Рафис абый дөньяны аңларга, аның матурлыгын күрергә өйрәтә.

### «Киләчәге бар милләт без, Шәхесләргә бай милләт без»

*(Г. Саттар-Муллиле)*

Шәхесләр турында сөйләргә куштылармы, сыйныфташларым Тукай, Җәлил, Сәйдәш, Туфан һәм башкалар турында сөйли башлый. Аларның күпчелеге язучы яисә артист, рәссам, композитор булып чыга. Ә бит милләтем танылган физикларга, табибларга, конструкторларга һәм башкаларга да бик бай. Татарлар Берлинга Җиңү байрагын кадаганнар! Хәер, тарих бу фактны күрмәскә тырыша.

Шәхесләр сәнгатьтә, фәндә генә булмый. Безнең тирәягыбызны бик күп үзенчәлекле кешеләр чорнап алган. Йортыбызда Роберт бабай исемле бер кеше яши. Аның әтисе «Аврора» крейсерында хезмәт иткән! Шәхес культы елларында, карт булса да, аны Колымага сөргәннәр, һәм ул шуннан кире кайтмаган.

Роберт абый үзе дә сугышта катнашкан. Орден-медальләре бик күп. Сугыш турында ул сәгатьләр буе сөйли ала! Яшүсмер генә булганлыктан, һәр нәрсә аның хәтерендә бик тирән уелып калган. Ул немецларның ату коралларын бик яхшы белә, үзләре узган шәһәрләрне, урман-сулыкларны да яхшы истә калдырган. Андый кешеләрне аяклы тарих дип атыйлар.

Роберт абыйның бүгенге көнгә дә үз карашы бар.

Шәхес культы елларының зур авырлыкларын кичерсә дә, ул совет системасын сагына. Мин бушка укып кеше булдым, илләр күрдем, каты яраланган булсам да, дәвалап терелттеләр, Совет иленә рәхмәт, ди.

Роберт абый көймә модельләре ясау белән шөгыльләнә. Кичләрен керсәң, сине дә эшкә катнаштыра. Аларның китап шүрлекләрендә модельләрнең нинди генә юк! Үзең аңа булышасың, үзең аның гомерендә очраган маҗараларын тыңлыйсың. Менә ичмасам шәхес! Ә андый шәхесләр безнең тирә-ягыбызда бихисап.

## Яшә, Казаным!

Казан! Мең ел сиңа!
Нәкъ ун гасыр аша
Атлап киләсең син.
Һәрбер алсу таңда
Таңгөл атлы кызга
Сәлам бирәсең син.

Казан! Казаным! Туган илемнең алтын пайтәхете. Башкалаларның башкаласы да син, балачагым бишеге дә син, Казан!

Кеше кайда гына туса да, үзен шул җирнең кадерлесе, кирәклесе итеп тоя. Татар булып дөньяга килгәч, үзен башка милләт баласы итеп күз алдына да китерми. Бары тик үз әтиең, үз әниең генә синеке була алган кебек, туган җиреңне, илеңне, башкалаңны да сайлый алмыйсың.

Шул ук вакытта ком сахраларын дөядә кичсәң дә, карлы тау башларында көтү көтсәң дә, карлы Себер киңлекләрендә болан җиксәң дә, Австралия далаларында сарык асрасаң да, мин айда яшәр идем, мин диңгездәге бер утрауда торсамчы, бай бер америкалы булсамчы дип хыялланмыйсың. Үз илеңдә, үз кешеләрең арасында бәхетле буласың, бай да яшисең, белем дә туплыйсың килә.

Әлбәттә, Туган иленең кадерен белмәгән, үз милләтен санга сукмаган кешеләр дә очраштыра. Алар, я дөрес тәрбия алмаганга, я әниләрен яратмаганга, я тормышта гел кыерсытылганлыктан, дөньяга рәнҗегәнгә генә,

Туган илен башкаларга алмаштырыр хәлгә киләдер.

Мин менә яшәвемне татарларның баш шәһәре булган Казаннан читтә күз алдыма да китерә алмыйм. Ул миңа киң урамнары, ял парклары, театрлары, музейлары белән ошый. Казанның һәр җирендә тормыш кайный, эш һәм ял бергә үрелеп бара.

Моннан йөз ел, мең ел элек тә таш кала гөрләп торгандыр. Көн дә, мәктәпкә барганда, эшкә күмелгәндә, син бу хакта бик уйлап та бетермисең. Атна арты — атна, ел арты ел уза. Ә менә, әз генә вакыт табып, берәр кая барып чыксаң, Казанның тарихи шәһәр, истәлекләр шәһәре булуы хакында уйланасың.

Җәйләрен әнием белән Яшьләр Үзәге тукталышы янындагы комлыкка су коенырга йөрибез. Казансу шәһәребезнең нәп-нәкъ уртасыннан ага! Каршы якта — Кремль диварлары, Сөембикә манарасы, мәчет урынына салынган чиркәү... Һәрберсе тарихи вакыйгаларга алып чыга. Бу корылмалар Казан ханлыгы чорыннан калган, аннан соң бераз үзгәртелгән. Диварларның тышкы ягы җәйләрен һәрвакыт актарылган була. Студентлар, танылган археологлар казу эшләре алып баралар анда.

Кайбер галимнәрнең әйтүенә караганда, табылдыклар Казанның мең елдан да озынрак гомерле булуы хакында сөйли икән! Әйе, бер генә шәһәр дә бер көн, бер ел эчендә төзелә алмый. Ул киңәйгәнче, төрле зур биналары калыкканчы, берничә йөз, хәтта мең еллар узарга да мөмкин бит.

Элекке заманнарда үзгәрешләр хәзерге кебек тиз бармаган. Бәлки, Казанның хәтта зур шәһәргә әверелүенә дә мең генә ел түгелдер. Мин киләчәктә башка милләт галимнәре дә чын дөреслекне таныр, аның яшен тагын да зуррак күрсәтер дип өметләнәм.

Казанның меңъеллыгына Кремль эчендә бик гүзәл бер мәчет калыкты. Аны Колшәриф мәчете дип йөртәләр. Казан ханлыгында шундый исемле бер галим, рухани яшәгән. Ул барлык руханиларга да баш булган, сәет дәрәҗәсен дә йөрткән. Аның бай китапханәсе, ул хезмәт иткән мәчет Казанны алу вакытында җимерелгән. Патшасы да, сәүдәгәре дә, илчесе дә Колшәриф

белән киңәшкән. Сөембикә-ханбикәнең дә иң якын кешесе саналган ул. Ватанны саклар өчен, кулына корал алган рухани алдында без бүген дә баш иябез.

Кремль диварлары, тирә-ягы гел төзекләндерелеп тора. Соңгы елларда аның әйләнәсендәге болынлыклар элек-керәк вакытына охшатылып киңәйтелде, Колшәриф мәчетенең күренеше ачылды. Янәшәдәге цирк бинасы да үзенчәлекле кыяфәт алды.

Ял көннәрендә без театрларга, музейларга йөрибез. Аларның исемнәре татарларның танылган шәхесләрен искә төшерә. Әйтик, Галиәсгар Камал, Кәрим Тинчуриннар атаклы драматурглар булганнар. Габдулла Тукай, Шәриф Камал, Каюм Насыйри кебек атаклы каләм ияләренең дә музейлары бар Казанда.

Башкаланың иң чиста, иң матур урамын Кремль урамы дип йөртәләр. Монда Казан дәүләт университеты, Дәүләт музее бинулары бар. Бер башына — Җәлилгә, икенче очына Ленинга һәйкәл куелган.

Казанда уку йортлары әллә никадәр! Мин аларның барысының да исемнәрен дә белеп бетермим. Барлык спорт сарайларында, кинотеатрларда да булганым юк. Әнием мине зоопаркка, Горький исемендәге ял паркына, аэропорт һәм башка җирләргә алып барды. Минем тимер юл вокзалының Кызыл бинасында, Педагогия университетында, Күргәзмә залында, Казан ярминкәсендә һәм Актерлар йортында булганым бар.

Казанның тирә-ягы да бик матур. Без Аккош күленә якын яшибез. Еш кына ял көннәрен шунда уздырабыз. Анда бик чиста күлләр, сәламәтлек лагерьлары, язучыларның җәйге йортлары бар. Халык күп йөргәнгә, урманында гөмбә, җиләк бик аз җыела, аның каравы, матур-матур чәчәкләрдән гөләндәм тупларга була.

Шәһәр ыгы-зыгысыннан, тавышыннан арынып торгач, көч туплап, инде мәктәбеңне, өеңне сагынып, шул ук вакытта рәхәтлек бирә торган ару белән арып, син тагын Казанның үзәгенә кайтып керәсең. Сиңа тагын ерактан Кремль карап тора. Таныш йөзләр, күршеләрең көтеп алгандай күренә.

...Казанның бүгенгесе дә аның меңъеллык тарихына керә. Су буенда калыккан зур йортлар, Милли-мәдәни

үзәк, Ирек һәйкәле хакында да бервакыт әллә кайчан төзелгән биналар кебек сөйләрләр.

Мин, *әллә* ничә гасырлар узгач та, татар милләтенең бетмәвен, Казанда татарча җырлар яңгыравын, татар театрларының эшләвен телим:

Казан! Мең ел сиңа!
Тагын, картаймыйча,
Миллион еллар узсын.
Бер-бер алсу таңда
Башка исемле кыз
Сиңа кулын сузсын.
— Бу бит — минем туган,
Торган, үскән җирем.
Татар иле! — дисен.

## Мин сезгә үземнең яраткан әсәрем турында язарга телим (I)

Н. Гыйматдинованың «Сихерче» повесте кеше-табигать мөнәсәбәтләрен тасвирлаучы әсәр буларак бәяләнергә хаклы. Аның хакында сихерчеләр һәм сихерчелек турындагы повесть дип гадиләштереп фикер йөртү хата булыр, шул ук вакытта әсәрдә бу темаларның барлыгын инкарь итү дә дөреслеккә туры килми.

Кеше-табигать мөнәсәбәтләренә бәйле рәвештә, повестьта мәхәббәт, яшьлек, дуслык, күршелек, гаилә, авыл һәм колхоз тормышы кебек темалар да яктыртыла. Повестьта бихисап мәсьәләләр күтәрелә. Алар — бала тәрбиясе, эчкечелек, ил, җир белән идарә итү, ир-хатын арасындагы мөнәсәбәтләр, кеше бәхете, табигатьне, рухны чиста саклау кебек мәсьәләләр ул.

Газета-журналларда «Сихерче» повесте хакында язмалар дөнья күргән иде. Минем повестька карата мөнәсәбәтем башкаларныкыннан шактый аерыла булып чыкты, бәлки, ул Әдибәнеке белән дә туры килмидер.

Кайвакыт яраткан язучың, әсәрең фикерләре белән килешеп тә бетмисең. Бу әсәрне укыгач та, шулай булып чыкты. Н. Гыйматдинова үз әсәрендә сихерчелек, им-томчылык Алладан бирелгән эш дип расларга маташа. Дин күзлегеннән караганда, шуның белән зур гөнаһ эшли. Сихер белән шөгыльләнү, йолдызлар ярдәмендә

фаразлау ислам динендә ярамаслык эш бит ул. Дөрес, безнең динебездә Аллаһе Тәгалә ярдәменә, изге сүзгә, дару үләннәренә таянып, кешеләргә шифа итү начар дип саналмый.

Әдибәнең дөнья бетү турында фаразларга алынуы, кешеләрнең җаннарын «алмаштырып» уйнаулары да дини кысаларга сыешмый. Сихер турында язганда, аны мәҗүсилек, табигать белән бәйләргә була, әмма һәрдаим бу эшләрне Бөек көч ярдәмендә башкарыла итеп күрсәтү — чын мәгънәсендә, дәһрилек дип уйлыйм мин.

Карчык, Сәвилә — кануннар белән яши алмаучылар. Алар дини кысаларда да яши алмый. Кием, сүз, яшәү тәртибе — һәр нәрсә буа бу ике сәер җанны. Алар үзләренә каршы төшкәнне үтерә, чирләтә ала. Яратсалар, ни өчендер табигатькә каршы баручыга да зыян салмыйлар.

Язучы җәмгыять кануннарына буйсынмый яшәүне бертуктаусыз мактый. Кануннар җинаятьчеләр өчен генә кирәк дигән фикердә тора. Һәр кеше укытучыны санламаса, шул ук табигатькә дә зыян тагын да күбрәк салыначагын онытып җибәрә аның Сәвиләсе. Н. Гыйматдинова үзен аның прототибы дип таный. Ир-атка, дөньяга карашы аныкы белән туры килә дип исәпли, шунлыктан аның һәр әйткәне әдибәнең үзенеке дип кабул ителә.

Әдибә, табигатькә якын хәлдә, бер-береңә ярашып, санлашып яшәү проблемасын күтәрсә, гаделрәк булыр иде шикелле.

Әсәрнең үзәк геройлары — җәмгыятьтән читкә китәргә газапланган затлар. Аларның үзләрен кешеләр арасында ят итүләре табигый. Тормышта үтә бәхетсез бу кешеләрнең башкаларны бәхетле итәчәге нигәдер бик үк ышандырмый. Сихер чын ярдәмче түгел.

Сәвиләнең яшәү рәвеше апасын күршеләре белән низагка кертә. Ул Тәминдар гаиләсен болгата, башкалар арасында да гел ыгы-зыгы тудырып тора. Бака күмеп, дәрескә соңга кала. Яраткан укытучысын, үзен аңларга тырышкан Тәминдарны башкалар алдында көлкегә калдыра.

Әлбәттә, әдибәнең нияте изге: ул Сәвиләне табигатькә якын дип күрсәтергә, табигать телен аңлаган саф күңел-

ле кыз образын иҗат итәргә тырыша. Шул күңелдә туган мәхәббәтен укучыга илтеп җиткерергә омтыла. Ул шундый килеп чыккан да, әмма бер үк вакытта бу героиняга үтә тупаслыгы, дорфалыгы, якыннарының кадерен белмәве зур зыян сала.

Минем дә мөнәсәбәтем кайвакыт аның сөйгәне Тәминдарныкы кебегрәк: ни өчен болай кылануын аңлыйбыз да, тик кабул итә генә алмыйбыз. Татар кызының тупаслыгын, әрсезлеген күрү авыр. Ник бу изге булырга тиеш образга гаиләле ирне яратуны йөкли инде язучы, дип уйлап куясың.

Кешеләрне, дөньяны яктыртырга, дәваларга бурычлы бу кыз ник Тәминдарлар гаиләсен ныгытмый, ир-хатынны бер-берсенә якынайтмый, дисең. Язучы җәмгыятькә аның яхшылыклары аңлашылмый дип әйтергә тели. Ә бит сәбәбе — Сәвиләнең үзендә дә. Ул бервакытта да башкаларга якынаерга, аларга ачылырга теләми.

## Мин сезгә үземнең яраткан әсәрем турында язарга телим (II)

Мин сезгә Н. Гыйматдинованың «Сихерче»се турында язарга телим. Соңгы елда укыган китапларым арасында күңелгә аннан да ошаганрагын тапмадым.

Әсәрне укыгач, күңелемнән аңа анализ ясадым. Башта геройларны төркемләп чыктым һәм алар арасында тискәреләренең өстенлек итүенә таң калдым! Мин үзәк образ Сәвиләне әдибәнең үз әсәрләрендәге һәм башка әдәби үрнәкләрдәге геройлар белән чагыштырып карадым, башка язучылар тудырган геройлар арасыннан әлеге кызга охшаганнарны эзләдем.

Холык сыйфатлары, яшәү рәвеше белән Н. Гыйматдинова геройлары Ф. Бәйрәмова образларына якын тора дигән фикергә килдем. Сәвиләнең — «Болын» повестендагы Алсу, Тәминдарның Алмаз белән уртак якларын күрдем мин.

Алсу белән Сәвилә хакында гына әйтеп узыйк. Аларның икесендә дә берничә төп сыйфат бар. Болар: гади кешечә яшәүдән тәм тапмау, кануннарга буйсына алмау, табигатькә якынлык, шәхси бәхеткә ирешү теләгенең көчлелеге, кешеләр белән мөнәсәбәтләрне җай-

лый белмәү. Табынган кешеләрендә алдану һәм башкалар. Шул ук вакытта Алсу камиллеге, рухи матурлыгы белән ныграк сокландыра. Аның уйлары, күңеле бик якты. Әсәр ахырында ул караңгылыктан чыгу юлын таба: авылга балалар укытырга кайтып китә. Иң кадерле кешеләрен соңлап булса да аңлый. Сәвиләдә исә Тәминдарсыз калудан үкенү хисе күзәтелми.

Сюжет, образлар эшләнеше нинди генә булмасын, Н. Гыйматдинова уздырган фикерләр, безнең карашыбызча, нигездә, бик актуаль яңгырашлы һәм уңай. Боларга түбәндәгеләрне кертергә мөмкин:

— кеше — табигать баласы, аның эчендә, аңа хезмәт итеп, үзенә дә зыян салмыйча яшәргә тиеш;

— мәхәббәт — бөек хис, ул тормыш ваклыклары белән түбәнгә төшерелмәсен;

— кеше җаны — карурман, аңа узу кайвакыт мөмкин дә түгел;

— авыл, колхоз белән белемле, кешелекле, табигатькә якын торган кешеләр җитәкчелек итәргә тиеш;

— эчкечелек — кеше шәхесен таркатучы сәбәпләрнең берсе;

— гаилә, мәхәббәткә нигезләнсә генә, нык була;

— кеше иреге — бар нәрсәләрдән дә өстенрәк һәм табигатьтән бирелгән хис.

Әсәрдә уздырылган фикерләр болар белән генә чикләнми, әлбәттә. Шулар арасыннан Әдибәнең халыкның табигать ярдәмендә дәвалануны белмәве һәм совет медицинасы чирле кешегә ярдәмсез кебегрәк фикерләре белән килешеп бетмәдем.

### Мин сезгә үземнең яраткан әсәрем турында язарга телим (III)

Н. Гыйматдинованың «Сихерче» повесте тәмам сихерләде мине! Теленең шигърилеге, образларының кызыклыгы! Сәвилә белән Убыр гына ни тора!

Бөтен нәрсәдән дә бигрәк Сәвиләнең бу заман кызларына һич кенә дә охшамавын яраттым. Үзе теләгәнчә яши, беркемгә иярми, табигать серләрен белә, чын-чынлап ярата, авырлыклар алдында сыгылып төшми.

Безнең бөтен тирә-ягыбызны сихерчеләр, экстрасенс-

лар, фаразчылар чорнап алган, әмма туларның берсенә дә ышанмыйм мин. Ә менә Сәвилә башкарган эшләргә ышандым. Монда әдибәнең язу осталыгы сизелә. Ул үзе тудырган геройларны яраттыра, алар өчен кайгырта белә.

Хатын-кыз Әдибәләрнең күңелгә үткәреп язулары сер түгел. Н. Гыйматдиновага да хас бу сыйфат. Әйтерсең, ул үзе — Сәвилә. Хәер, Убыр хакында укыганда да, авторны аның белән бер итеп күрә башлыйсың.

Әсәрнең төп фикере һәркемгә ачык: кеше табигатькә якын булырга тиеш. Үзен аңламаганнарны, үзенә каршы баручыларны табигать кайгы-хәсрәт китереп, чирләр биреп җәзалый. Юк, кеше үзенә шул җәзаны үзе сорап ала! Табигатьне аңламаган кеше бер-берсен дә аңламый, яшәүдән кызык тапмый, чын бәхет хисен кичерми.

### «Көйнең, телнең, гореф-гадәтләрнең
### Бар уз моңы, бар үз хисләре»

*(И. Юзеев)*

Моң сүзе татар телендә генә бар диләр. Бу халыкның моң-хәсрәтне чиктән тыш күп кичергәнлегенә бәйледер.

«Ялгызың гына җырлап утырма, моңлы бала булырсың», — диләр кечкенә чагында. Кеше моңның сәбәбен нечкә күңеллелек, кайгы-хәсрәт белән бәйли булып чыга түгелме?

Кычкырып җырлама, әдәпсез күренерсең, диләр, бераз үсә төшкәч. Бу гадәтнең барлыкка килүенең дә үз сәбәбе булгандыр. Син бар дөньяңны онытып шатланганда, икенче берәү авырып ятса, начар хәбәр алган булса? Авыл халкы әнә шуларның һәрберсе хакында бүген дә уйлый.

Мәҗлесләрдә күмәк җырлауны яратсалар да, ирле хатыннарның, яшь кызларның аерым гына, кеше каратып җырлавын да бик ошатып бетермиләр шикелле әле һаман да. Шуңамы, сүз тыңлатып, кемне дә булса җырлату еш кына мәҗлес алып баручының да кулыннан килми.

Аның каравы, сабыйларның килгән кунак алдында җырлавын, шигырь сөйләвен бик яраталар. Кеше картлысында осталыгын күрсәттерәләр дә тиз генә чыга-

46

рып җибәрәләр үзен. Татар өйләрендә чит кеше янында бәләкәй балалар табынга утырмый. Дөрес, гореф-гадәтләргә йөз чөереп караучылар, аларны санга сукмаучылар да бар. Бу аларның балалары әхлагында бик тиз үзен күрсәтәчәк.

Татар табыннарында төрле җырлар җырлана. Күңел күтәрә торганнары да, моңлылары да... Яшәү гел сөенечләрдән генә тормагангамы, күңелле бәйрәмнәргә дә сагыш җырлары килеп керә. Бер карасаң, аның да сәбәбе бар. Андый бәйрәмнәрдә кешеләр үзләренең беренче сөйгән ярларын, югалткан туганнарын искә төшерә. Алар белән бергәләп дөнья шаулаткан көннәрен искә ала.

Әбиләр күбрәк мөнәҗәт көйлиләр. Мин үзем сәхнә түрләреннән дини эчтәлекле җырлар башкаруны өнәп бетермим. Артист башкаруындагы мөнәҗәтне радиодан үзең генә калып, аның белән бергә моңланып, кушылгалап та тыңлау ошыйрак төшә.

Җырның моңы сүзләренә бәйле, эчтәлеге күбрәк узган тормышыбызны чагылдыра, ә үткән көннәребезнең төрлесе булгандыр. Җырларыбыз да шуңа күрә төрле-төрле.

<u>ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ</u>

## Сөембикә турында уйланулар

Мин Сөембикә язмышы, аның ничек итеп патшабикә булуы, коллыкка алынуы һәм башкалар турында еш уйланам. Кремль эчендә аның исемендәге манара, «Сөембикә» исемендәге журнал, аның хөрмәтенә уздырылган бәйгеләр дә бу олы шәхеснең күңелдән җуелмавына китерә.

Бүгенге көндә Сөембикә турында төрле фикерләр йөри. Аның исемен тапларга тырышканнарына да очрарга туры килде. Минем уемча, халык хәтерендә ул изге аты белән саклана икән, милли символ булып тора икән, Сөембикәне каралтуга юл куймаска кирәк. Милли көрәшкә әйдәп, безнең арабызда яшәсен ул.

«Сөембикә бәете»н «Казанны алган көй»гә җырлыйлар. Бу эчтәлеккә салынган хәсрәтне тагын да көчәйтә шикелле.

47

Бәет Сөембикәнең үзе турында сөйләве белән башлана, шунлыктан ул зур ышандыру көченә ия. Без аның мең биш йөз унбиштә дөньяга килүен, кайгысыз үсүен, дәүләтле нугай морзасы кызы икәнлеге хакында укыйбыз, әмма ул юлларда ук инде дәүләтне югалтачагына, кайгы-хәсрәт кичерәчәгенә ишарә бар кебек.

Бәеттә тудырылган Сөембикә белән тарихи Сөембикә арасында зур аерма бар, әсәрдә халык аны үз идеалларына туры китереп иҗат иткән. Ул башта — үтерелгән ире Җангали, аннан соң Сафагәрәе өчен ачы хәсрәт кичерә.

Сөембикә сәясәтне яхшы белгән хатын-кыз кебек фикер йөртә. Ул сугышлар сәбәбе, морзалар аркасында өзелгән солыхлар, җитәкчелек итү авырлыгы, сарай ыгы-зыгылары турында сөйли.

Сөембикәнең хан кабере өстенә манара салдыруы яңа сугышларга китерә. Әсәрдә ханбикәнең көндәшләре, аның, морзалардан аермалы буларак, Мәскәү белән килешү төзергә теләве турында да сүз бара. Мин бераз аптыраешта да калдым: чынлыкта да, илне җимертмәү хакына, Сөембикә русларга буйсынуны яклаганмы, әллә бу — халык уйдырмасы гынамы — тарихи китапларны укымый торып, моңа гадел җавап биреп булмас.

Сөембикә үзенең Мәскәүгә коллыкка озатылуында да кенәзләрне гаепли. Шул ук вакытта инде ул Казанның таҗсыз калуына чиксез кайгыра башлый.

Сөембикәне рус патшасы тагын кияүгә бирә. Шул чак ул үзенең көндәшенең аның «ир кайгыртып китү» турындагы сүзләрен искә төшерә. Бүген Сөембикә турында чыккан начар гайбәтләрнең нигезе әнә шул хатын-кызлар арасында була торган көндәшлеккә дә барып тоташа ала дип санадым мин.

Сөембикә үзен коллыка җибәргән морзаларның язмышы да аянычлы булуы, илне сатучы Шаһгалиләр дә барлыгы, аларның туган халкын басып алып баюы турында да әйтә.

«Сөембикә бәете»нең ахырында Үтәмешкә алты яшь тулу, аның фани дөньядан китүе турында юллар бар. Шуннан чыгып, әсәрнең иҗат ителү вакытын төгәл әйтү авыр түгел. Сөембикә әле исән, кайгы-хәсрәтенең чиге юк.

Бәет безне ерак тарихка, анда сөйләнгән шәхесләргә алып китә. Баласы диненнән чыгарылган, үзе иленнән аерылган, яратмаган иргә кияүгә бирелгән, соңгы гомере ачык билгеле дә түгел Сөембикә турында уйлыйсың. Бу көнгә кадәр тарихчыларыбызның каберен дә төгәл ачыкламаулары өчен, аның каршысында читенсенү хисләре дә кичерәсең.

## ӘДӘБИЯТ

### «Каюм Насыйри уз халкының һәм үз чорының улы булган»

*(Н.К. Дмитриев)*

Каюм Насыйри 1825 елның 2 февралендә хәзерге Яшел Үзән районының Югары Шырдан авылында дөньяга килгән. Әтисе атаклы мулла булгач, шәкертләр тәрбияләгәч, күрәсең, ул да аның юлыннан киткән, мөгаллимлек эшен сайлаган.

Каюм Насыйри ул чорда теләсә кайсы татар баласы белем ала алмаган уку йортында — Духовное училищеда белем алган, соңыннан аның дәвамы булган Духовная семинариядә татар теле укыткан.

Аның тәрҗемәи хәле турында мәгълүмат шактый күп сакланган. Без аның татар халкының гореф-гадәтләрен өйрәнүен, тарихи истәлекләр, фольклор әсәрләре җыюын беләбез.

К. Насыйриның мирасы бик зур. Аның галимлек хезмәтләре дә, әдәби мирасы да үз чорының укымышлысы булуын күрсәтә. «Әбүгалисина» кыйссасын гына алыйк. Ни өчен Каюм Насыйри Көнчыгышның танылган галиме хакында язырга алына? Минемчә, ул шушы кеше үрнәгендә татарларның дөньяви белемнәргә омтылуын тели.

Әбүгалисина тумыштан ук зиһенле булса да, аның белән генә канәгатьләнеп калмый. Бөтен белемнәр бергә җыелган мәгарәгә кереп, башкалар белән бергә алган байлыгын тагын да арттыра ул.

«Әбүгалисина» әсәрендә кешенең белемнәре бөтен халыкка, яхшылыкка, тормышны алга җибәрүгә хезмәт итәргә тиеш дигән фикер бар. Әхлаксыз кеше башына

тутырылган белем башкаларга зыян да китерергә мөмкин. Язучы әхлаклылык белән белемлелекнең янәшә яшәвен тели.

Белеменә таянып, гаделлек өчен көрәшкән, гади халыкны яклаган Әбүгалисина шул чор кешеләренең идеалын чагылдыра. Аны иҗат иткән Каюм Насыйри хакында да без үз халкының һәм үз чорының улы булган дип әйтә алабыз.

### Г. Тукайның «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» поэмасында Печән базары әһелләре

Г. Тукай «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» поэмасында Көфер почмагын гына сурәтләсә дә, шул чорның бик күп вакыйгалары һәм Печән базары үзе дә шактый тулы рәвештә күз алдыбызга килеп баса. Шул заман Казан тормышы, гомумән, Печән базарыныкына охшап калгандай була. Язучы, кечкенә генә җирне тасвирлап, зур күзаллаулар тудыра, заманына кагылышлы фикерләр әйтә ала икән.

Бүгенге иншада Печән базарыннан читкә китмәбез, аның кайбер әһелләрен үз аңлавыбызча һәм Тукайча тасвирларга тырышырбыз.

Шагыйрь баштан ук тиречеләр, итчеләр, шәмчеләр, майчылар, кибетчеләрне таңга калдырырга теләвен әйтеп уза. Болар — белгәнебезчә, ул заман базарының сатучылары. Аларның барысына хас уртак сыйфатлар бар: ничек тә булса башкаларны, бер-берсен алдау. Шул ук вакытта базарчылар гайбәт сөйләргә һәм тыңларга, кәмит карарга да өлгерәләр. Алар арасында акыл сатып, күп белгәнгә салынып, үзләренә охшаганны җөпләп утыручы картлар да бар.

Кеше хакында сөйләсәләр дә, сәүдәгәрләрнең үзләрен дә әйбәт дип булмый. Тукай урыны-урыны белән аларга да җиңелчә генә төрттереп уза:

Чыкты тагын да чапанлы бер хатын,
Җәлеб итәрлек тиречеләр диккатен.

Бер хаҗи шул хәл хатынга күз кыса
Һәм дә яп-яхшук оятсыз сүз куша.

Шул заманда Печән базарында сату итүчеләр төрек




Карәхмәт белән тәмам саташкан, шуны күрү өчен, циркка йөргән, көн-төн дога кылган була, аның мөселман булмаган көрәшчеләрне җиңүе белән горурлык хисе кичерә.

Поэмада Печән базары әһелләренең исемнәре дә бирелгән:

Йөзен орды туфракка, кыйлди зари,
Зари-зари еглады шәмче Гали.
/.../ «Миңлебай! Бар, тиз Карәхмәтне чакыр!»

Без Печән базары әһелләренең бер шатланып, бер күңелсезләнеп яшәвен күрәбез, әмма алар кайгырткан эшләрдән ислам дөньясына, дингә, милләткә файда юк.

**Дәрдмәнд лирикасында фәлсәфи уйланулар**

Уйланмаса, шагыйрь шигырь язмый. Милләтен сөймәгән кеше шагыйрь булмый. Шагыйрь кайсы телдә язса, беренче чиратта, шул телгә ия милләткә хезмәт итә, аның исеменнән сөйли. Үз заманының атаклы алтын приискалары хуҗасы булып та, милләтеннән ваз кичмәгән, алай гына да түгел, аның язмышы өчен көеп-яныл яшәгән Рәмиевләр алдында башымны иям.

Дәрдмәнд — Закир Рәмиевнең псевдонимы. Бу тәхәллүскә сагышлы, кайгылы, моңсу мәгънәләре салынган. Димәк, шагыйрь иле, халкы өчен кайгыда яшәгәнен, аның язмышы белән янганын аңлатырга теләгән.

Шигырьләренә мөрәҗәгать итик. «Кораб»... Әсәрнең өч ноктала белән чуарлануы гына да аның әйтелеп бетмәгән уйларга байлыгын күрсәтеп тора. Шигырьне укый башлагач та, кораб образында син үзеңне, адашкан юлчыны, гаиләңне, илеңне һәм башка бик күпләрне күрергә мөмкин. Ул сиңа гади бер сурәт, диңгез картинасы булып та тоелыр. Аннан соң килгән юлларда кораб образына салынган мәгънә тулылана төшә, шагыйрь аны Ил корабы дип аныклый.

Әлбәттә, син Ил корабы нәрсәне аңлата икән дигән уйларга батасың. Ул бит милләтне җитәкләгән зыялылар, аның белән идарә иткән хакимият, милли сәясәт һәм башкалар да була ала. Дәрдмәнд аңлавында, ул милләт символы булса кирәк, чөнки, шигырь язылганда, татар халкының милләт буларак формалашкан чагы.

Куелган шартларыннан чыгып карасаң, аның киләчәге дә әллә ни якты түгел, язмышын билгесезлек чорнаган.

XX гасыр башында инкыйлаблар, сугышлар булу бу чорның нинди катлаулы икәнлеген сөйли. «Чыкты җилләр, Купты дулкын», — ди шагыйрь дә. Милләт башка халыклар белән бергә яшәү, икенче берәүләргә буйсыну, үз эчендә төрле партияләр булу шартларында үзенең киләчәк юлын дөрес сызарга тиеш.

Дәрдмәнднең бу шигыре күңелдә моңсу уйлар тудыра. Милләтне тартучы, әйдәүче юлларны ул һәлакәткә илтер дип уйлый сыман. Шигырь әнә шул моңсулык тудыра алуы белән көчле. Язган юлларыннан өметсезлек сизелеп торса да, шагыйрь башкаларны шул юллардан качарга, үз халкын саклап калырга өнди кебек.

### Дәрдмәнднең «Видагъ» шигыренә салынган фәлсәфә

Туган илем, исән бул! Дәрдмәнд үзенең «Видагъ» шигырен әнә шул фикердән башлый. Без болыннарда тәгәрәп йөргән, таулар итәгеннән чапкан баланы күз алдыбызга китерәбез. Ул сабый чагында күргәннәрен гомере буена күңел түрендә йөртәчәк. Ул шул болыннарда ныгыган, суларда коенып, беләгенә көч җыйган, таулар артыннан чыккан таң кояшын каршылап, дөньяны яратырга өйрәнгән... Шуңа күрә шагыйрь үзе тәпи атлап киткән туган ягы хакында «тәгәрәп-уйнап буй үскән» ил дип яза да.

Туган якның җилләре дә җай исә, чәчне рәхәт кенә кузгатырлык була. Инде шушы матурлыкны җырлаган юллардан да сагыш хисе бөркелә, чөнки лирик мин хушлаша.

Сау бул дими ул, исән бул, дип, үзәген өзеп аваз сала. Сүзләр аша җиткерелгән хушлашу түгел бу, бу — йөрәк кычкыруы. Лирик герой, әлеге предметларның шушы туган як билгесе булып күңелендә саклануын да теләп, исән бул, дип әйтә сыман.

Шигырь строфаларга аерылмаган, әмма аны үзара охшаш саубуллашу юллары аерым кисәкләргә бүлә. Соңгы юлларга салынган аерылышу сагышына инде чикләр юк! Безнең күз алдыбызга тагын җанлы тор-

мыш картиналары килә. Олы юлдан атлап киткән егет. Артыннан йөгереп-йөгереп тә, аны шушы якта калдыра алмаячагын аңлаган чибәр кыз. Юллар башында яулык болгаган ул кызның күзеннән аккан аерылу яшьләре.

Егет китә. Күңеленә сабый вакытларын, үсмер чакларын, сөйгән кызының сурәтен, туган ягын ярату хисләрен салып, киләчәккә атлый.

Бу шигырьнең ничек язылуы картиналарының ни рәвешле чиратлашуы авторның фикерләү үзенчәлеген күрсәтә. Ике-өч деталь белән дә шагыйрь тулы бер вакыйганы чагылдыра.

## Гасырлар һәм минутлар

*(Һади Такташның шул исемдәге әсәре буенча)*

«Гасырлар һәм минутлар» поэмасында вакытны үлчәү берәмлекләре еш телгә алына. Озын тарихта, әйтерсең, гасыр — бик кыска аралык. Лирик мин аларның инде санын да югалткан шикелле.

Поэмада гасыр сүзе минут, көн, ел сүзләре белән янәшә куела. Шагыйрь катлаулы чорда көннәрнең, хәтта минутларның хәлиткеч роль уйнавын әйтергә тели. Кайвакыт минутлар гасыр китермәгән тетрәүләрне алып килә:

Бер минут — үлде.
Икенче бер минут
Шундый бер җимерү белән килде...

Минутларны, елларны киләчәк эшләр куалый. Ел узмый торып, гасырлар булмый, аларның да туасы, үләсе, зур эшләр майтарасы бар:

Таңны — көн,
Көнне
Гасыр, еллар куа.

Канлы көрәш еллары тизрәк уза. Шагыйрь аларны «ак сакаллы» дип атый, сынландыра һәм «тын гына җан бирә» дип белдерә.

Минутларның, көннәрнең, гасырларның каралары, аклары бар. Лирик герой яшәгән чор канлы еллар булып тарихка керәчәк. Шагыйрь аны акларга тели, чөнки көрәш матур таңнар китерәчәк дип исәпли.

Зилзиләле елларда һәр минут шомлы хәбәрләр җиткерә ала. Тыныч кына үтә торган гасырлар да була. Илләр, Җир шары, парламентлар турында сөйләгәндә, шагыйрь минут, көн, ел төшенчәләре белән генә канәгатьләнә алмый. Ул масштаблы уйлый, гасырларны күзаллап фикер йөртә.

Гасырлар — еллардан, еллар — көннәрдән, көн — сәгать, минутлардан тора. Йөрәк кадәр йөрәк минут эчендә туктагач, минутларны исәпкә алмыйча булмый. Кайбер минутлар гасырларны үзгәртә. Әйе болай... Бер караганда, гасырлар каршысында бер минут бар да кебек түгел.

## Татар әдәбиятында һәм сәнгатендә Муса Җәлил образы

Муса Җәлил, аның көрәштәшләре исеме безнең күңелләребездә мәңге сакланыр. Алар турында язылган йөзләгән әдәби әсәрләр, аларга багышлап төзелгән һәйкәлләр, Муса Җәлил исемен йөрткән опера һәм балет театры, республикабыз кала һәм салаларындагы урамнар да батырлар исеменең халык күңелендә саклануына китерә.

Казан Кремле каршында торган һәйкәлне генә алыйк. Аның турында бик аз шагыйрь генә язмыйча калгандыр. Бөек шәхесләр аркасында әдәбият һәм сәнгать тә үзара якыная ала икән.

Бу һәйкәл салыну тарихы чагылган шигырьне халык шагыйре Сибгат Хәким иҗат итә. «Һәйкәл турында уйланулар»да ул Җәлил янәшәсендә аның иптәшләре дә торырга тиеш дигән фикерне уздыра.

Күпләр Җәлил образын гел көрәштәшләре белән бергә тасвирлый. Г. Афзалның «Ышаныгыз» әсәрендә дә шулай. «Муса Җәлил һәйкәле» шигырендә ул шагыйрьгә куелган монументны сурәтли, ул тудырган кичерешләрне бирә. Аерым бер юлларны гына китереп узасы килә:

Куллары бәйләнгән сыныңны
Мәйданнар түренә бастырып,
Син үзең очасың еракка,
Йолдызлар иленә ашкынып.

Каерылып карыйсың биеккә,
Күзләрең еракка төбәлгән...

Кайвакыт шагыйрьләр Җәлилне башка темага язылган шигырьләрендә дә искә алалар, аны тасвирлаган һәйкәлне, аңа бәйле йортларны Казанның бер билгесе итеп күрсәтәләр:

Менә бу тоташ пыялалы
Соры йортта
Җәлил белән бер «банкет»та...

*(Ә. Давыдов, «Казанга чакыру» )*

Р. Вәлиев тә Казанны Җәлилдән, аның монументыннан башка күз алдына китерә алмый:

Янәшәдә — Җәлил. Кул богаулы,
Күзләрендә — халкым газабы,
Богауларын өзеп, ташланыр күк...
Саклар өчен уттан Казанны.

*(«Музейда янгын»)*

Татар шагыйрьләреннән Җәлил һәйкәле тудырган әсәрләргә бик күп мисаллар китерергә мөмкинлекне тагын бер кат әйтәсе килә. Димәк, сәнгать осталары иҗат иткән әсәрләр дә әдәбиятны баетуга сәләтле.

Шагыйрь турында әле тагын да язарлар, аның сыннарын әле тагын да уерлар, коерлар, чөнки Җәлил — милләтнең йөзек кашы. Хәсән Туфан да әнә болай ди:

Һәм синдә бар, ишек шакыганда,
Пароль булып калган исемнәр:
Олы улларың — Тукай, Галимҗаның,
Кече — Фатих, Җәлил ишеләр...

*(«Сөенечләр бирмәсә дә җилләр...»)*

## К. Насыйриның «Әбүгалисина» кыйссасында фантастик элементлар

Ләкин әкият никадәр генә фантастик булып күренмәсен, кайдадыр аның реаль нигезе бар.

*Г. Әпсәләмов*

Булуы мөмкин булмаган, уйдырма хәлләрне фантастика дип атыйлар. Фантастик сүзенең «тылсымлы» мәгъ-

нәсе дә бар. Көчле хыял белән сугарылмаган әкиятләр бик аз очрый. Бер караганда, еш кына язучы кулланган гипербола-арттырулар да тасвирланган күренешне, образны кеше ышанмастай итә бит.

К. Насыйриның «Әбүгалисина» кыйссасында кеше ышанмастай хәлләр байтак. Хәтта тау куышында булган белем мәгарәсенә дә бүгенге укучы ышанмый инде. Ике туган, әлеге мәгарәгә керер алдыннан, үзләрен ачлы-туклы торырга күнектерәләр. Алар бер көндә егерме тиен көмеш акча зурлыгындагы зәйтүн мае ашыйлар, айга нибарысы бер мәртәбә су эчәләр.

Кеше ышанмастай эшләрнең дә нигезендә тормыштан алынган хәлләр ята. Элекке заманнарда тау куышларында китапханәләр булу, эссе якларда куышта яшәүче халыклар барлыгы билгеле. Үзләрен махсус хәзерләгән кешеләр, әйтик, йогалар, бик озак ашамый-эчми дә торалар. Ә менә гадәти кешенең зур күпчелеге, әле ашамауны шактыйга сузганда да, ничә генә көн сусыз тора ала икән?!

Әкияттәге гап-гади генә күренгән нәрсәләргә дә игътибар итеп укыдым мин. Ит оныннан бавырсак пешереп буламы? Һавада очкан кеп-кечкенә чыпчыкка *әллә* тидерерсең дә, ә менә күзен генә чыгару мөмкин бер эш булып күренмәде.

Әсәрдә ике туган гадәттән тыш эшләрне фәнгә таянып башкаралар дигән фикер бар. Аның бер герое — Әбүгалисина тормыштан алынган бит. Һәм, чынлыкта да, заманасында кеше ышанмастай нәрсәләрне башкарган, астрономия, химия фәннәрен белгән, төрле ачышлар ясаган. Надан кешеләргә бу сихер, җен эше булып күренгәндер. Аның турында имеш-мимешләр таралгандыр, һәм шул имеш-мимешләргә каршы боларның бары фән эше генә икәнлеген сөйләүче «Әбүгалисина» кебек әкиятләр тугандыр.

Иң элек, уңай герой булган, гади халыкка хезмәт иткән Әбүгалисина «галәмәтләре»нең кайберләрен санап үтик. Кешене күзгә күренми торган итү, кибәктән хәлвә ясау, җылы илдәге мунчаның эчен боз белән тышлау һәм башкалар. Без хәзер химик юл белән, матдәнең төзелешен үзгәртеп, ризык ясап булганны беләбез.

Суыткыч камералары эчендә җәен дә боз тора. Экстрасенслар әллә кемнәрнең күзен буа: күренгәнне яшерә, булмаганны бар итеп күрсәтә. Моннан чыгып, без әле Әбүгалисинаны экстрасенс дип тә атый алабыз.

Әбелхариста да бар андый фантастик сәләтләр. Рәмел тактасы аша ул бөтен нәрсәне күзәтә. Андый хәлләр турында хәзер дә язалар ич. Димәк, ул да интуициясенә, экстрасенслык сәләтенә таянып, гади күзгә күренмәгәнне тасвирлаган. Мәйданда туганыныкы белән бергә башы киселергә хөкем ителгәч, бауларны чишеп, аның буенча сарай түбәсенә менгән. Менә сиңа каскадер!

Кыскасы, «Әбүгалисина» әкиятендә кеше ышанмастай хәлләр, фантастик күренешләр байтак, әмма алар юктан гына уйлап чыгарылмаганнар.

## Фатих Хөснинең «Йөзек кашы» әсәрендә Вәсиләнең тышкы портреты

Портретлар остасы, нечкә тоемлы Фатих Хөснинең кечкенә кыз Вәсиләне ничек тасвирлавын хәтерлисезме?

«Бүтәннәр алма карыйлар, мин кыз карыйм», — ди Айдар. Әгәр ул, Вәсилә шундый, Вәсилә мондый, дип, аның тышкы кыяфәтен махсус сөйләгәнен сиздерсә, әсәрне уку бик кызык булмас иде.

Нинди икәнен беләсе килеп карый икән, димәк, егет кеше аны энәсеннән җебенә кадәр тикшерәчәк, шунлыктан кызның тышкы кыяфәтен тасвирлау бик табигый килеп чыгачак.

Ф. Хөснинең хикәяләүче герое тасвирлап кына калмый, кызның һәр кыланышына, җиренә, киеменең һәр өлешенә бәясен биреп карый: «Кыланчык нәрсә икән, эшләпәсенә ал лента бәйләгән булган». Туктале, Айдар әле яңарак кына: «Аты әйбәт, арбасы әйбәт, кызы әйбәт», — дигән иде түгелме соң?! Юк, юк. Ул башта аны шөпшәгә тиңли ич. Алай дисәң, шунда ук сүзен кире кага.

Айдарның кызны әле чеметеп алуы, әле аның турында исе китеп сөйләвенең сәбәбе аңлашыла. Аның Вәсиләгә күзе төшкән, әмма шуны таныйсы, «егетлеген» түбән төшерәсе килми. Безнең бернинди кызга ис китми,

янәсе! Чөнки... кызлары да үзләрен нәкъ шулай тота.

Вәсиләнең портретын без аның эш-хәрәкәте вакытында да тулыландыра алабыз. Менә ул көлә: тешләре ап-ак икән. Менә ул малайга борыла: битендә миңе бар лабаса!

Язучы Вәсиләнең шушы вакыттагы кыяфәтен соңыннан да искә ала әле. Кешене гашыйк иткән беренче мизгелләр, мөгаен, гомер буе онытылмыйдыр. «Аллы-зәңгәрле ленталар тагып, шомырт кара күзләреңне сирпеп, сикергәли-сикергәли, әллә кайдан килеп чыктың да...», — ди, еллар узгач, аның хакында Айдар.

Буй җиткән кыз турында сөйләгәндә дә, укучы күз алдына аның янәшәсенә әнә шул нәни кызчык килеп баса. Вәсиләнең холкында, кыланышында һаман да балачак төсмерләре саклана. Фикеремне раслау өчен, язмамны башкага ярәшелгән Вәсилә турындагы юллардан берничәсе белән бетерәм: «Вәсилә кинәт үзенең балалыгына кире сикергәндәй булды. Кузгалды, җиңел гәүдәсе белән очып, минем муеныма килеп асылынды».

## Шулай үлде Ватан улы

*(Фатих Кәрим иҗаты буенча)*

Бөек Ватан сугышы чоры татар поэзиясе күгендә мәңгегә сүнмәскә дип кабынган йолдызлар бар. Шуларның берсе — шагыйрь Ф. Кәрим.

Фатих Кәрим сугышның башланган елында ук фронтка китә һәм һәр көнне, шигырь язып, газеталарга юллар өчен, кулына каләм ала. Иҗат белән туктаусыз шөгыльләнү шагыйрьнең осталыгын тагын да үстерә. Аның иң матур шигырьләре шушы елларда языла.

Сугыш кырларында йөрүче Ф. Кәримгә дуслары язган хатлар да әнә шул хакта сөйли.

Авторы дошман белән бәрелештә һәлак булганнан соң, «Ант», «Ватаным өчен» кебек тирән фәлсәфә белән сугарылган шигырьләрдә моңа кадәр аңлашылмаган бик күп нәрсәләр дә бар кебек тоела.

«Ант» шигырендә сөйләгәннәр кино кадрлары кебек күз алдыннан уза. Аның лирик героен без сугышка китүче теләсә кайсы ир-ат, Ватанын яраткан зат итеп аңлыйбыз.

58

Бик күп халыкларда ана, бала — изге төшенчәләр, алар белән ант итү зур җаваплылык йөкли. Вәгъдәңне үтәмәсәң, син гомергә дә бәхет күрмәячәксең дип уйланыла. Бала тотып ант иткән ир кеше дә нәрсә эшләгәнен аңлый булыр.

Сугыш үлем-җитемнәр алып килә. Ф. Кәримнең герое да үзенә үлемсезлек юрамый. Карары нык: ни генә булса да, ул артка чигенмәячәк!

«Ватаным өчен» шигырендә лирик герой шагыйрь-сугышчы образы белән кушылгандай була. «Җырым кала үткән юлымда» шигъри юлы аның иҗатчы икәнлеген күрсәтә. Соңгы строфа бу җырның мәгънәсен киңәйтә. Шагыйрь инде Ватан кырларында үлүне бөек җырга тиңли.

Ф. Кәримнең сугыш елларында язганнары шул чор елъязмасы кебек. Дөрес, аның «Ватаным өчен» шигыре, үзе әйткәнчә, соңгы хаты булмый әле, әмма ул, инде Җиңү көне якынайганда, һәлак була.

Шагыйрь:

Үләм икән, үкенечле түгел
Бу үлемнең миңа килүе, —

ди. Ватан хакына үлүдән курыкмау, аны данга санау көчле ихтыярлы, саф йөрәкле, батыр кешеләргә генә хас.

## «Сез — болгар бабалары, Без — аның балалары»

*(Г. Рәхим)*

Гәрәй Рәхим шигыреннән сочинение темасы сыйфатында китерелгән өзек миңа Н. Арслановның «Халкыма» шигырен хәтерләтте.

Борынгыма якыная барам,
Төшсәм ерак еллар артына.
Сәхифәләр саен хәйран калам
Зур тарихлы батыр халкыма, —

дип башлана ул.

Шигырьдән, безнең бабаларыбызның үз илләрен саклар өчен тырышканнары, милләтне авыр сугышлардан исән алып чыкканнары өчен, шагыйрьнең горурлануы күренә.

Болгар иңгән... Казан үсеп чыккан
Казан суы, Идел чатында:
Озак еллар буе дәүләт тоткан
Төп оясы булып халкыма...

Бу строфа югарыда Г. Рәхим уздырган фикернең кайтавазы кебек. Н. Арсланов Казанның, татарларның Болгар иле, болгар халкы варислары икәнлеген әйтә.

Шуннан соң бу халыкларга хас уңай сыйфатларга туктала ул. Без татарларның Көнчыгышка да, Көнбатышка да якынлыгын беләбез. Шагыйрь әлеге якынлыкның эчтәлеген ача. Татарлар Көнбатыштан акылга өйрәнде дигән фикерне әйтә.

Н. Арсланов, милләтебезнең үзенә генә хас сыйфатлары белән никадәр горурланса да, башка халыкларны тигез күрүен, яратуын, алар алдында да баш июен яшерми.

Без, бүгенге яшьләр, ата-бабаларыбыз тоткан юлдан барырга тиеш дип саныйм мин. Телебезне онытмасак, Ватаныбызны яратсак, башка халыкларның бәхетле яшәвенә дә сөенсәк, аларны туганнардай күрсәк иде.

## Мин сезгә яраткан язучым турында сөйләргә телим

*(Хәсән Сарьянның «Бер ананың биш улы» әсәре буенча)*

Мин Хәсән Сарьян белән «Бер ананың биш улы» повесте аша таныштым. Әлеге әсәрнең ышандыру көче шулкадәр зур ки, анда булган вакыйгаларны язучының үзе турында түгелме икән дип уйлап куясың.

Әлбәттә, оста художник кеше күңелендәге кичерешләрнең бик тирәндә ятканнарын да тотып ала, бирә белә, шуңа да карамастан, минем уйлавымча, язарга сәләтле һәм үтә тоемчан кешеләргә автобиографик җирлекле әсәр белән язучы уйдырмасы нигезендә туган повесть яисә романны аеру кыен түгел. «Бер ананың биш улы»н исә һәркем, моны үз күзе белән күргән, кичергән кеше генә шулай яза ала, дип укыгандыр.

Әсәре белән беренче кат танышкач туган хисләр мине аның белән яңадан танышырга, аерым фактларны истә калдырырга мәҗбүр итте, һәм шуннан соң мин әдип турында укырга, эзләнергә керештем. Хәсән Сарьянның шул исем белән дөнья күргән яңа китабындагы кереш

сүзнең беренче бите үк мине тетрәндереп җибәрде. Әмирхан Еники, әйтерсең, мин укыган әсәрнең ахырын язган иде. Әдип, «типсә тимер өзәрлек көчле, нык, таза ир»нең авырмаган бер вакытында йөзтүбән капланып үлеп яткан хәлдә табылуын әйткән иде.

Ә. Еники, үз герое Сириннең туганнары вафатын хәбәр иткән кебек үк, Хәсән Сарьяннныкы дәрәҗәсендә үкенечле үлем күргәне булмаганны яза. Моны тумыштан ук язмыш билгеләгән кебек аңлавын әйтә. Сирин дә, абыйларының үлеменең сәбәпләре булу өстенә, ниндидер билгеләгәнлекне дә сиздерә бит. Алар алдан ук аның белән хушлашкандай, егетләргә язмыштан хәбәр килгәндәй. Андый урыннар әсәрдә байтак.

Мин китап тышлыгына урнаштырылган рәсемгә карап уйланып утырдым. Дүрт улның төсмерләрен эзләдем. Киң борын, куе каш, нык, таза, мәһабәт гәүдә. Сирин — Сарьян, Салих — Солтан исемнәрендәге охшашлык һәм башка бик күп нәрсәләр автор һәм хикәяләүче геройның үзара бәйлелеге турында сөйли иде.

Сугыш чорына туры килгән язмыш, белем алу, хезмәт юлындагы аерым уртаклыклар, Башкортстан якларының тасвиры һәм башкалар да, «Бер ананың биш улы» повестена нигез итеп, язучы биографиясе алынганны, әмма аның бер үк вакытта шактый гына үзгәртелгән булуын да әйтә. «Әткәм һөнәре»н укыгач туган шундый ук уйлар, көчле тәэсирләр исә ул әсәрнең дә язучы биографиясеннән булу мөмкинлеге хакында сөйли.

Ә. Еники язган кереш сүздә язучы тормышыннан фактлар байтак. Ул вакытка инде аксакал әдип без атаган икенче иҗат җимешенең биографиясенә бәйлелеге турында язып та үтә.

Х. Сарьянны нәкъ менә шушы ике әсәр үлемсез итә дип уйлый идем... Инде керешне укыганда икенче кат сөртенгәндәй булдым: «Гомеренең ахырына таба язган ике үлемсез әсәре — «Бер ананың биш улы» белән «Егет язмышы» повестьларына карап әйтәм мин моны» дигән юлларга юлыктым. Бу — язучыны тагын да өйрәнү, уку теләге уятты.

«Вакытсыз киткәннәр алдында без һәрвакыт бурычлы!» — ди Әмирхан ага Еники. «Бер ананың биш улы»

повестенда язмышка буйсынган кебек булган геройлар да шул хакта һәрвакыт әйтеп тора. Якыннарын югалту хәсрәте аларны әкренләп юкка чыгаргандай була.

Х. Сарьян — күңелемне ике әсәре белән гомерлеккә биләгән язучы. Бер ананың дүртенче улымы син? Әллә мин ялгышаммы?

## «Бер ананың биш улы» повестенда эчкечелеккә китергән сәбәпләрне ачу

*(Хәсән Сарьянның шул исемдәге әсәре буенча)*

Хәсән Сарьян иҗат иткән мәһабәт гәүдәле геройлар, кырау суккандай, аналарын хәсрәткә батырып, якты дөньядан китеп бара. Әсәрнең беренче бите үк үлем вакыйгасын хәбәр итүдән башлана. Башта — бу балаларның аталары, сугыш башлангач, бер-бер артлы авылдашлары дөнья белән саубуллаша...

Сугышта, үзләре әйткәнчә, пуля да алмаган геройларның тыныч тормышта гомерләре өзелү әрнү хисләрен тагын да арттыра. Типсә тимер өзәрдәй таза гәүдәле Мирза, кешеләрне яклаганда, хулиганнар пычагыннан үлә.

Иң моңлы, иң чибәр Хәвадис авыр чирләрне тәмам җиңеп бетерә алмый. Сугыш чорында егетләрнең җан асрау өчен башкарган эшләре аны гомерлек хаста итә.

Раббани бу хәсрәтләргә каршы тора алмый, эчүгә сабыша. Аның үлеме барысыныкыннан да мәгънәсезрәк булып чыга. Кесәсенә шешә тутырып, энесе янына йөгергән ир, кузгалып киткән пароходка утырмакчы була, әмма суга төшеп, пароход астында юк була.

Хәсрәтне төрлечә кичерергә мөмкин. Татар кешесе нәкъ менә сугыш чорында, сугыш кырларында аны аракы белән юарга күнегә. Егетләр хәрби хезмәттән ялга кайтканда да җыелышып сыйланып алырга ярата.

«Бал абзый» Шәрифулла кызына өйләнгән Раббани гомере шулай киселгәнгә, бер караганда, аптырарлык та түгел кебек. Авыл халкына эчемлекнең төрлесен әзерләп кенә торган каенатасы да өмә вакытында бал күп эчүдән янып үлә бит. Кешеләр генә моны аңлап җиткерми. Аңлаганнары искә алырга теләми.

Әсәр безгә эчкечелекнең тиз арада тамыр җәюе турын-

да сөйли. Башта күмәк эшләрдә эчелгән балдан ясалган исерткечләрне әкренләп аракы, кибет сыралары алмаштыра. Мәҗлесләрдә көчләп, кемдер хөрмәтенә эчүләр модага керә башлый.

Аракыга тәмам битараф, башкалар эчкәнне дә өнәп бетермәгән, спортсмен Сирин дә кайвакыт, дусларны, туганнарны тыңлап эчеп куярга мәҗбүр.

Раббани абыйсының үлеме үзәк геройны әллә нишләтеп җибәрә. Биш туганнан нибарысы икәү калганны күтәрә алмыйча, ул да аракылы савытка үрелә. Шул вакыт Әдрән энесе аны беләзегеннән тотып ала: «Җитте, абый!»

Иң көчле, иң гайрәтле, сугыш чорында колхозны җилкәләрендә тартып алып барган егетләрне дә җиңә икән аракы. Ул әнә шуны төшенәдер шикелле.

Яшәүне эштән башка күз алдына китермәгән, яхшы күңелле, әниләрен яраткан, гаиләләрен караган ирләрдән дә көчлерәк ул аракы дигән чир дип әйтмиме язучы? Әллә ул — бер гадәтсезлек кенәме? Ә бит кайвакыт чирләр дә китә, гадәт кенә китә алмый. Раббани язмышы бу фикерне бик яхшы исбатлый. Алай гына да түгел, аракы эчү гадәтенә кергәч, аның гомерлеккә үткән кебек киткән чирләре дә яңадан кайта.

Бер ана, биш ул. Һәрберсе китергән шатлык белән бергә үк аның тәрәзәсенә хәсрәт шакый.

# VIII сыйныф

## ГҮЗӘЛ ГАМЬ

**Сез «... кабызган утлар сүнмәс алар,**
**Сүнмәс алар хәтәр җилләрдә...»**

*(К. Тинчурин)*

Татар сәнгатендә беркайчан сүнмәскә дип кабынган йолдызлар бар. Гөлсем Болгарская, Гөлсем Камская, Фатыйма Камалова, Фатыйма Ильская... Исемнәренә кадәр охшаш икән бу артисткаларыбызның.

Аларны мин үзләре башкарган рольләр белән бергә исемә төшерәм. Артистканы сәхнә остасы итеп таныту өчен яхшы әсәрнең, образларның иҗат ителүе дә кирәк

шул. Алда санап узган олы шәхесләр башкаруында кайчандыр фондларга тупланган аерым спектакльләрнең язмалары радио-телевидение аша әле һаман да яңгыратыла. Бу яшь буын артистларның да милли мирасыбыз традицияләрендә тәрбияләнүенә ярдәм итә. Без радио аша еш тыңлый торган әсәрләр арасында М. Әмир иҗат иткән «Тормыш җыры» пьесасы да бар.

Әлеге драма — кешенең рухи күркәмлеге турында җыр ул. Безне Басыйр белән Фатыйманың нинди тирән мәхәббәткә ия булуларына таң калдырган әсәр. Аның барлык геройлары иҗтимагый эш, күмәк хезмәт өчен янулары белән гаҗәпләндерәләр, үзләренең булдыклылыклары, иҗатка сәләтлекләре белән барыбызга да үрнәк булып торалар.

Кызганыч ки, пьесаның үзәк герое Фатыйма әсәр ахырында Басыйры белән бергә калмый. Егет сөеклесе янына бары җыр булып кайта. Бу җыр аны көрәшләргә әйди, Фатыймада яшәү теләген арттыра. Бүгенге көн яшьләре мөнәсәбәтләрен хәтерләтмәсә дә, кыз-егет арасында табигый хисләр яши, ул тормышчан романтика белән сугарылган.

Язучы «Тормыш җыры» әсәрендә, кеше бәхетле булсын өчен, еллар тыныч, илләр имин булырга тиеш, идеясен уздыра. Колхоз алдынгысы, уңган Фатыйма, җиңүне якынайту аша кешеләрне бәхетле киләчәккә китереп җиткерү өчен, бөтен көчен куя. Без аның оештыра белү талантына, ихтыяр көченә ия икәнлеген күрәбез.

Мәхәббәт өчпочмагы булмаса, пьеса хезмәт темасына язылган, кеше күңеленең төпкелләренә узмаган бер әсәр булып калыр иде. Фатыйма Фәриткә битарафлыктан гына Басыйрны көтсә дә, безгә ул хәлләр бик табигый күренер, кыз да үзенә тиешле яратуыбызга ирешмәгән булыр иде. Язучы кызыграк юл сайлаган: Фатыймада Фәриткә булган җылы хисне яшәткән. Кыз, күңелендәге каршылыкларны җиңеп, үз-үзе белән көрәшеп, егетнең мәхәббәтен кире каккан, Басыйрга тугры булып калган.

...Мин исән, мин үлмәм,
Мәхәббәт көчле диләр — салкын үлемнән, —

дип җырлый Басыйр. Ул сугыш кырларыннан кайткан көе белән сөекле Фатыймасын да яшәтә.

Фатыйма Ильская талантлы уены белән тамашачы, әдәбият сөючеләр күңелендә үзәк героиняны мәңгеләштерде, һәм үзе дә мәңгеләште, дип әйтәсе килә минем. Аның сәхнә йолдызын «Тормыш җыры»ндагы Фатыйма кебек башка бик күп көчле образлар кабызды.

**Хаклык өчен көрәшчеләр сафында минем урыным**

Үсеп җитеп, белем алып, нинди генә эштә эшләсәк тә, безнең урыныбыз хаклык өчен көрәшчеләр сафында булырга тиеш. Телевизор экраннары күрсәткән тапшыруларны карасаң, кулыңа газета-журнал алсаң, тәннәр чымырдап китә. Анда — үтереш, монда — кеше талау, тегендә — сугыш, мойда — фетнә... Әйтерсең, дөньяда бернинди гаделлек юк һәм булмаячак та. Карыйсың, тыңлыйсың, укыйсың да нәтиҗәгә киләсең: боларга, һичшиксез, чик куярга кирәк.

Бер генә кеше дә карак, вәхши яисә башка бер хайвани зат булып тумый. Ул әнисенең сөтен имә, туфракта үскән икмәкне ашый, балалар бакчасына йөри, мәктәп партасы артында утыра... Ул синең белән бергә су коена, таудан чана шуа, шатлана-кайгыра. Шулай икән, ни өчен синнән җәмгыятькә кирәкле кеше чыга, икенче берәү гомерен төрмә рәшәткәсе артында уздыра яисә беркемгә көн күрсәтмичә, үз рәхәтенә яши бирә?

Менә синең дустың Илмар. Ул кичә генә шаярып сыйныфташыңның аягын имгәтте. Аны беркем укытучыга әйтмәде, син дә бу эше өчен оялтмадың. Инсаф белән Алмаз, киемнәр бүлмәсендә калдырылган кеше кроссовкаларын киеп, физкультура дәресенә кергәннәр. Беркем белми калды. Яңадан урынына куйгач, син дә дәшмәдең. Күрше апа бакчасындагы чияләрне җәй көнендә үзең дә капкаламадыңмы? Әниең күрмәгәндә, суыткычтагы җиләкләрне кем юк итте?

Әйе, әнә шундый кечкенә генә бер шуклык булып тоелган эшләр зураерга мөмкин. Үзендә җаваплылык тойгысы, оялу хисе булмаган балалар әкренләп ямьсез гадәтләргә ияләнә, боларны эшләүне бер булдыклылык

дип саный башлый. Чир китә, гадәт китми, дигәннәр борынгылар. Зур-зур абыйлар бакчадан алма урлап йөрмәс бит инде. Алар кешенең зуррак малына кул суза башлый. Бүген дустын кыйнаган Илмар иртәгә аңа башка зыян сала.

Шуларны күбрәк күзәткән, бу хакта ешрак уйлаган саен, мин үземнең хаклык өчен көрәшчеләр сафында булырга тиеш икәнлегемне аңлыйм. Сыйныфташларың үпкәләмәсен дип, укытучыдан чын дөреслекне яшермәскә кирәк. Әти-әниең орышмасын өчен генә, үз гаебеңнән дә баш тартма. Көчеңә ышансаң, дусларыңны гадел юлга бастыру өчен, үзең тырыш. Булдыра алмасаң, башкаларны ярдәмгә чакыр.

Зур үскәч, гаделлекнең икенче юллары бар. Юрист булырга мөмкин, милиция һөнәрен сайларга була. Ә бит, бер карасаң, теләсә кайсы хезмәт урынында гаделлегең белән кешеләрнең хөрмәтен казанырга мөмкин.

## Халкымның күнел байлыгы

Сабантуйлар, каз өмәләре, чирмәнчек, яфрак бәйрәмнәре... Бу йолаларга халкымның күңел байлыклары салынган. Авылда яшәмәгән, һич югы ялларына кайтмаган кешеләргә аларның бөтен матурлыгын аңлатып бетереп тә булмый торгандыр.

Минем Казан сабантуенда да булганым бар, тик ул күңелемә авылныкы кебек көчле тәэсир ясамады. Күбрәк рус телендә алып барылган ярышларны караганда, мин үземне туган ягымның чит баласы итеп тойдым. Башка милләт халыкларына үз телләрендә бәйрәм уздырырга мөмкинлек биргән республикам инде хәзер бердәнбер булып калган сабантуйны да интернациональ дуслык бәйрәме ясап, эчтәлеген үзгәртте шул...

Авыл сабантуе нәрсә белән аерыла соң? Кунакларның елның теләсә кайсы көненә караганда күбрәк кайтуын беренче чиратка куйсам, ялгышмам. Кайвакыт син кайбер туганнарыңны үз гомереңдә беренче мәртәбә нәкъ менә шушы бәйрәмдә күрәсең. Сине инде әллә кайчан вафат кемгәдер ошатканга, аркаңнан сыйпап, озак еллар авылын күрмәгәненә үкенеп, яулык читен бөкләп елаган карт әбиләр, яшьлекләрен искә алып, гармун тарткан агайлар, беренче сөйгән ярлары

белән очрашкан апа-абыйлар булып күз алдына килә сабантуй.

Мәйданда көрәш кыза. Кунаклар күбесенчә бер-берсен күреп калырга ашыга. Авыл кешесе, утыргычтан урын алып, ярыш карауны сайлый. Кайсы авылныкы батыр калыр да, кем, колга башына менеп, кызыл әтәчне очыртып җибәрер? Бүләк читкә китмәсә генә ярар иде дип офтана авылпәрвәрләр.

Миңсылу апаңның төпчек кызы Минзилә генә башкача уйлый. Мәйдан уртасында торган күрше авыл егете Таһир иртәгә аны килен итеп төшерә. Авылдашларыңның бөтенесе дә моны белми. Менә таза беләкле Таһир батырны күккә чөя. Аксакал, бүләк биргәндә: «Авылның беренче киявенә», — дип сүз кыстыра. Мәйдан җиңел сулап куя. Аллага шөкер, батыр калган чит-ят кеше түгел икән әле.

Бер караганда, кемнең өстен чыгуы мөһим дә түгел кебек, әмма авыл көрәшчеләре өчен эчтән янып утыру көрәшне кызык итә, уртадагыларга дәрт өсти.

Безнең авылда ярышлар гаделлеген күзәтеп, уртага чыгып, тарткалашып, даулашып йөрүчеләр дә бар. Алары да — сабантуйга бер бизәк, көлешергә бер сәбәп ич аның!

Мин үзем ат ярышын яратам. Иң арттан килгән атка бүләк бирми калмыйм. Хәер, безнең якларда һәр катнашкан кешегә бүләк бирәләр. Җиңгән кешегә — бүләкнең саллысы.

Яулык җыйган көнне дә бик күңелле. Авыл кешеләренә кунакчыллык, юмартлык күрсәтергә җай вакыт ул. Кызларны сайларга, чиккән кулъяулыкларына карап, уңганлыкларын күрергә дә кулай. Сабантуй җырга-хискә байларны да үз түренә чакыра.

Күңелемне ачып салыйм дисәң, сабантуйга кайт!

**Бүгенге татар драматургиясендә замандашым**

Минем уемча, яшь драматурглар безнең тормышны аңлыйрак төшә. М. Гыйләҗевне генә алыйк. Соңгы елларда яшьләр турында әллә никадәр әсәр иҗат итте ул. Алар төрле театрларда зур уңышлар белән бара. «Казан егетләре» пьесасы бүгенге көндә дә сәхнәбез түреннән төшми.

М. Гыйләҗевнең замандаш образларын тудырган әсәрләре арасыннан «Сафиулла» пьесасын аерып атыйсым һәм шуның хакында язасым килә.

«Сафиулла» фаҗигасенең сюжеты шактый буталчык итеп бирелгән, шунлыктан уку, аңлау өчен бераз авыррак. Минем уемча, аны сәхнәләштерү дә җиңел булмас. Үзәккә куелган вакыйгаларның барысы да мине ышандырып бетермәсә дә, язучы уздырган кайбер карашлар белән килешмәсәм дә, ул мине үзенә җәлеп итә алды. Сафиулланың өч хатыннан туган өч баласы белән аеруча истә калды ул.

Пьесаның Каюм, Илгиз һәм Азатның үзара мөнәсәбәтләрен тасвирлаган урыннары иң зур ышандыру көченә ия. Әлеге геройлар яшьләре белән миңа тиң булмасалар да, мин аларның яшәү рәвешен, күңелләрен аңлыйм, чөнки өчесе дә — бүгенге заман кешеләре, өчесе дә һәрберебезгә таныш проблемаларны чишә алмыйча газаплана.

Араларыннан берсе — өстеннән милиция киеме төшмәгән каравылчы Илгиз. Аз эшләргә, рәхәт яшәргә ярата ул. Туганнарыннан, атасыннан бүген үк котылыр иде, тик уртак йортларын сатып, акчаның күбрәк өлешен үзенә аласы бар. Әйтерсең, тузган, шакшы өйдә яшәү аны тупасландырган, әти кулында гына үсү күңелен катылаткан.

Төрмәдә утырып кайтса да, кешелек хисләрен югалтмаган, ярата белгән, үзен куып чыгарган атасын гафу иткән Азатка караганда, хөкем органнары тарафыннан тагылган ярлыгы булмаса да, Илгиз җинаятьчерәк булып күренә. Хәер, ул аның хатыны Ләйләне көчләргә маташуы белән генә дә, чын мәгънәсендә, җинаятьче инде.

Бөтенләй башка шартларда, башка анадан туган, кешеләргә исәррәк булып күренгән Каюм хәтта Илгизне дә ярата, Азат, әтисе Сафиулла карт өчен кайгырып яши. Аның үзен тудырган ананың кемлеген беләсе, каберен тапса, шуны карауны үз өстенә аласы килә. Төрмәдән кайткан Азатны да гаилә тарихы борчый башлый. Димәк, күңелендә булган тетрәүләр аны уңай якка үзгәртә, кешелек хисләрен тагын да үстереп җибәрә.

Сафиулла, Каюм, Азатны җинаятьче дусларыннан

аерып калырга теләп, үзләрен зур авырлыкларга куйганда, Илгиз аны өйдән куып чыгаруның, дусларына тотып бирүнең юлларын эзләп йөри.

Яхшы күңелле кыз Ләйлә бу йортка яңа сулыш өрер, гаилә учагын кабызыр шикелле. Аның туачак баласы хәзер инде тупасланып күренгән, әмма кайчандыр мәрхәмәтлелеге, ярдәмчеллеге белән бөтен кешеләргә үрнәк булган Сафиулла кебек булсын иде дип телим мин.

Сафиулла башта янгын вакытында үз йортының гына исән калуына аптырый. Әсәр ахырында ул әнә шуның сәбәбен аңлый, дөньяга күзе ачылгандай була. Хәзер атаны, үзе әйткәнчә, «ахмак» Илгизнең йортны сатуы да куркытмый, аның күңеле авылдашлары янына яңа йортлар торгызырга ашкына. Балалары да аның белән булыр дип өметләнәм мин.

— Без кешеләргә булышырга тиеш... Безнең язмышыбыз шундый, — ди ул аларга. Инде юлдан чыга башлаган Илгиз дә атасы белән авылга китәр кебек.

«Сафиулла» пьесасында матди авырлыкларга, төрле фаҗигаләргә, рухи сынауларга тарган замандашларым тасвирлана. Ленар, Нурик кебек җинаятьчел төркем әгъзалары да — минем чордашларым, әмма алардан акыллы, хезмәт сөючән, гаиләсен олылаган Каюм, Ләйлә кебекләр йөз чөерә.

**Нәкый Исәнбәт — фольклорчы**

Н. Исәнбәт — татар әдәбиятын үзенчәлекле әсәрләр белән баеткан талантлы язучы. Ул — татар драматургиясенең Г. Камал кебек олы шәхесләр башлап җибәргән традицияләрен дәвам итүче дә, халык авыз иҗатының бай хәзинәләрен туплап эшкәрткән зур галим дә.

Н. Исәнбәт туплаган, гыйльми өйрәнгән, төркемләгән мәкаль һәм табышмаклардан төзелгән җыентыкларны кем генә белми, алардан кем генә файдаланмый?! Укучыларга «Татар халкының балалар фольклоры» китабы аеруча яхшы таныш.

Фольклор байлыкларын яхшылап өйрәнгәнгә, эчтәлекләрен дөрес ачканга, халык иҗатының бөтен тармакларын да әйбәт белгәнгә күрә, Н. Исәнбәт әдәби

әсәрләрендә аларга еш мөрәҗәгать итте. Ул аерым мәкаль-әйтемнәрдән уңышлы файдаланды, халык авыз иҗатындагы аерым сюжетларны пьесаларына нигез итеп алды.

Мәсәлән, язучының «Әбүгалисина» драмасы. Н. Исәнбәт анда Көнчыгыш әкиятләренең героен Болгар ханлыгы чорында әби-бабаларыбыз яшәешен чагылдыру максатыннан файдалана. Безгә мәзәкләр аркылы билгеле Хуҗа Насретдин образын үзәккә куеп, Туктамыш хан белән Аксак Тимер арасындагы көрәш елларын тасвирлый ул.

Н. Исәнбәтнең «Җирән Чичән һәм Карачәч сылу» комедиясе бүгенге көндә Г. Камал театрында зур уңыш белән куела. Анда XIV йөзнең урталарында Идел буенда барган вакыйгалар сурәтләнә. Җирән Чичән шулай ук — халык тарафыннан тудырылган образ.

Әдипнең бу әсәрләрендә дә, башкаларында да хезмәт кешесенең кайгы-хәсрәтләре, көндәлек проблемалары күрсәтелә. Н. Исәнбәт аларны мәрхәмәтсез, кайчак надан, куркак хаким сыйныфларга каршы куя. Уңай геройлар, үзләренең зирәклекләре ярдәмендә, тормыш киртәләрен җиңеп чыгалар.

Н. Исәнбәт халык авыз иҗатында киң таралыш тапкан фикерләргә таяна, үз әсәрләрендә шуларның иң куәтлеләрен ассызыклый. Әдип, тарихны халык тудыра дип санаганга, шулай эшли, минемчә.

Кайвакыт артистларыбыз Н. Исәнбәт әйтергә теләгән фикерләрне биреп җиткермиләр, әсәрләренең җитди мәгънәсен ачмыйлар. Соңгы елларда Г. Камал театры артистлары көче белән куелган «Җирән Чичән» пьесасының үзәк герое, әйтерсең, сакал кашырга рөхсәт алу өчен генә көрәшә. Төп артистның аерым кыланышлары зирәк күренергә тиешле героебызны бер исәр итебрәк аңлата. Кеше көлдерүне алгы планга куйганга, халыкның хакимнәргә белдерергә теләгән чын нәфрәте сизелми диярлек.

Фольклор материалларын җыйган, үзе дә шулар ярдәмендә остарган Нәкый ага Исәнбәт язган әсәрләренең асыл мәгънәсе гасырлар дәвамында саклануын телим мин.

## Тарихлардан килгән хакыйкать

Сөт урнына кан койдың,
Канымны түгеп, ни кылдың?

*«Идегәй» дастанынннан*

«Идегәй» дастанын халыкта ватандарлык тойгыларын саклау, көчәйтү, шул хисләрне данлау максатыннан язылган әсәр дип беләм мин. Милләтебез асыл сыйфатларын югалтуга йөз тоткан бер вакытта аны китап итеп бастырулары, әлбәттә, кирәк иде.

Дастанның башыннан ахырына кадәр кабатланган фикерләр бар. Шуларның берсе: үзара сугышлар бернинди яхшылыкка илтми. Без шул хактагы бер өзекне сочинениебезгә эпиграф итеп тә куйдык.

«Идегәй»нең беренче юлларыннан ук ил байлыкларының сугышлар ярдәмендә дә туплануын күрәбез. Аннан аерым бер кешенең — Котлыкыяның үлеменә бәйле вакыйгалар сөйләнелә.

Үзара шикләнүләр, әләк-чәләк, үч алу, кан коюларны тулы бер чылбыр итә. Кеше арты кеше гомере киселә. Төп геройлар да бер-бер артлы юкка чыга торалар.

Идегәй дә, башкалар да кемгә дә булса хезмәт итәләр, монгол нәселеннән килгән затларны, традиция буенча, тәхеткә куялар, гаделлек белән дан тотсалар да, илгә патша булмыйлар. Дастан ахырында Идегәйгә каршы берләшкән ирләрнең дә чыңгыз икәнлекләре кат-кат әйтелә. Кадыйрбирде өчен кавемдәшләрен саклап калу бик мөһим икәнлек күренә. Идегәй, аның улы, күп вакыт ялгыз диярлек шушы зур көчкә каршы торырга мәҗбүр.

Әсәрдә талау, басып алу сугышларына тискәре бәя белдерелми, геройлар аларны илне саклау, баету, җирләрен киңәйтү чарасы итеп күрсәтә. Шул ук вакытта үзара якын телле кабиләләр арасындагы ызгышлар кискен тәнкыйть ителә, илнең бердәмлеге хуплана. Бу шул чорлар өчен бик табигый була.

Дастанда Идегәй Идел-йортны саклап көрәшүче, аның бүлгәләнмәвен теләүче итеп тасвирлана. Төп герой бер генә ханның да мәңгелек түгеллеген, бу сугышларның илне таркалуга китергәнлеген әйтә:

Ханнан ханны мин ектым,
Хан булып син дә калмассың.
Сөт урнына кан койдың,
Канымны түгеп, ни кылдың?
Казан, Кырым, Аждаркан,
Кунымны сорап купканда,
Ни булганын анда күрерсең!

Идегәйнең: «Сөт урнына кан койдың», — сүзләренең мәгънәсе бик киң. Шуларның берсен мин килгән ханнарның башын чабасы урынга җирле биләрне үтерү хакындагы фикер дип аңлыйм, чөнки Туктамышның Норадын чапкан башыннан сөт акканы хәтергә килә. Ә менә Идегәй һәм башкаларның тамырларыннан кан ага. Норадын үзен изге көндә ике нур ялгануыннан, чын газиз каннан яралган дип горурлана.

Ә бәлки, китерелгән юлларга тыныч тормышта туганлашып яшәү урынына кан түктең дигән мәгънә салынгандыр? Үлгәндә чүккән Кадыйрбирде башыннан да кан чыга бит, югыйсә, ул — шул ук чыңгыз токымлы Туктамышның баласы. Хәер, монда әнкә ягы да исәпкә алына ала.

Вакыйгаларда катнашкан геройларның һәрберсе бераз хаклы да, кайдадыр ялгыша да. Бер нәрсә ачы хакыйкать: аларга, бердәм яшәп, халыкны, зур дәүләтне саклап калдырырлык акыл җитми.

## «Идегәй» дастанында Туктамыш хан һәм Котлыкыя арасындагы вакыйгалар

«Идегәй» дастаны, белгәнебезчә, Туктамыш хан тасвирыннан башлана. Аны иҗат итүче хакимне шактый дөрес сурәтли. Шул заманның барлык ханнары кебек үк, Туктамыш «ил булганга — ил», «яу булганга — яу» була, сугыш вакытында мал, кол туплый. Аның даны «сигез йортка» тарала. Туктамышның данын Төкле аягы, Акбүз аты тагын да шөһрәтле итә. Заманасында тугызынчы йорт иясе Бырлас — Шаһ Тимернең дә кунагы ул, башкаларныкы да. Әмма еллар узган, аның чәчләренә чал кергән, Шаһ Тимер аннан ау лачынын үзенә сорарга җөрьәт иткән, һәм, әлбәттә, кире җавап алган.

Аннан соңгы вакыйгалар Туктамыш ханны нахакка кеше рәнҗетүче итеп ачамы, юкмы? Минемчә, юк. Ау лачыны ничек кенә картайса да, бидаяк чыгара алмый. Башта хуҗасын алдарга теләгән Котлыкыя би соңрак моны үзе дә таный. Үзенең ике хуҗага хезмәт итүе хакында турыдан-туры әйтмәсә дә, бу эшнең Туктамыш ханның картаюы аркасында гына булырга мөмкинлеге турында сүзләре шуны раслый.

Котлыкыя, Төкле Аякны Шаһ Тимергә биреп, ике ил арасында низаг чыгармаска теләгәндер? Ничек булса булган, Туктамыш хан моңа кадәр иң тугрылардан саналган хезмәтчесенә ышанычын югалта. Ул үзенең картаюын, аның тарафыннан чал кош белән чагыштырылуын да күтәрә алмый булса кирәк. Кат-кат әле аның дәвере икәнлекне сүздә раславы әнә шуны күрсәтеп тора.

Туктамышның хансыз калган Сарайны кулына алуы, үзен Чыңгыз дәрәҗәсендә күрүенә каршы да һәм, хан боерыгын үтәп тә, Котлыкыя үз әйткәннәренең мәгънәсен аңлатып бирә. Сәүдәләр, талаулар аша тупланган һәм гомерлек кебек тоелган малның бетеп баруын, кәрваннарның юньләп салым түләмәвен, илнең әкренләп таркалуын әйтә. Ул җавабын:

Бездән ырыс киткәне,
Куштан кошның күчкәне —
Сездән дәүләт киткәне... —

дип тәмамлый.

Туктамышны бу сүзләр тәмам чыгырыннан чыгара, ул Котлыкыя бине мангыттан азган чал татар дип бәяли, үлемгә хөкем итә.

Туктамыш ни өчен бинең баласын да үтерергә фәрман бирә? Узган заманнарда кан үченең көчле булганлыгыннан хәбәрдарбыз. Баланың, исән калса, шул үчне алачагын белә ул. Әсәрдән күренгәнчә, шулай булып чыга да. Нәкъ менә Идегәй Туктамыш ханның башына җитә.

Бер үк вакытта нәсел-нәсәпнең тәмам бетерелүе дә яхшы киләчәк вәгъдә итми. Җантимер Туктамышны әнә шул хакта искәртә. Җиреннән куылса да — халыкның яшисен, Ватанын югалтса да — ил-йорты буласын, илсез чагында да — телен саклый аласын, теле бетсә —

китаплары саклангганны, ата-баба үтерелгәндә балалары яшисен әйтә. Ә менә бишектәге сабые да чабылган илнең иминлеген көтмә: ахыр чиктә хан дәүләтен дә, халкын да югалтачак.

Җантимер безне Котлыкыяның үткәне белән дә таныштыра. Аның бер бабасы сугышчы булган, берсе тыныч кына яшәгән, берсе коллыкка алынган, икенчесе би булган. Димәк, кеше бүген кол, иртәгә би булырга, башкалар белән хакимлек итәргә дә мөмкин. Котлыкыя нәселенең данлыклы булуын, халык тарафыннан хөрмәтләнүен күрәбез без. Аның бабасының бабасы Төкләс Хуҗа Әхмәтне Җантимер әүлияләр пире дип атый. Сөйләгәннәреннән күренгәнчә, дәрәҗәлерәк адәмнең үзеннән кечкенәрәк кешене кичерүе аның олылыгы булып тора.

Ханнар да еш ялгыша. Туктамыш хан Җантимер сүзенә колак салмый, озак еллар дәвамында үзенә хезмәт иткән кешегә җәзаның да бик катысын сайлый: аны тарттыра һәм башын чаптыра.

Ачу каты вакытта кешеләргә хаталык эшләү хас. Котлыкыя би ханның әнә шундый кызган бер чорында үтерелә. Бер караганда, аны хөкем итәрлек сәбәпләр дә бар кебек. Әмма бирелгән җәза үзенең катылыгы белән шаккатыра, шуның аркасында әсәр башында ук патша нәселләренең дәвамчысы Туктамыштан күңел кайта.

Котлыкыя би кыюлыгы, зирәклеге белән истә кала. Алар арасындагы мөнәсәбәтләрне җайлауның юлын таба алмаган Җантимер Кобогылны саклап кала, һәм үзара дошманлык инде яңа буыннар арасында дәвам итә.

«Идегәй» дастаны кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең элек-электән бик катлаулы булганлыгын бөтен нечкәлекләре белән күрсәтә.

ӘДӘБИЯТ

### Фатих Кәриминең «Салих бабайның өйләнүе» хикәясендә табигать тасвиры

Моннан инде бер гасырдан да элегрәк язылган «Салих бабайның өйләнүе» хикәясе, әйтерсең лә, бүгенге тормыштан алынган. Без дә җәйләрен авылга кайта-

быз, бүрәнә өстенә утырган картларның, кичләрен каравыл торучыларның гыйбрәтле хикәяләрен тыңлыйбыз. Авыл янына чегәннәр дә туктала, кызлар белән үртәшүләр дә була.

Җәйге авылның табигате бик матур бит. Аны сүз белән генә тасвирлап бирү дә мөмкин түгел кебек. Ә менә кайбер язучылар аны шулкадәр чынга охшатып сурәтли, син үзеңне әлеге күренешләрнең эчендә кебек тоясың. Ф. Кәримине дә мин шундый язучылар рәтенә кертәм.

Әдип башта ерактан үк мәчете күренеп торган авыл тасвирын бирә. Яз вакыты. «Ялтырап чыккан кояшның нуры, бөтен дөньяны яктыртып, берничә айлардан бирле үлек хәлендә җансыз булып торган табигатькә, ягъни агачларга, суларга, хайваннарга, инсаннарга яңадан җан бирмәктә исә дә, эсселеге илә рәхәтсез итәрлек дәрәҗәдә түгел иде».

Без олы юлны, аның буеннан-буена утыртылган каенлыкны, юлга килеп кушылган сукмакларны, таррак сукмакчыкларны күз алдыбызга китерәбез. Каеннар арасында күләгәлек юлдан атлаучы атлар күренә.

Язучы табигатьне артыграк та тәфсилле тасвирлый шикелле, тик анда барган хәрәкәт тоемлангач, бу сурәтләр ялыктырмый. Без җилнең дә кыйбладан исүен, яфракларның җилбер-җилбер кыштырдавын, чәчәкләрнең дә, гади генә булмыйча, латыйф икәнлеген, ә күбәләкләрнең гүзәл төрдәгеләре генә очуын укыйбыз. Юл һәм аның читендәге бер генә нәрсә дә язучы тарафыннан онытылып калдырылмаган. Ул күпләр өнәп бетермәгән чебен һәм кортларны да сахра матурлыгын арттыра дип исәпләгән!

Туган яклар сурәтләнсен дә, урманы, елгасы булмыймы соң! Без аларны да бер-бер артлы, юлда барган геройларыбыз шикелле үк күздән кичерәбез. Урман буендагы юлдан чабучы кешене дә күреп калабыз.

Язучы тасвирлаган елга ашкынып ага, аның тизлеге зур. Суны аркылы кискән агач күпер, буеннан-буена сузылган әрәмәлекләр...

Авторның шушы матурлыкны ни өчен тәфсилле сөйләве аңлашыла: аның геройлары — шагыйранә күңелле кешеләр, алар хәтта намазны да «җәннәт кебек гүзәл» җирләрдә генә укый.

Хәзерге роман-повестьларда, хикәяләрдә, минемчә, тасвир чәчелебрәк бирелә. Әйтерсең, техника заманы кешесенең бу матурлыкларны озаклап күзәтерлек вакыты юк. Кырыс чынбарлыкны тасвирлаган әсәрләрдә табигать күренешләренә артык тәфсилле тукталынса, ул, бәлки, бер төчелек тә тоелыр иде. Әйе, язучы тудырган күренешләр вакыт агышын тоярга да ярдәм итәргә тиеш бит әле!

Минемчә, элекке заманнарда табигать күренешләренә кагылышлы детальләрне, юлларны бер җиргәрәк туплаганнар. Укучыны матурлык күрергә өйрәткәннәр, үзләре дә шул матурлыкны кәгазьдә тудырырга өйрәнгәннәрдер.

Ф. Кәриминең тыныч холыклы, истәлекләргә бирелүчән, сөйләүгә маһир карты әнә шулай һәр нәрсәгә игътибар итәргә тиеш тә. Аның хикәят эчендә хикәяттәге герое әле яшь, олыларча яшәп калырга ашыкмый. Кызлар белән танышу, гаилә кору бу агымны тизләтәчәк. Әле ул тормышка да яңа гына аяк басып килә. Аңа дөнья кара төсләре белән ачылмаган, үзе кичкән сахра кебек матур. Әлбәттә, егет гомере буе сөячәк кызны да әнә шундый матурлык эчендә генә очратырга, шуның белән бергә кушып яратырга тиеш.

Салихның кыз белән танышуыннан соң тудырылган төрле күренешләр кыскарак, инде күпчелек урын үзара мөнәсәбәтләргә, кичерешләргә, төрле вакыйгаларга бирелә.

Ф. Кәриминең табигать тасвирлары егет белән кыз арасында кабынган мәхәббәтне тагын да матуррак, хыял белән өртелгәнрәк итәргә булыша.

## Ф. Кәриминең «Салих бабайның өйләнүе» әсәрендә үзәк геройга характеристика

Мәгърифәтче язучы Ф. Кәрими Салих бабайны ничек тасвирлый соң? Үзенең мәгърифәтчелек максатларына тугры каламы? Әлбәттә! Аның карты безнең күз алдыбызга итагатьле, ихлас яратучан, кече күңелле булып килеп баса.

Салих бабай — халыкны агартучы ул. Җеннәр турында хикәятләр сөйләгәндә дә, белеп торсыннар, кызыгып укымасलармы дигәндәй, үз заманында язучылар-

га, галимнәргә, алдынгы шәкертләргә таныш булган француз, рус язучыларын искә төшерә. Авылда яшәсә дә, кыяр каравылчысы гына булса да, зур белем алган икән диярсең! Хәер, аны тәмәке чигәргә өйрәткән мәхдүм Салихка бу хакта сөйли ала бит инде. Чынмы, ялганмы, анысы мөһим дә түгелдер. Ф. Кәрими үз заманы укучыларына Э. Золя, А. Дюма һәм башкалар турында мәгълүмат бирә. Алай гына да түгел, безне әнә шул язучыларны үзенең дә укуы белән кызыктыра. Тәрҗемә итәчәген дә әйтеп куя. Гади генә авыл карты сөйләгән мәхәббәт хикәясе дә бик татлы булгач, французларның мәхәббәте бөтенләй әллә нәрсәдер шикелле тоела башлый.

Ф. Кәрими әсәренең буеннан-буена безне тәрбияли. Тәмәке тартуның да начар гадәт икәнлеген әйтә ул, әфьюнга гади кешенең генә акчасы җитмәүне дә белдерә. Болары нигә кирәк соң? Искиткеч тәрбияле, яхшы кешеләрнең дә, яман иптәшләр белән янәшә килгәндә, аларның гадәтләренә өйрәнгәнлеген аңлашу хакына!

Ф. Кәрими матур табигать тасвирларын тудыра һәм безнең зәвыгыбызны тәрбияли. Мәгърифәтче язучылар гомерләрен кешенең әхлагын яхшыртуга багышлаганнар да инде.

## Һ. Такташның «Алсу» поэмасындагы төп фикер

Шагыйрь — баштанаяк үз чорының улы.

*Нил Юзиев*

Такташ катлаулы үсеш юлы үтә. Ул сурәтләүнең төрле алымнарын куллана. Егерменче елларга килеп кергәч, шигъриятькә карата анык бер фикергә килә: «Шигырьдә үгет, нәсыйхәт, сафсата бетәргә тиешле. Яшь күңелләр тасвирлы әсәрләр сорыйлар». Бу хакта ул үзенең «Иҗадиятем турысында» дип исемләнгән һәм әдәби бурычларны ачык чагылдырган өндәмәсендә язып чыга.

«Алсу» поэмасында без бернинди үгет-нәсыйхәт, акыл сату күрмибез, бары тик матур тасвирлар белән очрашабыз һәм үзебез нинди фикерләргә киләбез.

Әсәрнең төп идеясен аерып чыгару — кыен нәрсә. Әгәр нинди дә бер фикер башкалардан аерылып торма-

са, гел ассызыкланмаса, төп фикерләр берничә булырга мөмкин. Андый вакытта бер үк әсәрнең төп фикерен төрле кеше төрлечә аңлый.

Төп фикерне билгеләү өчен, «Алсу» поэмасындагы барлык уй-карашлар белән дә танышып чыгарбыз.

Поэма безне иң элек Алсу исемле шаянрак бер кыз белән таныштыра. Иптәш кызы Газзә аңа шаянлыклары өчен үпкәләгән кебек итенә. Без алдагы юллардан яшьлеккә шаянлык хас булу турында нәтиҗә ясыйбыз.

Кызларга «барабыз» бабай очрый. Ул хәллерәк кешеләр белән чагыштырыла. Без кешеләрнең төрле матди хәлгә ия икәнлеге хакында фикер чыгарабыз.

Шагыйрь тагын Алсуның матурлыгы, шаянлыгы, беразгына усаллыгы хакында сөйли. Башка студентлар да аңа охшагандыр кебек тоела. Җитмәсә, Такташ «студентта акча күплек» турында язып үтә. Без яшьлеккә матди кыенлыклар да зур фаҗига булып тоелмавын күрәбез, яшьлек һәр нәрсәгә өмет белән, шаяру аша карый.

Кызларны өметләндерер нәрсәләр, чынлыкта да, бар шул. Алар белем ала, яшьлекләре «зур елларга туры килгән», аларга сөю-сөелү хас... «Һәр кояшлы иртә» Алсу кебекләр өчен «яңа уйлар», матурлык, бәхетле киләчәк һәм бүгенге белән исерү алып килә.

Яшьлек — үзе бәхет, ди язучы. Зур елларга туры килгән яшьлек — бәхетнең тагын да зуррагы.

Алсу, чыннан да, бәхетле. Аны кайдадыр ире көтә. Ул, үзен алмаштырмаска кушса да, аңа ышана шикелле. Язган хаты да — бер шаянлык кына.

«Ул — үзенә үзе хуҗа бүген», — ди шагыйрь Алсу хакында. Монда сүз кызның шәхси иреге, irekле ил баласы булуы турында да барадыр. Шагыйрь Алсуның кемгәдер хезмәт итмәвен дә асмәгънә белән әйтеп биргәндер.

Бер-берсе белән кушылып киткән фикерләрдән мин Совет иле яшьләренең бәхетле булуы хакында нәтиҗә чыгарам. Әйе, аларның сөяргә, сөелергә, укырга, яңаны төзергә, үзләренчә яшәргә бөтен мөмкинлекләре бар.

Кем белә, бәлки, сез, бу поэмада яшьлеккә, гомумән, бәхет хисе хас дигән фикер үзәккә куелган дип саныйсыздыр.

78

## А. Расихның «Дустым Мансур» әсәренә рецензия

Озак еллар буена татар прозасына үзеннән өлеш керткән, күләмле әсәрләре белән укучы күңелендә калган язучылар арасында Атилла Расих та бар. Ул төрле язмышлы кешеләр, дөресрәге, төрле язмышлы геройлар турында иҗат итә.

«Дустым Мансур» романының үзәгенә тормышның биек киртәләрен атлап чыккан, зур чыныгулар алган Мансур образы куелган. Мансур — гади бер эшче. Язучы безне аның үткән тормышы белән таныштыруны егетнең үсмер чагыннан ук башлый. Ул аз сүзле, бик тыйнак булып күз алдына килә. Хисами абзыйларында ачлы-туклы да яши ул, Габделбәрләргә ялчы булып та йөри...

Язучы карашынча, бары тик хезмәт, шул хезмәт белән яшәгән эшчеләр сыйныфы гына Мансурга дөрес яшәү юлын сайларга булыша, шуңа күрә романда эшкә бәйле вакыйгаларны сайлаган урыннар бик күп.

Әсәрнең башыннан ахырына кадәр Мансурның тормышта үз урынын эзләвен һәм аны табуын күрәбез. Мансур һөнәргә өйрәнә, гашыйк булырга өлгерә, аны яраталар да, аңа хыянәт тә итәләр...

Кечкенә генә бу язмамда мин «Дустым Мансур» романындагы үзәк герой язмышындагы кайбер вакыйгаларны өстән-өстән генә сөйләп чыктым. Китапта башка геройлар да бик күп. Социализм төзүгә каршы төшкән кулаклар, крестьяннан эшчегә авырлык белән күчкән авыл кешеләре, Хәдичәне үзенә караткан шагыйрь...

Романдагы кайбер вакыйгаларны, үзара мөнәсәбәтләрне аңлау бүгенге көн укучысы өчен катлаулырак та, минемчә. Шул ук вакытта әдип аларның һәрберсен укырга кызыклы итеп, матур тел белән тасвирлый.

## М. Җәлилнең «Сандугач һәм Чишмә» әсәрендә яшәү мәгънәсе турында фикер

«Сандугач һәм Чишмә» балладасында табигатьнең ике баласы арасында туган үзара мөнәсәбәтләр искиткеч матур тасвирлана. Ул бик табигый кабул ителә. Без, башка әдәби әсәрләрне укып, кош һәм гөл, кояш һәм ай, кош һәм чишмә кебек образларның мәхәббәт

парларын белдерүен беләбез. Аның тормышчан нигезе бар. Табигатьтә аларны бер-берсеннән башка күз алдына да китереп булмый.

Сандугач өчен Чишмә — сердәш, сөекле. Алар яшь чакларыннан бирле бер-берсенә гашыйк. Чишмә Сандугачны суында коендыра. Кош аңа татлы җырларын бүләк итә. Гомер мәңге шулай узачак, яшәүнең мәгънәсе — сөю-сөелүдер кебек.

Тик бер вакыт Сандугач Чишмәнең болганганлыгын, тынып калганын, боеклыгын күрә. Ул инде дошман агулаган су белән сөеклесен иркәләргә ашыкмый, сусаган ил батыры суын эчәр дип кайгыра.

Чишмә буена туктаган егеткә Сандугач җырлаган җырда да сүз яшәү мәгънәсе турында бара. Былбыл бер-берсен яраткан йөрәкләрне, көрәш батырларын, дан алып килгән үлемне мактый, тугрылыкны, мәңгелек сөюне, чын дуслыкны зурлый. Шагыйрь кешеләрне борчыган сорауларга җавапны коштан әйттерә.

Егетне коткарып, суында сөеклесе җан бирүне Чишмә кичерә алмый. Ул урыныннан күчә, юкка чыга. Сандугач һәм Чишмәнең яшәү рәвеше мәгънәле узган тормышны чагылдыра. Сандугач җырында сөйләгәннәргә үзе дә тугры булып кала.

Бу ике җанны егет үзенә үрнәккә куя. Сандугач данлаганча яшәвен дәвам итә: дошман белән юлбарыстай көрәшә, Ватанын сөя. Әсәр:

Яшәде ул сөеп,
Һәм үләр бер көнне
Нәкъ мәгърур Сандугач
Һәм Чишмә шикелле, —

дигән юллар белән тәмамлана. Димәк, шагыйрь тагын бер кат кешеләргә бәхет китереп, бер-берсенә тугры калып, явызлыкка каршы көрәшеп, Илен сөеп үлгән Сандугач белән Чишмәнең яшәү рәвешен безнең бөтенебезгә үрнәккә куя. Шулай икән, ул, Ил һәм башкалар өчен яшәлгән, бирелгән гомер мәгънәле була, дип әйтә.

# IX сыйныф

ГҮЗӘЛ ГАМЬ

**«Киләчәге бар милләт без,**
**Шәхесләргә бай милләт без»**

*(Г. Саттар-Муллиле)*

Кол Гали, Г. Кандалый, Р. Фәхретдинов, Г. Исхакый, Г. Тукай... Алар — милли горурлыгыбыз. Бу исемлекне дәвам итсәк, без, һичшиксез, Ш. Мәрҗани исемен дә атарга тиеш булырбыз. Әлеге олуг шәхеснең халыкның милли аңын тәрбияләүдә өлеше әйтеп бетермәслек зур.

Мәрҗани — Шиһабетдин хәзрәтнең ерак бабасы нигезләгән авыл исеме, әдипнең шуннан алынган тәхәллүсе, фамилиясе дә. Аның әтисе Баһаветдин дә, бабасы Сөбхан да — тирә-якка дан тоткан хәзрәтләр. Атасына, белемлелегенә хөрмәт йөзеннән, хәтта Бохара әмире бүләкләр җибәрә торган булган!

Мәрҗани үзе белән бергә уйнап үскән иптәшләреннән һәрвакыт аерылып торган. Уеннар уйлап чыгарып, аларга да өйрәткән. Кечкенә вакытында кош-кортларны бик яраткан, аларны күзәткән, тормышларын өйрәнгән. Олы кешеләрне дә ышандырырлык төрле шаярулар оештырган.

Аның «җен күрсәтеп» уйнаулары, елгада салда йөзүләре турында хатирәләр сакланган. Авылдашлары аны сабантуй батыры буларак та искә ала. Аның «Көрәшче Шиһап» дигән аты бөтен Казан артына таралган. Ул инде 12-13 яшьләрендә үк «Намаз ничек кылына?» дигән китап язган.

Үсмер Шиһабетдин дин белән кызыксына, гомерен китаплар уку, төрле мәсьәләләргә әңгәмә кору белән уздыра.

Күп вакыт кешенең бала чактан ук кем буласы ачык күренә. Мәрҗанинең бөтен тәрбиясе кыюлык, батырлык, тапкырлык, гыйлем, әхлак белән аерылып торган шәхес формалаштыруга юнәлтелә.

Башта — үз Ватанында, соңрак Бохарада белем алган, шунда мөдәррислек тә иткән Мәрҗани анда дөнья-

ви фәннәрдән белем бирелмәүгә, наданлыкка таң кала, уку-укыту эшләренә төрле үзгәрешләр кертмәкче була, әмма үзен аңлау тапмый. Күп кенә татарлар, аның сүзләренә колак салып, белемне Төркиядә, гарәп илләрендә ала башлый.

Ш. Мәрҗани кая барса, кайда укыса, кайда хезмәт итсә, аңа юлыккан һәрбер милләт кешесе, талантына, акылына, белеменең тирәнлегенә таң калып, андый затларны очратканы булмавын әйткән. Ул һәр җирдә татар кешесенең исемен югары йөрткән, милләтенә хөрмәт уяткан.

Олуг мәгърифәтчебез, Казанга кайткач, чын-чынлап белем тарату, китаплар язу эшенә керешә, әмма көнчел холыклы адәмнәр аның юлына гел киртәләр корып куя. Укыту программаларын үзгәртү омтылышлары да зур уңышлар алып килми, ул инде мәдрәсә программалары эчендә дә чит мәгълүмат бирергә, дөньяви фәннәр ирешкәннәрне башкаларга да белдерергә тырыша. Күпчелек шәкертләрнең боларны ишетергә дә теләмәвенә гаҗәпләнә. Ул борынгы фольклордан, тарихтан бик хәбәрдар була. Кызганыч ки, шул белеменә шәкертләрдә ихтыяҗ таба алмый.

Еллар үткәч тә, Ш. Мәрҗани туплаган, үз акылы белән ирешкән белем тирәнлеге белән шаккатыра. Үз заманында исә бары тик алдынгы карашлы, белемгә омтылышлы яшьләр генә аны остазлыкка сайлый һәм башлаган эшләрен дәвам итәргә алына.

Кайбер мәгълүматларга караганда, Ш. Мәрҗани мәдрәсәсендә 200 дән артык мулла җитешә. Алар арасында соңрак шулай ук белемнәре, хезмәтләре белән дан тоткан Хөсәен Фәезханов, Әхмәт Латыйф хәзрәт һәм башкалар бар.

Ш. Мәрҗани язган китаплар дини мәдрәсәләрдә бүген дә дәреслек сыйфатында файдаланыла. Дөньяви мәктәпләрдә укучылар да ул язганнарны беләләр. Ш. Мәрҗани калдырган бай мирас һаман да халыкка хезмәт итә, милләтен, тарихын сөюче уллар тәрбияләргә булыша.

### Ил хәтере — вакыт күпере

Үз заманында милләтен күтәрү өчен гомерен биргәннәр дә бер хаксызга онытылырга мөмкин. Кайвакыт эшлә-

гән, кылган анықы янында кечкенә генә булып тоелса да, икенче берәү тарихка кереп кала. Ерак бер илдә әллә кайчан ачылганга Европада әле яңарак кына ирешкән ниндидер галим фән тарихына шул ачыш иясе буларак теркәлә.

Кызганыч ки, фәнни ачышларда кайчандыр Көнбатыштан бик алда атлаган Көнчыгышка игътибар гел аз булды, яисә аны күрергә теләмәделәр. Югыйсә, Җирнең түгәрәклеген, Кояшның аның тирәсендә әйләнүен әйткән Сәйф Сарайлар исемен бөтен дөнья белергә тиеш иде кебек. Хәер, бәлки, әле ул да бу хакыйкатьне үзеннән элгәреләрдән алгандыр...

Кайвакыт тарих андый зур шәхесләргә мәрхәмәтләнеп тә китә. Г. Исхакый исеменең яңадан телебезгә кайтуы, иҗатының галимнәребез тарафыннан икенче кат югары бәяләнүе җанны җылыткыч бер вакыйга булды.

Ил хәтере — вакыт күпере. Халык шулай ди. Бу әйтемне Гаяз Исхакыйга мөнәсәбәтле дә кулланырга мөмкин. Ярты гасырдан артык узгач, халык аның исемен хәтерендә кабат яңартты. Хәзерге заманнан үткәнгә бер күпер салынгандай булды.

Без бүген Гаяз Исхакый иҗатын кайтып-кайтып өйрәнәбез, аның, мәгърифәтчелек реализмы әдәбияты баскычларыннан этәрелеп, башкалардан күпкә алдарак, тәнкыйди реализм биеклегенә ирешүен күрәбез. Милләтпәрвәрлегенә, фикерләренең кыюлыгына шаккатабыз.

Г. Исхакый бары тик «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрен генә язса да, исеме татар милләте тарихына, әдәбияты елъязмаларына алтын хәрефләр белән чигеләргә тиеш иде.

Исхакый кайтты. Иң мөһиме: аның белән бергә фикерләре кайтты. Алда аталган әсәрне генә алыйк. Милләтнең чирләрен атаган, аны саклап калу юлларын ачкан бу әсәр әле бүген дә халкыбызга юлкүрсәткеч була ала.

Беренчедән, Г. Исхакый белем алырга, алдынгы карашлар белән коралланырга куша. Артта калган теләсә кайсы милләт хәзер дә алга киткән милләтләргә хезмәт итә, чит илләргә китеп, кара эшче булып яллана, табигать байлыкларын сату хисабына яши. Бу юнәлештә

фәне үскән, яңа технологияләргә хуҗа японнар, немецлар һәм башкалар халкыбызга үрнәк булып тора.

Г. Исхакый безне надан дин галимнәреннән белемлеләрен аерып куярга өйрәтә. Ни дөньяви фәннәрдән, ни юньләп дини тәгълиматтан хәбәрсез бүгенге көн муллалары яшьләрнең исламнан йөз чөерүенә хезмәт итә, халык биргән сорауларга надан җаваплары белән хак динебезне кимсетәләр, дин белән фәнне яраштыра белмиләр. Теологларыбыз исламның чисталыкка, тынычлыкка, белемгә өндәүче бер тәгълимат икәнлеген аңлатыр, яшәү рәвешләре белән үрнәк булырлык дәрәҗәгә җитсеннәр иде...

Безгә рус фәненең зурлыгын, бөеклеген дә аңлау җитми шикелле. Русча сөйләшергә өйрәндекме, без шул милләт баласына әйләнәбез. Күп вакыт фәнен, әдәбиятын, мәдәниятен дә юньләп белмибез, үзебезнекен исә тәмам онытабыз. Рус теле рус мәдәниятен өйрәнүгә хезмәт итсә, ул мәдәният безнең милләтпәрвәрлегебезне көчәйтергә тиеш кебек, югыйсә.

Үзгәрешләр заманы теләсә нинди бушбугазга югары үрмәләү мөмкинлекләре тудырды. Икейөзле галимнәр, милләтенә матди ярдәм күрсәтмәсә дә, «курчак туйлары»ның бер формасы булган төрле шоуларга акча кызганмаган байлар, азгынлыкның төбенә төшеп, йогышлы авырулар тараткан кызлар һәм башка рухи чирләгән затлар турында язмыймыни әдип?!

Г. Исхакый кайтты. Аның кайтуының кыйммәте — фикерләрендә. Милләтне саклап калу мөмкинлеге калдырылган икенче йөзне башладык. Ул тәмамлангач, Гаяз Исхакый искәрткән инкыйраз килмәсә иде.

## Яңа гасыр башында милләтебезнең киләчәге турында уйлануларым

Милләткә бәяне чор бирә. Ата-бабаларың язып калдырган тарих белән мактанырга мөмкин. Музейларда йөргәндә борынгыдан сакланып калган истәлекләр синең күңелеңә горурлык хисе өстидер. Уйлан: ерак тарихка синең кулың эшләгән бизәнү әйберләре, син сызымын сызган биналар, син төзегән очкычлар, син уйлап тапкан ачышлар, синең спорт рекордларың яисә

язган китапларың, син үстергән акыллы балалар калачакмы? Ул балалар синең белән горурланачакмы? Алар татар милләте исемен йөртәчәкме? Ул милләт нинди хәлдә булачак?

Заманабыз — фән-техника, ясалма җепләр, кеше кулы, акылы иҗат иткән Җир һәм Ай иярченнәре чоры. Шушы ясалма дөньяда ихласлылыгыңны, чиста иманыңны, моңлы күңелеңне, шат елмаюыңны, хезмәт сөючәнлегеңне саклап кала алырсыңмы син, милләтем баласы?! Шушы кара туфракларны, урман шаулаган киңлекләрне, иген үскән кырларны, агуланмаган елгакүлләрне күрерме синең балаң? Син сулаган һаваны сулый алырмы да син эчкән суларны татырмы?

Син аның бәхетле булуын телисеңме? Син киләчәккә нинди хыяллар, нинди күз белән карыйсың? Син ул якты киләчәк өчен ниләр башкардың, нинди яман ниятләргә каршы төшәргә батырчылык иттең? Син Кеше дигән исемне ничек аңлыйсың да башкалар каршында бурычларың барлыгын тоясыңмы? Мине әнә шул сораулар борчый.

Милләтне, хәтта, гомумән, кешелекне ялган бетерә дип саныйм. Үзара мактанышу, чынбарлыкны ялган буяуларда күрсәтү, милләтеңнең проблемаларын күрергә теләмәү ул... Буш вәгъдәләр, эшләнмәгән эшләр, матур докладлар, юкка-барга һаваланулар...

Без шауладык инде, көлә-көлә,  
Халык тыңлап торды, җилкә кашып.  
Матур заманнарга килә-килә,  
Туры сүзне әйтик, горур басып, —

ди Гамил Афзал.

Моңлы без, дәртле без, көчле без,  
Алыплар торалар артында.  
Якты сүз, кыю сүз, туры сүз —  
Чатнатып әйтергә тартынма! —

ди ул икенче бер шигырендә.

Җир-анабыз бүгенге кешедән, буш сүзләрдән битәр, реаль эшләр көтә. Милләтебез үз баласына шәфкать күзе белән карый. «Саклагыз безне!» — диләр алар икесе дә. Киләчәгебезнең имин, матур, бәхетле булуын телиләр.

Мин милләтем яшәешенә өмет күзе белән карыйм. Ул безне үстергән, безгә белем, һөнәр биргән икән, без шул белем-һөнәрләрне аны саклап калуга файдаланачакбыз. Ана телебездә китаплар язарбыз, фәнни ачышларыбызны игълан итәрбез, ул телгә балаларыбызны өйрәтербез. Болар барысы да — безнең милләт каршында бурычыбыз.

Кеше, бишектә тирбәткән, сөтен имезгән анасын бервакытта онытмаган, картлыгында тәрбияли икән, үзен олы юлга чыгарган, моңын, телен, күңел җылысын биргән зур әнкәсен — милләтен дә онытырга тиеш түгел. Андый хис бер мине генә биләми торгандыр. Әнә ни өчен мин милләтемнең бәхетле киләчәгенә ышанам.

Шул ук Гамил Афзал «Инкыйразга каршы» дип аталган бер шигырендә:

Инкыйраз, дисең син, мелла Гаяз,  
Син акыллы егет булгансың.  
Бездә бәхет көткән көннәр аяз,  
Оныклар да яшәр бездән соң, —

ди милләтенең киләчәгенә зур ышаныч белән.

## <u>ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ</u>

### **Мифлар — хыял тудырган дөнья**

Кешеләр — уйларга сәләтле җан ияләре. Шулай икән, алар үзләренең килеп чыгышы, җир ярaтылышы, анда яшәүче җан ияләре, дөньяның зурлыгы, галәм төзелеше турында да элек-электән уйланганнар бит инде. Тамагың тук, өстең бөтен, буш вакытың бар чагында син хыялга чуммыйсыңмыни? Берәр авырлык килсә, башыңа хәсрәт төшсә, тамагың ач калса, инде шул хакта уйлыйсың.

Мин борынгы кешеләрне сабыйлар белән чагыштырам. Чыннан да, алар яшәгән чор Кешелекнең бала вакыты бит. Аягына тәпи басканчы ук, нәниләр әйберләрне тартып, сүтеп карарга тотына, аның белән сөйләшә, тереме, юкмы икәнлеген тикшерә. Инде сөйләшә башлагач, аларның сорауларына җавап биреп өлгереп тә булмый, һәм әлеге сорауларның ни дәрәҗәдә үткен икәнлегенә шаккатасың.

Бала, күрше апаның сыеры ничә литр сөт бирә, дип сорамый, синең кайчан укудан кайтасыңны да тикшерми. Сыер нигә кирәк, чеби каян барлыкка килә, уенчыкның эчендә нәрсә бар, кояшны алып буламы, җирнең иң ерак ноктасы кайда, эттән нигә куркырга кирәк? Сабыйның сораулары әнә шул рәвешлерәк була. Кыскасы, ул әйберләрнең төзелеше, функциясе, иясе, ясаучысы, алардан үзенә янаган куркыныч турында кызыксына.

Борынгы кешеләр дә үзләренең башларын нәкъ шундый сораулар белән катырган. Кояш кайдан чыга? Җирнең хуҗасы кем? Без аулаган аю, куян кемнеке? Ни өчен юлбарыс миннән көчлерәк? Җирнең эчендә ниләр бар? Алар әнә шулайрак уйлаган. Сабый бала куйган сорауларга бик охшаш бит. Балаларга җавапны күбрәк әти-әнисе, алар укыган китаплар бирсә, борынгы кешеләр бу сорауларга җавапны үзләре тапкан, әти-бабалары авызыннан ишеткән.

Дөньяны күзаллау көндәлек тормыш вакыйгалары аркылы барлыкка килгән. Табигать кешене көче белән куркыткан, аны җиңәргә, аннан файда алырга кирәк булган. Бабаларыбыз аңа үз ырудашларына булган мөгамәләсен күрсәткән: куркыткан, күңелен күреп, бүләкләр китергән, аның хакында хикәятләр чыгарган, бу хикәятләрне башкаларга сөйләгән. Кыскасы, бабаларыбыз аны «кешеләштергән», аның хакында мифлар иҗат иткән.

Галимнәр мифларны төрлечәрәк төркемли. «Сүз эчендә хикмәт бар» исемле җыентыкта аларның өч оясы аерып күрсәтелә. Шулардан аңлатмалы мифларның теге яки бу табигать күренешләренең асылын төшендерүе әйтелә. Мәсәлән, бер миф «Ай тотылуның сәбәбе» дип атала. «Җил иясе җил чыгара» мифының атамасында ук җилнең ничек барлыкка килүенә кыскача гына җавап бар.

Кисәтү мифлары безне төрлеияләр белән таныштыра, алар белән мөнәсәбәт корырга өйрәтә, зыянлы яклары турында кисәтә, файдаларын да күрсәтеп бирә.

Борынгы кешеләр дә бала үстергән һәм тәрбияләгән. Алар үзләренә алмашка үсүчеләрнең оста аучы булуын, картайгач, ата-аналарын карауларын теләгәннәр,

балаларына үзләрен кешеләр арасында тоту кагыйдәләрен өйрәткәннәр. Шулай булгач, аларга, акыл бирү өчен, матур-матур хикәятләр уйлап чыгарырга туры килгән. Бу хикәятләр тирә-якны өйрәнү нәтиҗәсендә туган.

Әйтик, «Песи» мифы. Бер яктан, ул бит-кул юмыйча ашарга ярамаганны аңлата. Хәтта песиләрнең дә чисталык сакларга тырышуыннан мисал белән ныгыта. Икенче яктан, матур сүзгә алданмаска, беркатлы булмаска, дошманыңа ышанмаска куша. Кечкенә генә хикәят кебек, ә эченә никадәр мәгънә салынган.

Без мифларның нигә килеп чыкканлыгын беләбез. Яңа туган балалар аларга бик нык ышана. Әлбәттә, әле күп әйберләрдән хәбәрдар булмаган, үзе яшәгән җирдән еракка китмәгән әби-бабаларыбыз да Кешелек яралган бер чорда аларга ышанып караганнардыр, әмма торабара инде ул әдәби иҗатка гына әйләнеп калгандыр.

## М. Кашгарыйның «Диван...»ында мәкальләр

> Мин бу китапны ... хикмәтле сүзләр, сәҗгылар, мәкальләр, шигырьләр, рәҗәз һәм нәсер дип аталган әдәби парчалар белән бизәдем.
>
> *М. Кашгарый*

М. Кашгарый сүзлегендә фольклор үрнәкләре дә, каләм ияләре иҗат иткән әсәрләр дә бар. «Диван...»дагы халык тәгъбирләренең күпчелеген мәкальләр тәшкил итә икән. Аларның тематикасы бик киң.

Төрек филологы Ферит Биртек хезмәттәге мәкальләрне 30 тематик төркемгә бүлгән. Үз галимебез Хуҗи Мәхмүтов «Мәңгелек ядкяр» исемле китабында татар укучысын да әлеге бүленеш белән таныштыра. Болар: телсүз, намуслылык-әхлаксызлык, дин-инану, мәхәббәт, кеше-гомер, начарлык, хезмәт, киңәш, бердәмлек, файда, мал, мохтаҗлык, егетлек, хәйлә, кайгы-сөенеч, туганлык, хатын-кыз, хакимлек, эрелек, масаю, хаталык, саклык, хайваннар, кунак, гореф-гадәтләр, бәхәс-көрәш, уйлап эш итү турындагы мәкальләр. Татар халкында хәзер кулланышта йөргән мәкальләрне дә шулай төркемләп булыр иде.

Мәкальләр — чор җимеше. Димәк, аларның байта-

гына тарихи-иҗтимагый эчтәлек салына. Моннан бик күп еллар элек төзелгән «Диван...»да да ханнар, бәкләр, феодал җәмгыятьнең башка сыйныфлары турында үткен фикерләр байтак.

Байлыктагы тигезсезлек хакындагы мәкальләр бүгенге көннәргә кадәр килеп җиткән. «Ачның хәлен тук белми», — дибез без. «Ач ни ашамас, тук ни сөйләмәс» — монысы М. Кашгарый сүзлегеннән алынган мәкаль.

Чик-чаманы белмәүче танышларыбыз хакында: «Авызы ашаганнан күзе оялырлык», — дип әйтәбез. Баксаң, М. Кашгарыйда да шундый ук мәкаль бар икән: «Агыз йисә, көз уйадыр».

«Аюның хәйләсе аучыныкыннан күп» дигән мәкальне хәтерлисезме? М. Кашгарыйда ул болайрак яңгырый: «Аучы ничә ал белсә, адыг анча юл белер». Бу — хәйләгә каршы корылган хәйлә хакында сүз йөртүдер инде.

Икътисади кыен заманда кешегә бурычын түләмәүчеләр бик күп, шунлыктан «Кулың белән бирерсең, аягың белән алырсың» мәкале бик популярлашты. М. Кашгарый заманында да шулай ук булган икән. «Алым кеч алса, адакланур», — дип теркәгән ул.

Гаилә, ата-ана һәм балага кагылышлы мәкальләр дә гасырлар кичкән. Без «Диван...»нан баланың ата-анасына охшавы турында мәкаль-әйтемнәргә охшаш мәкальләрне китерә алыр идек.

М. Кашгарый туплаган байлык безне кешеләр арасында кешечә яшәргә, әдәп сакларга, тормышны дөрес корырга өйрәтә. «Кот билгесе — билиг». Әлбәттә, белем — бәхет билгесе. М. Кашгарый теркәп калдырган мәкальләрне белү һаман да файдалы. Ул халык уйлап чыгарган тапкыр фикерләрне китапның бер матурлыгы санаган, чөнки алар — телебезнең бизәкләре.

ӘДӘБИЯТ

### Алтын Урда чоры — татар әдәбиятының Яңарыш чоры

Алтын Урда дәүләте шәһәрләре, һөнәрчеләре, сарай җырчылары, шагыйрьләре, галимнәре белән дан тота. Ул заманнардан язма истәлекләр бик аз гына сакланса

да, әнә шул әдәби ядкарьләр генә дә чынбарлыкта иҗат ителгән мирасның бинигая зурлыгын күрсәтә.

Әдәбиятның югарылыгы, әлбәттә, илнең икътисади, мәдәни үсеше белән билгеләнә. Төрле мәмләкәтләр белән тыгыз бәйләнештә яшәгән, үз эченә бик күп халыкларны берләштергән империянең күтәрелеш чорында язма әдәбиятның бай булуы шик тудырмый. Бүгенге көннәргә килеп җиткән үрнәкләр белән танышкач, аларның поэтик камиллегенә, шагыйрьләрнең телсурәтләү чаралары белән оста эш итүенә, шигъри фикерне бик үтемле җиткерүенә шаккатасың.

Бу заман әдәбиятын галимнәребез Яңарыш чоры мирасы буларак бәяли, чөнки ул вакытта бик күп жанрлар яңарып киткәндәй була, әдәбият яңа жанр формаларына байый. Хикәят, дастаннар, шигъри романнар языла, касыйдә, газәл һәм башка шигырь төрләре чәчәк ата.

Алтын Урда чорында яшәгән иҗатчыларның күплеге дә үсеш-үзгәреш хакындагы фикерне дәлилли булса кирәк. Болардан тыш, әдәбиятыбызның идея-тематик яктан да баюын әйтеп узыйк.

Шулай ук Яңарышның бер баскычы булган һәм Алтын Урда мирасының нигез ташларыннан саналган болгар-татар әдәбиятыннан «Кыйссаи Йосыф»ны искә төшерик. Әлеге әсәрдә кешенең камиллегенә дан җырлана, камиллеккә омтылу аша кеше Аллага да якыная, пәйгамбәрлеккә, бәхеткә ирешә. Камил зат Җирдә камил дәүләт төзи.

Бу фикерләр, әлбәттә, яңа заман иҗатчыларының язганнарына да үтеп керә һәм заман шартларына бәйле рәвештә үстерелә. Рабгузыйның «Кыйссасел-әнбия»се дә пәйгамбәрләштерелгән шәхесләр турында язмыймыни?! Монда мөселманнарның изге китабы Коръәннән алынган сюжетлар тагын да күбрәк, фикергә дә урын киңрәк.

Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәре, «Кыйссаи Йосыф» кебек үк, шигъри роман формасында язылган. Анда кешене Галәмнең олуг заты дип санау күзәтелә. Харәзми инде яшәүнең, дөньяның матурлыгын тагын да ныграк, тормышчанрак күрсәтә.

Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә Солтан»ында да, башка

бик күп әсәрләрдә дә шул заманның атаклы хөкемдарларына кагылышлы фикерләр бар. Аларның да, уйдырма геройларның да язмышы авторларга бирелгән гомернең кыскалыгын, яшәү мәгънәсен аңлатырга ярдәм итә.

Әхмәд Үргәнчи иҗатына тукталсак, анда да заманга хас социаль-иҗтимагый проблемаларның күтәрелүен, автор кулланган детальләренең тормышчанлыгын күрербез.

Кыскасы, Алтын Урда чорында, гомумән алганда, әдәбиятның тормыш белән бәйләнеше тагын да арта бара. Бу да аның яңарыш кичерүе турында фикер йөртергә чираттагы бер сәбәп булып тора.

Узганда тудырылган мирасның, Көнчыгыш классикасының традицияләрен ныклап үзләштергән Алтын Урда әдәбияты иҗатчылар өчен зур мөмкинлекләр туган шартларда иркен сулыш алгандай була.

## С. Сараи иҗатында чагылыш тапкан эхлакый-этик таләпләр җыелмасы

С. Сараиның «Гөлестан бит-төрки» әсәре шигърияте белән бөтен дөньяга дан тоткан Сәгъдинең «Гөлестан»ына нигезләнгән. Фарсы телендәге ядкарь дә, «Төркичә Гөлестан» да мәктәп-мәдрәсәләрдә хрестоматия рәвешендә кулланылган, аны шигъри тел белән язылган педагогик хезмәт дип тә санаганнар. Каюм баба Насыйриның «Тәрбия китабы»на ни өчен әлеге әсәрдән хикәятләр кертүе аңлашыла булса кирәк.

«Гөлестан» — шигырь һәм прозаны аралаштырып язган әсәр. Китапка тупланган хикәятләр тематик яктан бик киң, шунлыктан алардан чыккан гыйбрәтле нәтиҗәләр дә күп. Кешенең җәмгыятьтә үз-үзен тотышына кагылышлыларын бергә тупласаң, әхлак кагыйдәләре җыелмасы килеп чыгар иде.

Шәхес яшәгән тирәлек гомер-гомердән гаилә, дуслар, хезмәт һәм уку урыны, ул яшәгән урын һәм хәтта ил белән билгеләнә. Димәк, шагыйрь ата-ана белән бала, дуслар, күршеләр, остазлар һәм укучылар, хезмәт урыны белән тәэмин итүчеләр һәм хезмәткәрләр, хөкем ияләре һәм гаепләнүчеләр, аерым бер чорда хакимлек итүчеләр белән буйсынучылар арасындагы мөнәсәбәт-

ләрне җайга салырга алына. Әле бу исемлекне тагын да дәвам итәргә булыр иде.

Солтаннарга, изгеләргә кагылышлы бер хикәятне искә төшерик. С. Сараи, ике кеше — патшалыкның һәм диннең дошманыдыр, ди. Аның берсе — гадел булмаган солтан, чөнки патшалыгын таратыр. Икенчесе — надан заһид, аңа ияргәннәр диннән язар.

Шагыйрь иҗат иткән хикәятләр арасында барлык кешеләргә дә аталган нәсыйхәтләр, хикмәтләр күбрәк, минемчә. Шуларның берсендә менә мондый юллар бар:

«Ул эш кем күңелләрне рәнҗетер, син аны эшләмә, башкалар эшләсен.

Әйа килгән җиһанга, игелек ит,
Йаман эшләрне йаманнарга куеп кит».

Әйе, кешеләргә, кем булуларына карамастан, ниндидер уңай һәм кимчелекле сыйфатлар хас. Алар дөрес, җиңел яшәргә, авырлыкларны җиңеп чыгарга булышырга яисә комачауларга мөмкин. С, Сараи әнә шуларны да истән чыгармый, аерым бер хикәятләр аркылы укучыга гыйбрәт бирә, әсәрләрен тематик яктан бергә туплый. Мин кайвакыт хәтта эндәшми торуның файдасы барлыгына аның хикәятләре аша ышандым.

Дөньялыкта эшләнми калдырган изгелекләр кешене мәңгелеккә киткәндә үкенечле итә. Китаптагы иң соңгы хикмәт, минемчә, иң гыйбрәтлесе:

«Ике кеше дөньядан хәсрәт һәм үкенеч белән китә. Берсе — җыеп та ашамаган, икенчесе — белеп тә кылмаган».

Бу хикәятне һәркем үзенчәрәк аңлыйдыр. Кемдер сүз файдасызга җыелган мал һәм тиеш урында эшләнмәгән игелек турында дип уйларга мөмкин. Икенче берәү саранлык һәм дини гамәлләр кылмауны тәнкыйть итү дип тә карар. Хикәяттән башка мәгънәләр дә чыга, һәм аларның һәрберсе хак.

Хикәяттән соң китерелгән шигырь аның мәгънәсен үзенчәлекле ачып җибәрә:

Нигъмәте күп саран изгене
Ил даим шелтә утына алыр.
Мең гаепле сәхи ирнең
Бер гаебен дә күрмәс.

С. Сараи әсәрләрендәге бик күп хикмәтле сүзләр мәкаль-әйтемнәр рәвешендә бүгенге көндә дә кулланыла, алар халык педагогикасының нигезен тәшкил итәләр.

«Патшалар тормышы турында»гы бабның 3 хикәятендә кечкенә буйлы бала, атасының мыскыллы карашын тойгач, болай дип җавап бирә: «...озын буйлы ахмактан кыска буйлы акыллы яхшырак торыр». Белгәнебезчә, угылның сүзләре бүгенге көндә дә киң кулланылышта.

Шушы ук хикәятнең ахырында бер илгә ике солтанның сыешмавы турында әйтелә. Без аны да, анықына охшаш мәгънәне җиткергән «бер казанга ике тәкә башы сыймый» мәкален дә беләбез. Икенчесендә сүз гомумәнрәк, ул бер җирдә ике хуҗа булмауны белдерә.

Китерелгән өзекләрне мин, үз аңлавымнан чыгып, бүгенге телебезгә күчердем. С. Сараи әсәрләренең һәрберсен дә уку, аңлау җиңел түгел. Мин аларның барысының да мәктәп укучысына аңлашылырлык хәлгә китерелеп бастырылуын теләр идем. «Төркичә Гөлестан» ул чагында безгә менә дигән тәрбия китабы булачак.

## Утыз Имәни иҗатында гыйлем-мәгърифәт темасының чагылышы

Утыз Имәнине халкыбыз тарихында — бөек шәхес, шигърияттә — яңа сүз әйтүче каләм иясе, иҗтимагый фикер тарихында яңа карашларга күпер салучы дип таныйлар. Утыз Имәни тудырган байлыкның татар мәгърифәте, матур әдәбияты өчен никадәр кыйммәтле булуын торган саен ныграк аңлыйсың, шуңа да карамастан аның иҗаты, тормышы турында хезмәтләр бик азлыкка көенәсең.

Язучыны, шагыйрьне, укыган саен, яңача ачасың, юлларга салынган мәгънәләрне башкачарак күрәсең, аларны кәефеңә бәйле рәвештә дә төрлечә шәрехлисең. Шул ук вакытта каләм иясенең аерым бер карашлары һәрвакыт күзеңә ташлана. Әгәр ул үзендә әлеге карашларның ныклы бер системасын булдырган, аны иҗатында чагылдырган икән, моны күрми калырга мөмкин түгел.

Утыз Имәнинең зур мирасында шактый урын гый-

лем-мәгърифәт мәсьәләләренә бирелгән. Аның Мәрәс авылында табылган бер кулъязмасында мондый юллар бар икән:

«Китаплардан бер аять үгрәнмәк синең өчен йөз рәкагать намаз кыйлмактан хәерледер. Вә дәхи гыйлемдин бер баб үгрәнмәк, аның илән гамәл улсын, кирәк улмасын, синең өчен бең рәкагать намаз кыйлмактан хәерледер».

Әлбәттә, Аллага ышанган, намазын укыган Утыз Имәнинең бу сүзләре аптырашта калдырырга мөмкин, кемгәдер шагыйрь дәһри дә булып күренер. Шулай икән, бу — ашыгып уйлаулар нәтиҗәсе. Беренчедән, элекке заманда китапларының да күбесе — дини эчтәлектә. Аларны уку — шул ук динилегеңне дә арттыру ул. Икенчедән, дини һәм дөньявилыкны бергә кушкан әсәрләрдә төп урын барыбер әхлак тәрбияләүгә бирелә. Син намаз укыгандагы кебек чистарынасың, күңелең белән Аллага якынаясың. Өченчедән, ислам дине тәгълиматы үзе дә белем җыюны, китап язуны изге гамәлләргә тиңли. Димәк, Утыз Имәни әйткәннәр, эшләгәннәр аның динилеге белән каршылыкка керми.

Борынгы шагыйрьләр, шул исәптән Утыз Имәни дә белемне ике дөнья өчен дә кирәк дип санаган. Гыйлем тормышны яхшыртырга, мөнәсәбәтләрне җайларга, акыл белән яшәргә өйрәткән. Аның аеруча дини эчтәлектәгесен туплау зур савап булган. Ул ахирәтне, дөнья, Кеше яратылышын үзенчәлекле күзалларга булышкан. Дини өйрәтмәләр кушканча яшәү гөнаһтан ерагайткан, җәннәт юлына якынайткан, кеше күңеленә тынычлык алып килгән. Аның бу фикерләре бигрәк тә «Гаварифез-заман» поэмасында ачык чагыла.

«Гыйльмилә булды сәгадәт», — ди Утыз Имәни һәм белем туплау яшәү рәвешенең иң асылы дип исәпли. Кешене данлаучы гыйлемне угры да, дошман да ала алмау хакында бик гыйбрәтле юллар яза.

Утыз Имәни — мәгърифәтче каләм иясе. Ул кешенең әхлагы гыйлеменә бәрабәр икәнлекне әйтә. Гыйлемле кешене ай, йолдызларга тиңләве аның бер шигъри табышы булып тора.

Гыйльмилә бостан улисәр ничә чүл...

Югарыда китерелгән юллар — кеше акылының чүлдән бакчалар ясавы хакында. Утыз Имәни көн күрергә булышкан, халыкның күзен ачкан белемне аеруча кирәкле саный. Галимнәрнең җыйган мәгълүматларын халыкны агарту юлында кулланырга тиеш икәнлекләрен әйтә:

Чөнки галим халыкның гыйльмен ачар,
Мөшкел улмыш хәлләрең юлын ачар...

Мәгърифәт турында язганда, шагыйрь антитеза алымын куллана, белемлелекне наданлыкка, галимне җаһилгә каршы куя, һәрдаим аларны үзара чагыштыра:

Үлмәя галим кеше, килсә үлем,
Үлде җаһил килмәзидин бу үлем...

Шагыйрь надан һәм галимнең теге дөньядагы урыннарын да алдан ук билгеләп куя. Аның берсе җәннәткә керәчәк, икенчесе ахирәттә эт көненнән дә начарракка калачак:

Җаһил улан гокбада (ахирәттә) эттин яман...

Утыз Имәни үз шигырендә кеше камиллеге мәсьәләсен күтәрә. Безнең әдәбиятыбызда инде ул «Кыйссаи Йосыф» поэмасыннан ук бер традиция булып килә. Шәхес ничек камилләшә дигән сорауга Утыз Имәни мәгърифәтче буларак җавап бирә:

Мәгърифәттин бер ула эчең-тышың.

Димәк, гыйлем эстәү кешенең рухын да, тышкы кыяфәтен дә матур итә, бер-берсенә тәңгәлләштерә.

Утыз Имәнинең, бүгенге телебезгә күчереп әйтсәк, «Гыйлем вә гакылның өстенлеге турындагы бүлек» шигыре дә, исеменнән үк күренгәнчә, мәгърифәт темасына багышланган. Анда ул тагын бер кат гыйлемнең халыкка хезмәт итәргә тиешлеге хакында фикерен ассызыклый. Белемле кешене тирәлек, җәмгыять хөрмәт итә дигән караш уздыра. Димәк, белем әле тормышта үз урыныңны табарга да булыша икән.

Дөньяда байлык белән аерылып торган адәмнәр дә бар. Утыз Имәни карашынча, андыйларның бары тик бай-

лыгын гына зурлыйлар, шул ук вакытта әлеге байлык мәңгелек тә булмаска мөмкин. Бер тупланган гыйлем китми, шунлыктан кешеләрнең сиңа карата хөрмәтләре дә үзгәрми.

Гыйлем дәрьясы чиксез. Ул бервакытта да кимеми. Аны алу мөмкинлекләре дә чиксез. Утыз Имәни үз чордашларына шуны да аңлатырга теләгән:

Кимемәс зәррә андин һич нәмәрсә,
Халаек барча андин чук алырса.

## Казан ханлыгы шигъриятендә суфичылык чагылышы

Казан ханлыгы чорыннан безгә килеп җиткән истәлекләр бик аз. Алар яндырылган, юкка чыгарылган. Кайберләрен, саклау өчен, башка илләргә алып киткәннәр, һәм алар шунда җирле халыкның мирасына әйләнгәндер дип уйлыйм мин. Аларның милли байлыгыбыз икәнлеген шигырьләрдә билгеле бер мәгълүмат сакланганда гына исбатлау мөмкин.

Бүгенге көнгә килеп җиткән ядкарьләр шул заман әдәбиятының үсеш дәрәҗәсе югары булуын күрсәтеп тора. XV-XVI йөздә иҗат иткән шагыйрьләр арасында Казтуган чичән, Хәсән Кайгы, Чалгиз җырау, Мөхәммәд Әминне телгә алырга мөмкин.

Колшәриф — шул заман каләм ияләренең бик күренеклесе, минемчә. Аның мирасы чагыштырмача күбрәк сакланып калган.

Барыбызга да таныш «Бакырган китабы»на Колшәрифнең биш әсәре кертелгән. Шуларның беренчесе — мәгърифәткә өндәү шигыре.

Башың күтәр гафләтдин,
Гафил торма, «һу!» — тигел,
Күзең ачкыл ойкыдин,
Гафил торма/«һу!» — тигел, —

дип башлана. Әлбәттә, руханилар башлыгы Колшәриф гыйлемне дини, Аллага якынайтучы белем буларак та аңлый:

И Колшәриф, тынмагыл,
Төннәр ятып оймагыл,

Хак зикрене куймагыл,
Гафил йөрмә, «һу!» — тигел.

Колшәриф шигырьләрендә бераллалык, шайтанны кире кагып, аңа табыну, аның рәхим-шәфкатенә өметләнү фикере көчле. Бер шигырен ул «Галәмнең Раббысы Аллаһка мактаулар» дип башлый, Коръәннең бөеклеген, кирәклеген раслый.

И күңел, бил баглама, күпне кичергән дөньядыр,
Бу үлем ширбәтен халыкга эчергән дөньядыр, —

дип яза ул икенче бер әсәрендә. Анда гомернең кыскалыгы, вакытлы булуы турында бик тәэсирле сүзләр бар.

«Хакыйкать чын гашыйклар» дип башланган әсәр ахырына кадәр суфичылык белән сугарылган. Анда сүз Аллага гашыйклыктан мәҗнүн хәленә килгәннәр турында бара. Шагыйрь алар арасында суфи шагыйрь, йөздән артык поэмасы белән Көнчыгыш әдәбияты тарихына кереп калган, Чыңгыз ханны мактап язмаганы өчен җәзалап үтерелгән Шәйх Гаттарны, Урта гасырларда дәрвиш буларак танылган Боһлулны, үзен Аллаһе Тәгалә белән кушылган санау хәленә килгән, шулай ук һәлак ителгән Шәйх Мансурны, XIII йөзнең атаклы суфи шагыйре Шаһ Борыкыйны һәм башкаларны саный. Колшәрифнең аларның барысын да дивана дип атавы Аллага мәхәббәттән исереклекләренә ишарә булып тора. Шул ук вакытта дивана төшенчәсе диндарлыкта камиллеккә ирешкән, экстазда яшәүче кеше буларак та аңлашыла.

Колшәриф суфи шагыйрьләр иҗатына хас образларны куллана. Гадәттә, суфилар үз яшәүләрендә кемне дә булса раһнәм итә, Аллага якынаюда юл таныклыгы саный. Колшәриф тә бу төшенчәне ике мәртәбә кабатлый.

Шәйх Мансурның үзеңне Аллаһе Тәгалә дип белдерергә батырчылыкны, «гыйшк көфрен иман итү» дип, бик үзенчәлекле гыйбарә белән атый.

Монда гыйшк багы, рух Дөлделе кебек традицион образлар бар, алар барысы да Аллага мәхәббәтне ачу өчен кулланылганнар. Бүгенге шагыйрьләребез иҗатында ут һәм күбәләк образы еш очрый. Гашыйк кеше утта ян-

ган күбәләккә тиңләштерелә. Суфи шагыйрьләр, шул исәптән Колшәриф тә әлеге образлар белән Алланы һәм аңа чын күңелдән бирелгән колларын атый:

Шәвкъ утыга парванә...

Шаһ Борыкыйны «Хакның кавышкан былбылы» дип белдерә ул. Колшәриф хәтта Мөхәммәд пәйгамбәр заманында ук яшәгән Вәйсел-Каранины да телгә ала. Ул бу әсәрендә суфичылыкның ерак гасырлардан килүен, көчле бер хәрәкәт, хис булуын да күрсәтә. Шигырьдә телгә алынган шагыйрьләрнең берничәсе, гомерләрен Аллага багышлауларына карамастан, язганнары, әйткәннәре аркасында, денсезлектә гаепләнгәннәр һәм үлем җәзасы алганнар.

Колшәриф хак: дини белемнән дә исерергә, Алланы сөюдән дә янарга мөмкин. Ул үзен дә әнә шундыйлардан саный:

Мәгърифәткә кол булган,
Гыйшкта янып көл булган,
Талипләргә юл булган,
Кол Шәрифи дивана.

### Татар поэзиясендә әхлак проблемасы

Әхлак проблемасы — хәзерге вакытта иң актуаль мәсьәләләрнең берсе. Бик борынгыдан ук иҗтимагый фикер аны чишүгә юнәлтелгән. «Бу тенденция тәүге ядкарьләрдән алып Урта гасырларның ахырларына кадәр булган болгар-татар культурасының барлык вәкилләренең мирасы аша кызыл җеп булып сузыла», — дип яза Я. Абдуллин «Мәгърифәт нуры ачар» хезмәтендә.

Алда әйтелгән фикерләрне дәлилләү максатыннан, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ын, Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки»ен, «Кисекбаш»ны, Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан», «Нуры содур» кебек әсәрләрен искә төшерик. Аларның барысында күркәм холыклылык, кешеләргә авырлык китермәү, гаделлеккә хезмәт итү әхлаклылык чагылышы итеп карала. Эче камил кешенең тышкы кыяфәте дә матур була, яисә Тәңре аны берчак шул матурлыкка ирештерә.

Сүзебезне тәгаенләштереп, шулардан «Кисекбаш» әсәрендәге Гали образына бәйле рәвештә уздырылган кайбер карашларны әйтеп узасы килә. Бихисап диюләрнең башын өзеп, адәми затларны тыныч тормыш белән бүләкли героебыз. Мифик затларның малын тоткынлыктан азат ителгән халыкка өләшә. Дога укып, коега төшерелгән кешеләрне җир йөзенә күтәрә. Галидә юмартлык, олуглык, вәлилеккә чикләр юк сыман. Аның белән хәтта Тәңре үзе горурлана, аны «Арысланым» дип атый. Димәк, геройның сыйфатлары әхлаклылык, бөеклек билгесе итеп карала.

Галинең ярдәме тигән Кисекбашның да әхлак сыйфатлары үрнәккә куярлык. Ул Алла турында уйлап кына яши, илле тапкыр хаҗга барган, ятим-ялангачка хәер өләшеп яшәгән. Хатынын, улын яраткан. Бераздан ул кабат кеше кыяфәтенә керә, хатыны, улы белән очраша. Күрәсез, бу чор әсәрләрендә диндар, ярдәмчел затлар әхлакый үрнәк буларак бәяләнгән, аларга Аллаһе Тәгалә үзе рәхим-шәфкать күрсәткән, төрле авырлыклардан чыгарга булышкан.

XIX йөзнең икенче яртысында, мәгърифәтчелек хәрәкәте формалашу шартларында иҗат иткән Мифтахетдин Акмулла язганнарны барлап чыгыйк. Аның иҗатының үзеннән элгәреләрнекеннән аермасы шунда: күтәрелгән мәсьәләләре мәгърифәтчелек идеяләре белән тыгыз бәйләнештә чишелгән. Ул кешенең әхлаклылыгын да аның мәгърифәтлелеге белән бәйләп караган. Бер шигырендә бик ачык рәвештә бу хакта әйтелгән түбәндәге юл бар:

Аң-гыйлем адәм эчен керсез итә.

XX гасыр башы шигърияте милләткә хезмәт иткәннәрне югары әхлакка ия кешеләр дип бәяли. Г. Тукай да, Г. Камал да, М. Гафури да, башкалар да риялылыкны, сорыкортлыкны, наданлыкны... көчле тәнкыйть утына ала. Бу чорда шигырьләрнең эчтәлеге тагын да байый, күпчелеге көндәлек вакыйгаларга җавап рәвешендә туа, шунлыктан аларда еш кына әхлаксыз затларның исемнәре атала, яисә алар тоемлана.

XX гасыр башы әдәбиятында башкалар хисабына яшәүче, надан ишаннарга, динчеләргә тәнкыйть аеруча

каты эләгә. Мәсәлән, Ш. Бабич 1912 елда язган «Имеш» исемле шигырендә чалма чорнап, яшел чапан киюнең тышкы билге генә икәнлеген, чын әхлак түгеллеген әйтә.

Үтә тормышчан XX гасыр башы шигърияте инде шәхеснең мәхәббәттә, гаиләдә, җәмгыятьтә, милләт эчендә, халык арасында әхлаклылыгы мәсьәләсен җентекләп карый, иҗтимагый төркемнәргә, сәяси фиркаләргә дә бәясен бирә. Һәр кешенең, һәр төркемнең эше, яшәү рәвеше милләткә китергән файда ноктасыннан тикшерә. Аңа зыян салучылар әхлаксызлыкияләре кебек кабул ителә.

Әйтик, Тукай. Ул башлангыч чор иҗатында — милләтнең мәгърифәтле, әхлаклы анадан тууына, соңыннан ил эчендәге зуррак үзгәрешләргә өмет баглый.

Совет идеологиясе хакимлек иткән шартларда «Коммунизм төзүченең мораль кодексы» булдырылды, әдәбият, шул исәптән шигърият аркылы андагы таләпләр пропагандаланды. Әлбәттә, алар гомумкешелек идеалларын чагылдыра иде. Тоталитар системага нинди генә гаепләр ташласак та, рухи гүзәллеккә, югары әхлакка дан җырлаган совет шигъриятенә рәхмәт кенә белдерәсе килә. Вульгар социологизм шаукымына ияреп язылган аерым әсәрләрне исәпләмәгәндә, һәр шагыйрь иҗаты, нигездә, Илен, Ватанын, халкын, туган туфрагын, кешеләрне, сайлаган ярын, ата-анасын яраткан, алар бәхете өчен яшәгән кешене үзәккә куйды һәм бу сыйфатларны югары әхлаклылык билгесе итеп күрсәтте.

Үзгәртеп кору елларында идеаллар бераз үзгәрде. Милләтне яшәтү фикере алга сөрелә башлады. Инде яңа шартларда халыкка хезмәт итү кабат милли әдәбият тудырган геройларның иң мөһим сыйфаты итеп карала башлады. Телне оныту, тарихка битарафлык маңкортлык дип бәяләнде. Шул ук вакытта язучылар саф сөюне, гаиләгә тугрылыкны, аек яшәү рәвешен пропагандаладылар. Соңгы еллар шигъриятендә әхлаксыз яшәү күренешләренең арта баруына борчылу хисе көчәйде. Наркомания, фахишәлек кебек яман чирләр заманның әхлаксызлык күренешләре дип аталды һәм кискен тәнкыйть ителде. Татар шагыйрьләре безнең милләтебез әхлагына туры килмәгән ул гадәтләр турында чаң суга башлады.

100

Бозыклыкка каршы көрәш уты ачкан шигърият саф әхлак турында җырларга бай булды. Р. Гаташ «Безнең җыр» шигырендә әйткәнчә:

Ул аклык, ул сафлык турындадыр.
Гаҗәпмени өзми кабатласак?

Кешелекнең асыл сыйфаты булган әхлаклылык мәсьәләсе аның яшәү дәверендә шигърият үзәгендә калачак.

### «Бичара кыз» һәм «Рәдде бичара кыз» пьесаларына чагыштырма анализ

*(Г. Ильяси һәм Ф. Халиди иҗаты буенча)*

XIX йөзнең икенче яртысында беренче авазларын салган татар драматургиясе, XX гасырга аяк баскач, нык-лы адымнар белән атлап китә. Сәхнә әсәрләре тамаша яраткан, аларга йөргән татарларның үзаңы уянуында бик зур роль уйный. Китаплар һәркемнең дә кулына барып ирешә алмаган бер заманда театр туу сәнгать аша халыкны әдәбиятка тагын да якынайта. Ә бит милли труппаларыбыз барлыкка килгәнче, беренче спектакльләр куелганчы язылган пьесалар да халыкны сәхнә сәнгатен кабул итүгә хәзерлек эшен башлый торган.

Үз драмаларыбызның тәүге әсәрләреннән саналган «Бичара кыз», «Рәдде бичара кыз», һөнәри театрлар туганчы ук, татар зыялыларының йортында аз күләмдәге тамашачы өчен уйнала торган булган. Кызганыч ки, патша хөкүмәте аның халыкка сәхнәләштерелүенә каршы килгән.

Г. Ильяси һәм Ф. Халиди иҗат иткән бу ике әсәрнең исеме үк үзара чагыштыруны сорап тора сыман. Белгечләр еш кына икенче драматург беренчесенә каршы әсәр иҗат иткән дигән фикерне уздыралар. Мин исә, Ф. Халиди, Г. Ильяси язганнардан этәрелеп китеп, тормыш вакыйгаларына үзенчәлекле караш үткәргән, конфликттан чыгуны башкачарак күрсәтеп бирә алган, дип әйтер идем.

Бу ике әсәрнең охшаш яклары үзара аерып торган сыйфатларыннан күбрәк, чөнки «Бичара кыз» да, «Рәдде бичара кыз» да хатын-кыз бәхете, иреге мәсьәләсен күтәрә, аның шул хокукларга лаек икәнлеген исбатлый.

Г. Ильяси да, Ф. Халиди дә үзләре куйган сорауларга җавапны мәгърифәтчелек күзлегеннән чыгып бирәләр.

Башта «Бичара кыз» әсәрен карап узыйк. Вакыйгалар «бер кара бай кеше» гаиләсе эчендә бара. Ата кызына кияүне дә үзенә охшатып сайлаган: бик бай кешенең ямьсез, аңгыра улы Җантимер ул.

Пьесада кияү егетенә дә, булачак каенатага да урын азрак бирелгән, кыз кичерешләре уртагарак куелган сыман. Ни өчен? Чөнки без Маһитапның язмышын хәл итәбез, бу вакыйгалар ата-ана, «кабахәт» Җантимер тормышын ничек үзгәртәчәк — ул әллә ни мөһим түгел.

Инде Маһитапны авырлыклардан кем коткару мәсьәләсенә килик. Әлеге вазифа актив хәрәкәт итүче Җанбай образына тапшырыла. Шушы ноктадан караганда, үз язмышына битараф булмаган Маһитапка бик тиң ул.

Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз» пьесасы үзәккә башка геройларны куя, шәһәр ярлылары тормышын тасвирлый. Автор бер үк вакыйгаларга нигезләнмәгәч, ничек итеп, Г. Ильясига «каршы чыккан»лыгы хакында әйтәсең?!

Мирза кызы Хәнифә дә үз социаль катламыннан булган кешегә бармый: бай углы Әптем ала аны. Димәк, Ф. Халиди дә, Г. Ильяси да кешенең юньлелеге байлыгына бәрабәр булмыйча, белеменә бәйле икәнлеген әйтә. Биктимер кебек кара бай кызы Маһитап та яхшы бит!

Бу язучыларны мәгърифәтче әдипләргә хас белемлелеккә, күңел байлыгына табыну берләштерә. Алар икесе дә татар кызларын мәрхәмәтле һәм укымышлы кешеләрнең бәхетле итәчәген әйтә.

## «Бичара кыз» һәм «Рәдде бичара кыз» драмаларының жанр үзенчәлекләре

*(Г. Ильяси һәм Ф. Халиди иҗаты буенча)*

Г. Ильяси һәм Ф. Халиди — сәхнә әдәбиятыбызның чишмә башында торучылар. Алар иҗат итә башлаганда, әле драматургия жанрлары формалашып кына килә, жанр формалары байлыгы күзәтелми.

Татар драматургиясе, нигездә, ике жанр белән аякка баса. Болар: комедия һәм драма. Мисалга «Комедия Чистайда», «Кызганыч бала» әсәрләрен һәм башкалар-

ны китерә алабыз. Телгә алган пьесалар, тәрҗемә әсәрләре булса да, драматургиябез тарихында мөһим урын тоталар, аның этәрелеш нокталары булып торалар.

Г. Ильясиның «Бичара кыз»ы һәм Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз»ы икесе дә драма жанрына карый. Беренчесендә сүз иске гореф-гадәтләр белән яшәүчеләр һәм аның белән ризалашмыйча, тормышны үзләренчә корырга теләгән яшьләр арасында бара.

Драматик конфликтка корылган әлеге пьесада урталыкта калган Фәрихә ханым бар. Кызын да бәхетле итәсе килә аның, ирennән дә артыгын уза алмый. Героиняны иске гадәтләр сакчысы дип атап булмый, туларның корбаны дип карарга кирәктер. Кыз әнисе язмышын кабатламаска тиеш тә инде.

Әсәр ахырында Маһитап һәм аны коткаруны үз өстенә алган Җанбай, каршы көчләрне тәмам мыскыллап, көлке объектына әйләндереп, бик җиңел генә бәхәстә өстен чыгалар.

Мин бу пьесага үзенчәлекле бер жанр формасы дип карыйм, ул драма һәм комедиянең уңышлы синтезын хәтерләтә. Ә нигә аны драмкомедия дип атамаска? Трагикомедия жанры бар ич. Бу атама сәхнә белгечләренең әле хәзер язылган әсәрләр хакында: «Жанр сыйфатлары ачык түгел» яисә «Драмадан узган, комедия булып җитмәгән», «Комедия алымнары уңышлы кулланган драма», «Әсәргә драматик чишелеш уйлап табылмаган» кебек фикер йөртүләренә чик куяр иде.

Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз»ы да — драма. Анда да яшь татар кызының, аның әти-әнисенең үзләрен чорнаган тирәлектәге кешеләр белән мөнәсәбәткә кергәндә килеп туган драматик хәл сурәтләнә. Хәнифәгә димләнгән егет, төрле коткыларга бирелеп, кыздан баш тарта. Җитмәсә, бу вакытта болай да фәкыйрь генә тормышлы Мирзаларның өе дә янып китә. Әнә шул янгын конфликтны уңай хәл итүгә булыша да инде. Янгын вакытында Хәнифәгә күзе төшкән бай улы Әптем аңа тәкъдим ясый. Хәнифә тыйнаклыгы, әхлаклылыгы, белемлелеге аркасында бәхеткә ирешә.

Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз»ы, чыннан да, драма жанрының бөтен сыйфатларына ия. Монда драма-

тик конфликт катлаулырак, чишелешкә юллар да кыска түгел.

Шул ук вакытта икенче әсәрдә дә вакыйгалар тиешенчә җәелеп китә дип әйтеп булмый. Бүгенге көн күзлегеннән караганда, драматик конфликт та гади, ә менә шул чор өчен ул алай күренмәгән, пьеса драматургиябезнең зур уңышы саналырлык булган.

Әлбәттә, гади генә конфликтлы әсәрләр дә укылышлы, тәэсирле була ала. Моңа геройларның күңеленә тирән узу, конфликт тудырган вакыйганың аерым бер кеше язмышында бик мөһимлеген һәм кичерешләр, үзара мөнәсәбәтләр дөньясын бөтен нечкәлекләренә кадәр күрсәтү белән ирешелә.

«Рәдде бичара кыз»ның тышкы билгеләре дә йомшак әле. Анда тәфсилле ремаркалар бихисап. Проза әсәрләрендәге диалогларны формалаштыруда кулланылган автор сүзләре дә ремарка итеп бирелә. Кайвакыт драматург режиссер вазифаларын да үз өстенә ала: геройлар нинди халәт кичерергә, аны ничек итеп чагылдырырга тиешлеген әйтә. Сәхнәләштереп булмый торган эчке уйларны да язып үтә.

Беренче драмаларыбызда заман проблемалары бик тар алына әле, аларның драматик эшләнеше дә йомшак. Геройларны гаилә тирәлеге белән генә чикләүне язучыларның тар карашлылыгы дип санамаска кирәк. Ул шул чорда тамыр җәйгән мәгърифәтчелек идеологиясе белән бәйле. Нишлисең, һәр чорның үз хыяллары. XIX гасырның соңгы чирегендә каләм ияләребез кешене мәгърифәт бәхетле итәр дип өметләнгән.

## «Бичара кыз» һәм «Рәдде бичара кыз» драмаларын үзара чагыштыру

XIX йөзнең соңгы чирege татар халкы тарихына бай елъязма калдырган. Бу чорда әдәбият мәйданына аяк басучыларның барысы да гомерләрен халыкка мәгърифәт таратуга багышлаган. Алар бер үк вакытта галим дә, мөгаллим дә, философ та, әдип тә, җәмәгать хадиме дә булганнар. Әнә шундый күренекле кешеләр арасында Г. Ильяси һәм Ф. Халиди исемнәре аерым бер урын тота. Без аларны татар драматургиясенә нигез салучылардан дип беләбез.

Киңкатлам укучыга бу ике язучының «Бичара кыз» һәм «Рәдде бичара кыз» исемле әсәрләре аеруча билгеле. Аның икенчесе беренчесенә җавап рәвешендә туа.

Г. Ильяси әсәрендә вакыйга-күренешләр дә, анда катнашучы геройлар да бик аз. Алары да ныклап ачылырга өлгерми, күп әйберләр үзебезгә фаразларга кала. Әйтик, Мәһитап. Аның хыялыйлыгын, чиста күңеллелеген, диндарлыгын күрәбез. Болар безне аның берникадәр укымышлылыгы хакында уйлата. Җанбайның да кыз өчен борчылуы бер сәбәпсез булмаска кирәк.

Җантимернең галимлеге турында автор «Әшхас»та ук әйтә. Пьесаның эчендә аны бер-ике деталь генә күрсәтеп тора. Кыз язмышында мөһим урын тоткан имче хатын барысыннан да ныграк ачыла шикелле. Ул — шактый кызыклы, тормышчан эшләнгән образ. Матур үрнәк булганга да, татар әдәбиятында шул типтагырак карчык образлары белән без тагын да очрашачакбыз әле.

Сәхибә берникадәр хәйләкәр, күпмедер дәрәҗәдә дипломат, «күчтәнәч»кә өмет итүчән... Ул менә дигән яучы да була алыр иде, әмма автор димләү вазифасын башкага тапшыра. Ә яучы эшне бик тиз тота...

Җанъяр Болгатаев образы кеше күңеленә вәсвәсә салу, дөресрәге, Җанбайга Мәһитапның ярәшелүе турында хәбәрне җиткерү өчен генә файдаланылган. Аны төшереп калдырырга, ул эшне башкаларга тапшырып, эчтәлекне кызыграк, тыгызрак итәргә дә мөмкин. Фатыйма да әсәр өчен артыграк шикелле. Әле аны тагын да уйнатырга, Мәһитапның башын катыруда файдаланырга кирәк.

Кечкенә генә күләмле «Бичара кыз»да без әнә шундый ачылып җитмәгән геройлар белән очрашабыз, шунлыктан ул бүгенге көннең бер-ике пәрдәлек скетчларына, миниатюр пьесаларына аваздаш.

Ф. Халиди әсәрендә 12 персонаж катнаша. Алар арасында инде вакыйгалар үстерелешендә бөтенләй әһәмияте булмаган Әхмәт бай кызы Фәрхәнә, Әхтәм байларның асраулары, кучерлары бар. Дөрес, автор аларны вакыйгага билгеле бер максатлардан кертә. Мәсәлән, Хәйри һәм Әхтәм, пьеса куелса, масса төсен тудыра-

чак. Фәрхәнә Хәлимә белән чагыштыру өчен кирәк. Боларны, персонажларның санын арттырмыйча, вакыйгаларны бер герой тирәсендәрәк туплап җиткерү юллары да бар.

«Рәдде бичара кыз»ның бер үзенчәлекле ягы -- аның төрле социаль төркем вәкилләренә байлыгы. Монда без фабрикантны, гадәти бер байны, приказчикны, кучерны, асрауны, шәһәр ярлысын, хезмәт яшеннән чыккан карчыкларны күрәбез. Драматург аларның берсен дә сыйныфына бәйле рәвештә тәнкыйтьләми, чөнки ул — мәгърифәтче. Мәгърифәтчеләр исә бер генә сыйныфны да аерып карамыйлар, милләтнең алга китешен һәр сыйныфларының хәле яхшыруында күрәләр, һәр социаль төркем вәкиле башкалар һәм халык бәхете өчен үз өлешен кертергә тиеш дип саныйлар.

Г. Ильяси үз әсәрендә үзәккә бай кызын куйса, Ф. Халиди иң түбән катлам вәкиле баласын ала. Икесенең дә бәхете мәсьәләсен күтәрүләре белән, «Бичара кыз», «Рәдде бичара кыз» бер-берсен тулыландыралар гына.

Мин сочинениемдә ике пьесаның да геройларын янәшә куеп бастырдым, аларны сан ягыннан, үзләре караган социаль төркемнәр ноктасыннан чагыштырдым.

# X сыйныф

ГҮЗӘЛ ГАМЬ

**Яраткан әсәрем турында язарга телим**

Мин драма әсәрләре укырга яратам. Аларда вакыйгалар зур тизлек белән бара, чишелеш озак көттерми. Повесть яисә романда пейзаж урыннары, автор сөйләме, аның аңлатмалары бик күп. Ә миңа кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен күзәтү, үзем анализлау, бәяләү ошый.

Сәхнә әсәрләрендә явызлык һәм яманлык бер-берсеннән аерылыбрак тора, шунлыктан алар зур күпчелеккә аңлаешлырак. Ә менә Хәй Вахитнең «Туй алдыннан» драмасында мин кешеләр бәхетсезлегендә кемне гаепләргә белмичә, аптырабрак калдым.

Пьеса егет белән кызның загстан кайтуын көтү күренешеннән башлана. Язылышачак парга туйга кадәр

сынау көне бирелгән. Авторның әнә шул вакыт аралыгында барган вакыйгаларны тасвирлаячагы әсәрнең исеменнән үк билгеле.

Шушы ук көнне Рафаэльләр йортына төрмәдән дусты Марат кайтып төшә. Димәк, ул алдан планлаштырылган көннәргә ниндидер үзгәреш кертәчәк, туй буяуларын җетеләндерәчәк я тоныкландырачак. Чынлыкта да, шулай булып чыга. Марат, Рафаэльнең берәүгә пычак кадавын үз өстенә алып, төрмәгә утырган икән. Шунда ук сорау туа: чын дуслык хакына ясалган адыммы бу, әллә берәр хикмәте бармы?

Бераздан Маратның үзен шундый зур авырлыкларга дучар итүе талантлы Рафаэльне саклау өчен икәнлеге аңлашыла. Әмма, җәза срогы тулганнан соң, Марат башкача фикер йөртә башлый. Шул арада аның дусты шәп нигез салган, кәнәфигә менеп утырган, машинасы бар, җитмәсә, кайчандыр ул сөйгән кыз белән гаилә корып җибәрмәкче, ә ул беркем түгел, һәм аның бернәрсәсе дә юк. Марат бушка узган гомер газабы кичерергә тотына. Үзенең бөек идеаллар хакына кылган гамәлен әрәмгә санап үкенә, инде Рафаэльне ул көткәнне акламауда гаепли үк башлый. Тора-бара ике яктан да гаепләшүләр китә. Кем хаклы — аңлый алмыйсың.

Рафаэльгә, сөйгәне Йолдызга өйләнмичә, Әдиләне алганы өчен ачу килә. Кайвакыт Маратның гаепләүләре дә артыграк төсле тоела. Иптәше Йолдыз язмышында гаепле икәнлеген аңлаган, борчыла, Маратны фатирлы итәчәк, туй көнендә дә кунакчыл каршы алган бит инде, дисең. Икенче яктан, шул вакытта егетнең әтисе үлгән, туган нигезе юкка чыккан.

Әсәр ахырында кем гаепле соравына һәр герой үзенчә җавап бирергә омтыла. Рафаэль җинаятьне үз өстенә алганы өчен Маратны гаепли, син миңа гомерлек рухи җәза китердең, ди. Аның да шәхси драмасы ныграк ачылып китә. Син шунда ук, Рафаэль нигә дөреслекне яшереп калдырган соң, дип, гаепне аңа күчерәсең.

Кыскасы, геройлар бәхетсезлегендә кемне гаепләргә дә белмәдем мин. Ә менә ике арадагы дуслыкка чик куелуда аларның икесенең дә гаебе бар дип таптым. Рафаэль дә, Марат та дуслыкны саклап калуның дөрес юлларын сайламаганнар.

## Г. Бәширов әсәрләрендә Туган як образы

> Гомәр Бәширов нәкъ менә туган-үскән җирне олылаучы язучылар рәтенә керә.
>
> *Г. Ахунов*

Г. Бәширов язган әсәрләр сурәт нәфислеге, җылылыгы, яктылыгы белән истә кала. Авыл, туган җир табигатенең нинди генә вакытларын тасвирласа да, йомшак, чиста буяулар белән эш итә ул. Туган якка күңелнең иң түрендә урын бирелгән ул тудырган геройларда.

1938 елда язылган «Урман шаулый хикәясе» татар җиренең бер матур урыны булган урман тасвирыннан башлана: «Без аның белән зур каен төбендә утырабыз. Әйләнә-тирәбездә — биек, юан агачлар. Күтәрелеп карaганда, бик биектә, агач башлары арасыннан күкнең ертык читле зәңгәр кисәкләре күренә. Җиргә түшәлгән сары яфраклар өстендә кояшның алтын тәңкәләре уйнаклый...» Урманның һәр төшендә, туфрагы, яфрагы өстендә, үләне арасында хәрәкәт бара. Меңләгән җан ияләре яши анда. Әнә шулар урманны да тере, күңелгә якын итә.

Ике иптәш урман тормышына бөтен күңеле белән бирелгән. Урманнан Фәтхигә яшәү тавышы ишетелә сыман. Хикәяләүче герой иптәшенең табигатьне яратуына, аның «моңнарын өзелеп тыңлавына» малай чактан ук гадәтләнгән, шуңа күрә Фәтхинең музыкантлык юлын сайлавы аңа табигый күренә.

Фәтхи борынгы озын җырларның көйне табигатьтән алуын күреп, тоеп белә. Шул табигать көендә «яшәү дәрте дә, моң да, рәхәтләнеп көлү тавышы да ишетелә» аңа. «Кара урман», «Зөлхиҗҗә»ләрне мәңге яши торган халык тудырганлыгы хакында бик үзенчәлекле фикер әйтә ул.

Без туган якны аның матур, камил табигате, шул табигатьне чагылдырган җырлары, аларны иҗат иткән, моңлы көйләр аша үз язмышын да чагылдырган халкы аша күз алдына китерәбез. Туган як Фәтхи кебек иҗатчыларны, «Намус»тагы Нәфисә кебек хезмәт сөючән кызларны, эче-тышыннан гүзәллек бөркеп торган асыл затларны тәрбияләргә сәләтле. Гомәр Бэширов әсәрдән-әсәргә шушы фикерне ныгыта. Аның геройлары авыл-

да яшәсәләр, Туган як матурлыгыннан хозурланырга вакыт таба, читләргә китсәләр, аны күңелләрендә йөртәләр, чиксез сагыналар.

Барыбызга да яхшы таныш «Сиваш» повестен искә төшерик. Сугышның авыр юлларыннан узган Шәмси белән бергәләп Туган якны сагыну хисен кичерик. Андый чакта халык җырларын җырламыйча ничек түзәсең?!

Йөгереп китәрдәй булам,
Кайтып җитәрдәй булам
Кичке салкын җилләрдә,
Туган-үскән илләргә, —

дип җырлый Шәмси. Әйтерсең, ул туган якта кичке салкыннар, җан өшеткеч җилләр юк! Туган як ул — йомшаклык, рәхәтлек, гүзәллек дигән сүз...

«Намус» романын укысаң да, чыннан да, шулай дип уйлыйсың: «Үлән белән капланып та җитмәгән йомшак урман юлыннан яшел тоннель сыман күренгән зур юкәләр күләгәсенә кереп киткәндә, агачларның йомшак яфраклары Зиннәтнең битен, иңбашларын сыйпап кала, аланнарга килеп чыкканда, усак яфраклары, куанышып кул чапкандай, аны лепердәшеп каршы алалар...»

Алай гына да түгел, урман кошлары сайраудан туктый белми, алар берсеннән-берсе купшы, сандугачларының авазлары «куыш пыяла чикләвекләр» чыгарган тавышка охшаган.

Таң алды. Тынлык. Г. Бәшировның Нәфисәсе — шул тынлык уртасында. «Нәфисә, таң алдының бу гаҗәеп тынлыгына сокланып, бу гүзәллекне бөтен тәне белән дә тоярга теләгәндәй, күзләрен йомды... Ул яңадан күзен ачканда, кыр өсте тоныклана төшкән, шәфәкъ кызыллыгы, сүнәр-сүнмәс бер бизәк булып, уңып бара иде». Бу табигать матурлыгы, әйтерсең, кешене хыял канатларында очырыр өчен яратылган. Син иң якын, иң кадерле кеше белән шул гүзәллектә коенырга телисең.

«Туган ягым — яшел бишек» безне Арча ягы урманнарында йөртә, Арча суларыннан авыз иттерә, Яңа Сала тугайларында ял иттерә. Син, гәрчә анда тумаган булсаң да, бу минем туган ягым бит, дисең, данлы Арча

ягын зур Ватаныңның бер кисәге итеп тоясың.

Г. Бәшировның Туган ягын кадерләгән геройларында үзенең рухы яши. Алар безгә туган җиргә кагылышлы тасвирларның гади генә сурәт булмыйча, кеше күңелендә йөрткән зур бер образның чагылышы булуын аңларга булышалар. Г. Ахунов сүзләрендә кире кагып булмаслык хаклык бар. Чыннан да, Г. Бәширов — туып-үскән җирен данлаучы, аны яратырга өйрәтүче әдип.

## ӘДӘБИЯТ

### Әдәбият мәйданына алып килгән әсәр

*(Гаяз Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт...» хикәясе буенча)*

Гаяз Исхакый, биографиясе материалларына нигезләнгән «Тәгаллемдә сәгадәт яхуд гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» хикәясен Габдулла хәзрәттә (Апанаевлар мәдрәсәсе) торганда язып, инде Яңа бистә чорында бастыруына карамастан, әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан ул бернинди игътибарга да алынмый. Бу аңлашыла да. Беренчедән, сиксәненче елларда әлеге идеяне күтәреп чыккан һәм сәнгатьчә эшләнеше ягыннан югарырак торган башка әсәрләр дә була (М. Акъегет, «Хисаметдин менла», 1886 һ.б.). Икенчедән, татар зыялыларының шактые, гади укучы бигрәк тә, әлегә гади телдә иҗат ителгән, милли тормышыбыздан алынган һәм вакыйгалары чынбарлыктагыча хикәя-романнарны бәяләргә күнекмәгән. Алар гарәп-фарсы алынмалары белән чуарланган яисә асыл затларның маҗараларын чагылдырган француз һәм Урта гасыр көнчыгыш әдәбиятына ияреп язылган китапларны укырга гадәтләнгән.

Шул ук вакытта «Тәгаллемдә сәгадәт...»тә әдипнең тормышның фактик материалыннан аерыла алмавы, аны теркәү формасында язуы, икенче төрле әйткәндә, хикәягә хас җитешсезлекләр дә аның җәмәгатьчелек тарафыннан игътибарга алынмавына китерә.

Кайбер әдәби тәнкыйть мәкаләләре Г. Исхакыйның беренче әсәрләрендә вәгазьнең күзгә ташланып торыр дәрәҗәдә икәнлеген билгелиләр.

Сәнгатьчә эшләнеше ягыннан аннан соң язылган «Кәләпүшче кыз» да шактый йомшак, әмма аны «Тәгаллемдә сәгадәт...» кебек бер күзәнәкле әсәр дип санап булмый. Анда вакыйгалар да күбрәк, һәм алар укырга кызыклы итеп тә тезелгән.

Гаяз Исхакый башлангыч чор иҗатындагы җитешсезлекләрне үзе дә күргән, билгеле. Повестька язылган керештә ул «Кәләпүшче кыз»ның кимчелекләре булса да, халык соравын искә алып, аны икенче кат бастырырга мәҗбүр булуын яза. Китапның ул басмасының да гасыр башында басылуы укучы ихтыяҗының чор карашларын чагылдыруын күрсәтә.

Иҗат юлында беренче әсәре булган «Тәгаллемдә сәгадәт...» тә әдипкә бер вакыйгадан икенчесенә күчү, диалоглар төзү авырлыгы күренә. Шул чорның әдәби үрнәкләренә хас булганча, хикәядә дини гыйбарәләр дә шактый гына. Аны укыганнан соң, тормышта булган вакыйга, үзгәрми-нитми, әсәргә кереп утыргандыр кебек тәэсир кала. Бу әлегә язучының, тормыштан аерылып, гомумиләштерә алу осталыгы юклыгын дәлилли.

Дөрес, әсәрнең кереш абзацыннан ук булачак олуг язучыны чамалау кыен түгел: «Агачларның яфраклары коелып, үләннәрнең чәчәкләре саргаеп, җәй фасылының бетүенә хәсрәтләр чигүдә, кошларның тавышлары үзгәреп, урыннарының бетүенә, гомерләренең тәмам булуына хәсрәтләнеп: «Әлвидаг, әлвидаг!» — дия сайрауда; суларның дулкыннары, агачларның яфраклары бөрешеп-бөрешеп, куркыныч тавышлар белән тавышлануда; күз алдымда — моңлы».

Гаяз Исхакыйның һәрбер иҗат җимешенә, хәтта ул ашык-пошык язылганда да, җиренә җиткереп эшләнмәгәндә дә, беренче абзацның камиллеге, кабатланмавы, шагыйранәлеге хас. «Тәгаллемдә сәгадәт...»тә дә шулай, әмма анда әле әдипнең соңрак язылган әсәрләрендәгечә, җитди фикерне юмор белән катнаштырып сөйләү күзәтелми.

Бу хикәя, җитешсезлекләре күп булуына карамастан, әдәбият мәйданына зур әдипнең килүен хәбәр итә, чөнки гасыр башында, беренче тапкыр каләм сынаганда ук, заманга хас мәсьәләләрне күтәрү теләсә кем акылына

килми. Белгәнебезчә, әсәр үзәккә искечә-яңача укыту кебек бик актуаль проблеманы куя, бәхетне геройның белем алуы белән генә түгел, нинди белем алуы белән дә бәйләп карый.

## Г. Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт...» әсәрендә уздырылган карашлар

«Тәгаллемдә сәгадәт...» («Белем алуда — бәхет») — язучының төп герое тулы бәхеткә ия бердәнбер әсәре. Үзәк герой Хәлимнең дә, әнисенең дә теләкләре: аның, укып, зур кеше булуы, шуның нигезендә чиксез бәхетләргә ирешүе. Мәгърифәтче язучыларның зур күпчелек әсәрләренә хас булганча, уңай геройның язмышы монда да үзе теләгәнчә тәмамлана. Егетнең хыяллары артыгы белән тормышка аша дип әйтергә мөмкин.

Хикәя башыннан ахырына кадәр мәгърифәтчелек идеяләре белән сугарылган, төп фикере кешенең ирешә алган теләсә нинди бәхете белемгә генә бәйле дигәннән гыйбарәт. Бу идея инде аның исеменә үк салынган. Алай гына да түгел, кешенең белеме никадәр зур, камил, шатлык-сөенечләре дә шуңа бәрабәр, пропорциональ.

Алда әйткәннәребезне геройлар язмышы аша дәлилләп була. Хәлимнең әнисе улын кечкенә мәдрәсәгә илтү белән генә канәгатьләнми, чөнки танылган, тирән белемнәр бирүче мәдрәсәдә укыса, Хәлимнән аеруча зур кеше чыгар дип саный.

«Тәгаллемдә сәгадәт...»тә Гаязның башка әсәрләрендә дә чагылачак шәкерт вакытында уйлаган уйлары ярылып ята: ул әле кешеләрне галимнәргә һәм мужикларга бүлеп карый һәм үзенең шуларның беренчеләре арасына керәсе, зур кеше буласы килә.

Г. Исхакыйның беренче хикәясе зур самимилек белән язылган автобиографик җирлекле әсәр тәэсире калдыра, өлешчә булса да әдипнең формалашуын, балачак хыялларын күзалларга да ярдәм итә.

«Тәгаллемдә сәгадәт...»нең төп герое Хәлимгә һәр нәрсә уңай килеп тора. Әнисе аны аңлый, башкалар да баладагы зур омтылышларны югары бәяли, үзләренең фатихаларын бирәләр. Байлардан укырлык акча табыла.

Зур тырышлык куйганга күрә, ул мәдрәсәдә беренче укучы дәрәҗәсенә күтәрелә. Рус, гарәп, төрек, фарсы телләрендә сөйләшә. Бер үк хәлләр, укучы аңына сеңдерелер өчен кебек, хатлар аша кат-кат сөйләнелә. Хәлим үзе бурычлы булган һәр кешегә рәхмәт әйтеп калырга тырыша, Алланы да теленнән төшерми.

Хикәядә белем кешенең иң зур байлыгы буларак бәяләнә. Укымышлы егеткә, артык *хәлле* түгеллегенә карамастан, Казан байлары яучы да җибәрә. Ярәшеләчәк кызы Маһирә дә үзе шикелле үк белемле, шулай да ул әхлаксыз күренергә, кешене алдарга теләми: хәлне аңлатып, Хәлимгә хат яза. Әдип карашынча, мәгърифәтле кыз намуслы да, шәхси авырлыклардан мөстәкыйль чыгарга сәләтле дә була.

Хәлим гаиләсен дә үзенә лаек итеп төзи: Габдрәхим хәзрәтнең кызын ала. Алар шулай ук, бер-берсе белән аңлашып, хатлар алышалар, соңыннан өйләнешәләр, бергә-бергә бәхетле гомер кичерәләр. Белемле геройларның һәрберсенең язмышлары уңай хәл ителә.

Үзенең тәүге әсәре булган «Тәгаллемдә сәгадәт...»тә әдип киләчәктә төп проблемалар буларак күтәрәчәк кайбер мәсьәләләрне дә сызып куя. Шуларның берсе — хатын-кызның гыйффәтлелеге. Үзәк герой Хәлим кәләш итәрмен дип уйлаган Маһирә Фатихка бирелгән. Бер яктан, ул моны яратканлыгы аркасында эшләгән кебек. Икенче яктан: «Каһәр суккан Бәдәр харап итте мине», — дип тә куя. Әйтерсең, Гаяз Исхакый белемле кызга гаеп ташларга теләми.

Маһирәнең язганнары Хәлимнең дөньяга күзен ныграк ачып карарга булыша. Галиягә хатын инде ул махсус рәвештә: «Гафифә кыз!» — дип башлый. Шушы ике генә сүзнең ни өчен язылганлыгын аңлаган Галия шулай ук «һич гаепсез бер кыз» икәнлеген «бер дә курыкмыйча» сөйли. Һәм Хәлим, Маһирә үтенгәнчә, «үзе өчен генә яратылган» кәләшне таба.

Гаяз Исхакый беренче хикәясендә үк бөтен яшәешенең юнәлешен билгели. Төп герой Аллаһе Тәгалә миен кавемгә хезмәт итәчәк белемнәр өчен тутырды дип саный. Аларның кулланылышын ул әлегә мәгърифәтчеләрчә күзаллый: «...Син, үзеңнең кавемең наданлыгына

карап, икенче кавемнәрнең гыйлемнәреннән гыйбрәтләр алып, алар шикелле итәргә телә».

Әлегә бу әсәрдә шул заманга хас суфичылык карашлары да үзен сиздерә: белемлелек, милләткә хезмәт Аллаһыга якынаю өчен кирәк дип тә аңлашыла. Зур нәселдән чыккан, үзе дә тирән белемле ана кеше баласын укытмый калдырган өчен кыямәт көнне җавап бирү хакында уйлый. Шул ук вакытта белемнең дөнья күтәргә дә, ахирәткә дә бер үк дәрәҗәдә кирәклеген дә төшенә.

Бу чорда төрле фәлсәфәләргә, дөньякүләм билгеле галимнәргә табыну көчле була. Фатыйма баласының мөмкинлекләрен «философ дәрәҗәсенә җитәчәк» дип чамалый.

Хәлим һәр карашында «бәхетсез» әнисен кабатлый, аныңча уйлаганга, сәгадәткә ирешә. Ул, иң беренче чиратта, Фатыйма ханымның тәрбиясе аркасында, ислам кушканча йөрү тиешлегенә инана, белемен баштан ук мөселман кардәшләренең хәлен яхшыртыр өчен кулланырга исәпләп тора. «/.../ Искедәге бабайларның дин юлында, милләт юлында иҗтиһадларыннан гайрәт алырмын», — ди.

Гаяз Исхакыйның бу хикәя белән әйтергә теләгән төп фикере: баланы мәгърифәтле ата-ана тәрбияләргә тиеш. Әгәр әнисе дә, әтисе сыман наданрак, улының язмышына битарафрак караса, Хәлим, һичшиксез, үзе генә бернәрсәгә дә ирешмәс иде. Шулай итеп, язучы, башка мәгърифәтчеләр кебек үк, гаиләдә аналык вазифаларын иң югары мәртәбәгә күтәрә, алай гына да түгел, актив хатын-кыз образы тудыра. Бу тәүге әсәр өчен бик зур уңыш саналырга хаклы.

Гаяз Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт...»тә күтәргән мәсьәләләргә киләчәктә ничек якын килүе аның әдип, шәхес, җәмәгать эшлеклесе буларак үсү юлын күрсәтеп тора.

«Тәгаллемдә сәгадәт...»нең өйрәнчек кенә әсәр икәнлеген, аның инде өлгергән Гаяз Исхакыйның иҗат омтылышларын канәгатьләндермәвен, карашларын ачмавын, типик хәлләрдән чыгуның төп юлын күрсәтмәвен соңрак биографик материалларга тагын да ныграк таянган «Мулла бабай» романы язылу да раслый.

## Г. Исхакыйның беренче әсәрләрендә яманлык белән яхшылык көрәше

Урыс мөселманнары арасында Исхаковның популярлыгы бик зур, аны бөтенесе һәм бөтен җирдә беләләр вә укыйлар, хәтта татар авылының иң караңгы почмакларында да аның исеме мәхәббәт вә зур хөрмәт белән телгә алына.

*М. Токтамышев*

Милли әдәбиятыбызның классигы Гаяз Исхакый турында Токтамышев тарафыннан бер гасырга якын элек әйтелгән сүзләр аның исеменең хәтеребездән сызып ташланырга тиеш түгеллеген күрсәтә һәм әлеге популярлыкның сәбәпләре хакында уйландыра. Минемчә, каләм иясенең, халык мәнфәгатьләрен кайгыртканда, гаделлекне яклаганда, әсәрләрендә яхшылык өстен чыкканда, исеме дә мәңгеләшә. Г. Исхакый язганнар үз заманында ук нәкъ менә явызлыкка, гаделсезлеккә каршы көчле бер аваз булып яңгырады.

Үзәгендә мәгърифәт аркылы кешене бөтен яктан камилләштерү идеясе яткан «Тәгаллемдә сәгадәт...»тә әлегә «яхшылык һәм яманлык» концепциясе бөтенләй юк. Бөтен геройлар, нинди социаль даирәдән чыгуларына карамастан, уңай яктан гына тасвирлана. Уңай һәм тискәренең көрәше тудырылмаса да, тормыштагы тискәре күренешләргә ишарә бар анда. Кайбер мәдрәсәләрдә, мөгаллимнәргә бәйле рәвештә, әдәпнең тиеш дәрәҗәдә бирелмәве хакында фикерләр дә күзгә чалынып ала.

«Бай углы»н Гаяз Исхакый инде «яманлык — яхшылык» концепциясенә нигезли һәм көрәшне мәгърифәтчеләрчә чишә. Кешеләргә авырлык китергәннәр эшләренә бәрабәр җәзасын ала. Сәгыйдә бикә белән Фатыйх бай бала тәрбиясенә, мәдрәсәләр ачуга кызганган байлыкны «этләр ашый». Кеше гомерен кискән һәм азгынлыктан башы чыкмаган Кәрим фәхешханәдә алган яраларыннан үлә, гади кешеләр белән исәпләшмәгән Сәгыйдә бикәне, акчасыз калгач, хәзрәт тә кабул итми.

Яхшылык та җирдә ятмый: Бәдрия чиста күңеллелеген кешеләр каршысында раслый, Тәүфикъ улы ул үстерә, картлыгында аның тәрбиясенә кала.

Гаяз Исхакыйга әдиплек данын китергән «Кәләпүшче кыз» әсәрендә «тормыш төбенә төшерелгән» хатын-кыз язмышы үзәккә куела. Анда язучы кешенең үз-үзен тотышында акылга таянып эш итәргә тиешлеген һәрдаим ассызыклап тора. Явызларга акыл белән генә каршы торып була, ди ул. Камәр, уйлап бетермәве, хисләренә табынуы аркасында, әхлаксызларның, явызларның берсе булган приказчик Вафадан алдана. Аннан яшьрәк булган Васфибануның акыллы киңәшләр белән апасына ярдәмгә килергә теләве, үзенең дә бәхеткә ирешүе — язучы әйткәннәргә ачык дәлил.

Берәү дә Камәрне коткару юлында реаль эш күрсәтми, ул явызлар тирәлегендә ялгызы торып кала. Әнисенең үз хәле хәл, энесе — яшь. Тормышында очраган яңа кешеләр дә Камәрне баткаклыктан коткару чарасын күрми. Мифтах абзый үзе артыннан кызын да ияртер дип куркуга төшүдән ары китми. Җитмәсә, ул, гомумән, Кәримә теләгән, көткән, мәрхүм ире кебек әйбәттер дип өметләнгән кеше булып чыкмый.

Камәрнең авыр хәлдә калуын күреп, аны әшәке максатларында файдаланып калучылар гына җитәрлек. Башта ул шундыйларның берсе булган Зөһрә абыстай кулына эләгә. Тора-бара Камәр фахишәлекне һөнәр итә, инде аңа теләп, табигый хисләренә дә буйсынып бара. Азгынлыгы аркасында, матди тормышын кайгыртып торучы Бәдридән дә колак кага. Фәхешханә тормышы аңа чирдән башка берни бирми. Исеме-даны башка шәһәрләргә барып ирешә. Анда хезмәт итәрлек матурлыгы беткәннән соң да, ул элекке яшәү рәвешен дәвам итә. Чир арты чир, үлем... Исеменә ай мәгънәсе салынган, кайчандыр бик чибәр Камәрне инде яхшылар рәтендә күреп тә булмый, әмма, хәзер үзе теләп явызлыкка хезмәт итсә дә, аның өчен йөрәк әрни.

Язучы, кайтып-кайтып, аның түбәнлеккә төшү сәбәпләре хакында уйлана: «Әтисе остазбикә булуын теләгән иде. Мөмкинлеге булса да, бу хәлгә төште. Нинди сәбәпләр аркасында? Ул кем? Кем булыр? Шул турыда елады». Гаяз Исхакый әсәрнең соңында (хатимә-пролог) моның сәбәпләренә төртеп үк күрсәтә: Вафа белән Зөһрә кебек ике төрле кешеләрдер.

Әсәрнең эчендә әлеге сорауларга җавапны киңрәк, төрле яктанрак бирә әдип. Ул аның үз мәнфәгатьләрен алгарак куйган, шулай ук өметләрендә алданган әнисен дә җаваплылыктан азат итми, Камәрнең үзен дә тулысынча акламый.

«Кәләпүшче кыз»дагы Вафа һәм Зөһрә, әлбәттә, һәркемнән гаеплерәк. Алар — туып килүче капиталистик җәмгыятьнең паразит тормыш алып баручы вәкилләре. Мәгърифәтче әдәбиятчы әкренләп югары катлам вәкилләренең әхлакый бозыклыгын, шул бозыклыклар аркасында аларның башкаларга авырлыклар китерерлек адымнар ясавын сурәтләүгә таба атлый. Җәмгыятьнең гади халыктан өстәрәк торган яңа катламнары әлегә байларга хезмәт итүче Вафа кебекләрдән формалашуын аңлый ул.

Бозык тормыш алып баручы Вафа иң югары катлам вәкилләреннән булмаса да, зур табыш китерәчәк киләчәк капиталын туплау юлына баскан. Ә менә алда телгә алынган Кәрим — матди байлык тудырмыйча гына, җиңел тормыш алып баручы, шул тормышның төрле азгынлыкларын татып өлгергән бай углы, югары катлам вәкиле.

«Кәләпүшче кыз»да вакыйгалары аксөякләр тормышыннан алынган русча әсәрләр өчен бик типик булган сөяркә тотучы яшь байлар образы — Бәдри белән дә очрашабыз. Ул Камәргә фатирны да руслар яшәгән тирәлектән алып бирә, бераздан хыянәте өчен кызны матди тәэмин итүдән туктый. Бу Гаяз Исхакый әсәрен шулай ук ике гасыр чигендәге әдәбият эчендә үзенчәлекле итә.

Әгәр язучы, геройларның үз-үзләрен тотышын «табигый хисләр» җиңүгә, бозык тирәлеккә эләгүгә генә кайтарып калдырса, мәгърифәтчелек реализмы принципларын тулысынча тормышка ашырмаган булыр иде. Повестьның тормыш көтү өчен тиешенчә белем алмаган, намусын сакламаган, һөнәре юк Камәргә капма-каршы Васфибану образы тасвирлавы — аеруча мөһим якларыннан. Аның аркылы язучы идеалдагы мөселман хатын-кызын күрсәтә.

Хатимәдә Гаяз Исхакый, яшьләрне түбәнлекләрдән саклау өчен, китаплар язып аңлатырга кирәклекне әйтә һәм бу эшне иҗатчы зыялыларга йөкли. Димәк, күре-

некле әдип Явызлыкка каршы көрәштә әдәбиятка зур өметләр баглаган.

## Гаяз Исхакыйның башлангыч чор әсәрләрендә гыйффәтлелек мәсьәләсе

Хатын-кызның, бигрәк тә яшь кызларның әхлаклылыгын бәяләгәндә, гыйффәт төшенчәсен читләтеп узып булмый. Әлеге сүзнең киң һәм тар мәгънәләре барлыгын онытырга ярамый. Беренче мәгънә «кызлык намусы»н күздә тотса, икенчесе шәхеснең эчке һәм тышкы сафлыгын аңлата. Г. Исхакый иҗатында алар икесе дә кеше бәхетенең шартлары булып тора.

Г. Исхакый инде «Тәгаллемдә сәгадәт...» әсәрендә үк белемле, укыган, әхлаклы егетләргә гыйффәтен саклаган кызлар гына тиң булу хакында әйтә. Эчтәлектән кемнеңдер кызлык намусына кул сузган кеше аның белән калырга тиеш кебек аңлашыла. Әдип бераз соңрак язылган «Теләнче кызы»нда үзәк героиня Сәгадәтне дә кабат Габдулласы белән очраштыра, аларның бергә бәхетле булу омтылышын күрсәтеп ала.

Әлбәттә, гыйффәтлелек турында сүз йөрткәндә, ир-атны да читләтеп узып булмый. Г. Исхакыйның гомерләрен фәхешханәдә уздырган «бай углы»ның язмышы шул юлда йөргән «кәләпүшче кыз»ныкы шикелле үк тәмамлана.

Язучы азгынлык, фахишәлек кебек чирләрнең туу, таралу сәбәпләре турында уйлана. Башлангыч чор әсәрләрендә хатын-кызны шундый юлга әхлаксызлыгы белән даны киткән югары сыйныф вәкилләре, матди тормыш кыенлыклары, билгеле бер дәрәҗәдә хисләргә бирелүчәнлек, беркатлылык этәрсә, бай балалары эшсезлек, дөрес тәрбия күрмәү, заманча белем алмау, табигый теләкләренең колы булу аркасында бозыла.

Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендә фахишәлек аркасында туган яман чирләр тулы бер милләткә яный, әнә шуны аңламау аны инкыйразга илтүнең бер юлы булып тора.

Сюжетының катлаулылыгы, психологизмга зуррак урын бирелү, тормышчанлыгы белән башка әсәрләрдән ныграк аерылып торган «Теләнче кызы»нда, күңел хисләренә бирелгәне өчен, Сәгадәтне битәрләү юк дәрәҗә-

сендә. Язучы аның үзен җан газаплары аша уздыру белән канәгатьләнә. Без Сәгадәт Габдулладан алданмаган булса да, мохтаҗлык, торыр урыны булмау, һөнәрсезлек аркасында барыбер шундый ук икенче бер бай малаеның кулына төшәсен беләбез. Язучы бу әсәрендә Сәгадәт кебек чибәр кызларга тормышның иң төбенә атларга «булышкан» Габдулла кебекләрне кискен тәнкыйть итә.

«Теләнче кызы»нда Г. Исхакыйның башка әсәрләрендә очрамаган фикерләр бик күп. Әйтик, ул сәнгать үсмәгән татар дөньясында хәтта иҗатчы рухлыларның да фәхешханәгә баруы хакында сөйли. Без тагын югары катлам вәкилләренең халыкның рухи, матди үсешенә җаваплылыгы мәсьәләсенә килеп чыгабыз.

Г. Исхакыйның башлангыч чор әсәрләрендә авылда яшәгән, хезмәт белән көн күргән, табигать матурлыкларына хозурланган кызлар бозык булмый. Сәгадәт тә авылда вакытта яман күренешләрдән, дуслардан ерак тора. «Бай углы»ндагы Бәриягә килсәк, ул, нәкъ менә авылда туганга, яман тәэсирләргә эләкми. Тегермән буйларында су шаулавын тыңлап, табигатьнең үзе кебек саф, нечкә күңелле, хезмәт сөючән, хәтта начарлыкка да начарлык белән җавап кайтара алмаучы бер кыз итеп тәрбияләнә.

Г. Исхакый беренче әсәрләрендә үк үзәк героинясының намусын югалту вакытын тәфсилле тасвирлый, аның кичерешләренә, газапларына урын җитәрлек бирә. Димәк, хатын-кызның әхлагы мәсьәләсе әдип өчен хәл ителергә тиешле, көн кадагына куелган проблема булып тора.

Хатын-кыз намусы хакында сүз йөрткән «Кәләпүшче кыз»ның, аннан соң язылган «Теләнче кызы»ның халык тарафыннан яратып укылуы фахишәлек күренешенең тамыр җәя баруы, күтәрелгән мәсьәләләренең актуальлеге белән бәйле. Беренчесенең үк матбугатта зур резонанс алуы да табигый, чөнки Гаяз Исхакый хатын-кызны җәмгыять тудырган баткаклыклардан йолып калу мәсьәләсен милли проблема дәрәҗәсенә күтәрә. Бу уңайдан Йосыф Акчураның «Гаяз әфәнде» язмасыннан түбәндәге юлларны китерәсе килә: «Татар әдәбиятыннан иң күп тәэсир берлән укыган китабым

«Кәләпүшче кыз» булды /... /. «Кәләпүшче кыз»ны укыр көн шул Казанда гомер иттем һәм милләтемә чыккан иң тәһликәле (һәлакәтле), иң агулы чобан (чуан, чир) сызлавын үз рухымда хис кыларак гомер иттем...»

Беренче әсәрләреннән әдипнең, белем, һөнәр биреп, кешеләрне әхлаксызлыктан саклап калып була дип исәпләве күренә. Шул заманның күренекле шәхесе Н. И. Ашмарин «Несколько слов о современной литературе Казанских татар» хезмәтендә егет һәм кызларны бу юл белән баткаклыктан коткаруны мәсьәләнең дөрес чишелмәве дип караган, Гаяз Исхакыйның фахишәлекне татар тормышында типик күренешкә әйләнүен җиткерүенә каршы рәвештә, аның башка җирләргә дә хаслыгын язган. Тора-бара әдип үзе дә әхлаксызлыкның чын мәгънәсендә социаль күренеш икәнлеген һәм аны җәмгыятьне үзгәртеп кенә чишеп булуны аңлау дәрәҗәсенә күтәрелә.

## Әдәби әсәрләрдә бетем турында уйлануларым

Башлам, әсәргә җан өреп, аның рухын, интонациясен билгеләсә, эчтәлекне кабул итүгә хәзерләсә, бетем укучы Күңелендәге билгесезлекләргә чик куя, вакыйгалар барышыв туктата, бер нәтиҗә ясый яисә гнуларның киресе дә: ул вакыйгаларның дәвамын күңелебездә тудырырга тотынабыз, әйтелеп бетмәгән фикерләргә җавап эзлибез...

Кайвакыт шундый борылыш бетемдә ычкындырылган кечкенә генә бер мәгълүмат, автор интонациясендәге шик төсмере һәм башка бик күп сәбәпләр аркасында да барлыкка килә. Укучы, җиңел сулап, геройлар бәхетенә сөенеп, китап битләрен ябарга да, финал ачысыннан тетрәнеп китәргә дә, бетемнән сирпелгән яктылык тәэсирендә өмет катыш аптыраганлык хәлендә калырга да мөмкин. Бетем башкарган функцияләр турында бихисап озын сөйләргә була.

Язучы бигрәк тә зур күләмле әсәрләрне зур хәзерлек белән язарга тотына. Башында йөрткән сюжеты була, аның бер структурасы формалаша... һәм, әлбәттә, сайлап яисә табигый башланган беренче җөмләләр үзләре үк билгеле бер дәрәҗәдә авторны да буйсындыралар.

Әгәр шушы буйсыну аркасында туган интонация, эзлеклелек аның күңеленә хуш килмәсә, ул әсәрне язу эшенә кабат-кабат башкачарак та керешергә мөмкин. Шулай да җиңел кулдан язылган әсәрләрнең башламына әдип бик сирәк әйләнеп кайтадыр, чөнки хикәя яисә романмы тәмамланганнан соң, бик нык үзгәртелгән башламның яңгырашы төп өлешнекенә туры килмәскә, шунлыктан бөтенләй башка рухтагы әсәрне кабул итүгә хәзерләве дә мөмкин.

Миңа калса, соңгы җөмләләрнең язылышы хакында автор алдан ук ныклап уйланып йөрми. Аның өчен башта конфликтның чишелеше мөһим. Дөрес, башламда ни хакында сүз барачагы хакында ул якынча чамалый, әмма әле бу әсәр нәкъ шулай тәмамланачак дигән сүз түгел. Бигрәк тә аның сюжет композициясе нинди дә булса символик образга бәйле икән, әйтик, символ аның структур өлешләрен үзара ялгау функциясен башкаради, бетемнең дә алдан ук шактый уйланылган булуы мөмкин.

Бетем соң өлешкә буйсынган хәлдә туса да, ул шактый еш үзгәрә. Аеруча кыска әсәрләрнең, хикәяләрнең бетемнәрен язуга таләпчәнлек сорала. Син соңгы абзац белән укучы күңелендә геройлар язмышына бәйле рәвештә туган хис-кичерешләрне ныгыта да аласың, көчәйтәсең дә яисә бөтенләй башка агымга да күчерәсең.

Әгәр бетем төп өлешнең табигый дәвамы гына булса, укучы чишелештән туган тәэсирләрдә яшәр иде, ә каләм ияләре аны еш кына уйга салырга, аңын активлаштырырга тырышалар. Киләчәккә ишарәле, эндәш рәвешендә, әсәрнең гомуми тонына туры килмәгән интонацияле соң җөмләләр әнә шул эшне башкаралар да инде. Димәк, бөтен сүзләр әйтелеп беткән кебек булгач та, без язучы белән  хушлашмыйбыз.

Еш кына аеруча кечкенә күләмле әсәрдә, башламда кулланылган символларга әйләнеп кайтканда, гади укучы да бетемнең бик уйлап язылганлыгын тоя. Моның үз плюслары һәм үз минуслары бар. Фикердә, сурәттә образлылык артыннан куып, әсәр тукымасының табигыйлегенә зыян салуың да мөмкин. Һәр хикәяңнең, повестеңның структур өлешләрен символик мәгънәләр

бирүгә юнәлтсәң, образлы иҗатың да шаблонга, үз-үзеңне кабатлауга кайтып калачак, һәм син тапкан символларның тәме китәчәк.

Әдәби әсәрдә бетем хакында мин әнә шулай уйлыйм, һәм минем сүзләремне теләсә кайсы әдип иҗаты, милли прозабызның камил үрнәкләре белән раслап булыр иде дип саныйм.

## Г. Исхакыйның башлангыч чор әсәрләрендә бетем

Бетем, һичшиксез, язучы каләменең камиллек дәрәҗәсен күрсәтеп тора, язучы иҗатын хронологик тәртиптә өйрәнсәң, бетемнәрдә авторның осталык баскычларыннан югары күтәрелүен күрү кыен түгел. Аның иҗат ысулы, алга сөргән карашлары да бетемдә билгеле бер чагылыш таба. Үткән чорыбыз мирасында бу бигрәк тә ачык күренә.

Гаяз Исхакыйның тәүге әсәрләреннән булган «Тәгаллемдә сәгадәт...»тә бетем мәгърифәткә омтылышлы уңай геройның бәхетле киләчәгеннән хәбәр бирә, һәм без инде аны шулай булачак кебек үк кабул да итәбез.

Бик күп сүз кабатлаулардан, нигездә, санау интонациясе белән бер-берсенә ялганган җөмләләрдән торган әлеге бетем шул ук әсәрнең башламыннан тел камиллегендә, образлылыкта нык калыша. Бу авторның фикер уздыруга артык бирелгәнлеген, әмма әлеге фикер уздырылган формага игътибарсызлыгын күрсәтә.

«Кәләпүшче кыз»да Г. Исхакый исеменнән язылган кереш һәм соң сүзләрне, эчтәлекне ачуга ярдәм итсә дә, билгеле бер дәрәҗәдә башлам һәм бетем функцияләрен үз өстенә алса да, китапка шәрех кебек санарга кирәктер. Авторның култамгасы да сүзебез хаклыкка ишарәли булса кирәк.

Әсәрнең натуралистик, ягъни артык детальле тасвирга корылган бетеме дә көтелмәгәнчә түгел. Тулы бер абзацы аерым бүлек рәвешендә шәкелләштерелгәнлектән, фигыльләрнең заман формасы алмашынмый. Хәбәре үткән заман хикәя фигыль белән белдерелгән җөмләләрнең янәшә күп килүе теләсә кайсы текстны ямьсез итә. Монда да шулай: «Бара-тора Камәрнең баласы туар вакыт йетте. Үзе авыру булганга, баласын китерә алмады, ничә көннәр мәшәкатьләнеп

ятса да, бабкалар сүзенә караганда, баланы ярмаенча китерә дә алмавы беленеп, Камәрнең эче ярылып, баласы алынса да, бала үле күрелде. Һәм Камәр дә җан бирде. Камәрне бүлнистән алып күмделәр». Китап чыгаручыларның текстны хәзерге шрифтка күчергәндә уйсыз эшләве дә башлам яңгырашына кечкенә генә булса да зыян салган: «бүлнис» сүзе, урысчага якынайтылып, «больнис» формасында язылган.

Теле чагыштырмача матуррак һәм үзе дә тәэсирлерәк булган «Очрашу яки Гөлгыйзар»ның бетеме дә үзенчәлеклерәк. Тартмалы композиция ысулы кулланылган әсәрләрдә бетемне, башламны билгеләү кыенрак. Әсәр эчендә әсәр ике рухта язылса, сюжетлар бер-берсе белән керешмәсә, аларның структур өлешләрен аерым билгеләү дөрес булса кирәк. Әдәби кайма үз эченә берничә хикәятне тупласа, бу, гомумән, бәхәссез. Кайвакыт ул төп өлешкә рухы, аһәңе белән бик береккән була, анда экспозиция, чишелеш элементлары да очрый. Мондый чакта бетем һәм башламны кайдан эзлибез? Уйланырга кирәк. Без тикшергән әсәрдә исә төп өлеш интонацион яктан мөстәкыйль.

«Очрашу...»ны бүгенге Гаяз Исхакый, бәлки, Гөлгыйзар белән саташкан, аның чагылышын һәр нидән, һәр җирдән эзләгән Габдулланы тасвирлаган юллар белән тәмамлар иде. Укучыны хисләр биеклегендә калдыру аеруча романтик рухлы әсәрләрнең тәэсирен озын гомерле итә. Күргәнебезчә, әдип, аерым бер максатлардан, иҗат принципларыннан чыгып, алай эшләмәгән, безне яңадан бераз җиргә якынайткан.

Гөлгыйзарның «төсләре, кыланышлары, сүзләре һаман еракка китә генә» барып, үзе дә куе бер томан кебек югалган, аны үлеп яраткан, аның белән генә яши алыр кебек тоелган Габдулла инде Гөлгыйзар язмышыннан хәбәрсезлеген акларлык сәбәпләр эзли. Әйтерсең, ул безне әкрен-әкрен тынычландыра, башка бер кеше белән тормыш коруын табигый бер хәл, тормыш канунияте кебек кабул итәргә хәзерли.

Соңгы бер абзац, бу очракта бетем, Гөлгыйзарны еракта калган, ымсындыргыч яктылык һәм бераз үкенечлерәк мәхәббәт рәвешендә күңел түребезгә урнаштыра.

һәркем өчен бик үк табигый булмаган мәхәббәт тормышта бик тә табигый булган чишелешен таба.

«Бай углы»ның бетеме, мәгърифәтче әдипләрнең каләм сынаган тәүге әсәрләренә хас булганча, уңай геройларның бәхетле гомереннән хәбәр белән бетә. Үзенең формасы, интонациясе, темпы белән, тормыш төбенә төшерелгән, юкка чыккан Камәр язмышы хакындагы соңгы юллардан аерылмый диярлек.

«Ике йөз елдан соң инкыйраз»ның жанры башка. Үткәргән идеяләре тулы бер милләтне исән-имин калдыруга юнәлтелгән, үзәккә дә аның аерым бер социаль төркемнәре генә куелмыйча, тулы бер милләт алынган. Әдип «Инкыйраз...»ның башлам, бетем өлешләренә дә башкачарак якын килә. Соңгы абзац алда сөйләгәннәрдән нәтиҗә кебек бирелсә дә, анда төп өлештә әле асмәгънә рәвешендә һәм теләсә кем тота алмый торган бер фикер бар:

«Русиядәге шулкадәр безгә бирелгән иркенлек, безнең хактагы гадәләт һичбер мәмләкәттә, һичбер милләте мәхкүмәгә (буйсынган милләткә — тәрҗ. Р. Х.) бирелмәгәндер. Шуңардан да файдаланырга гайрәтемез, хәмиятемез калмаганмыни?» Дөньядагы хәлләрдән хәбәрдарлык Гаяз Исхакый сүзләренең соң дәрәҗәдә заманчалыгым раслың. Төркиядә яшәгән көрдләрнең милләт буларак та танылмавы, Үзбәкстандагы урыннан урынга куылып йөртелүче төрек месхетинлылары, Украинада сан исәбенә дә алынмаган кырым татарлары... Гаяз Исхакый безнең соң дәрәҗәдә хокуксызлыгыбызны, әлбәттә, белә, әмма хәтта булган мөмкинлекләрдән дә файдалана алмавыбызга борчыла, схоластика сеңгән татарларның аяныч язмышын фаразларга алына.

## Ф. Әмирханның «Яшьләр» пьесасында аталар һәм балалар каршылыгы

Ф. Әмирханның «Яшьләр» пьесасында олы һәм яшь буынны үзара каршылыкка керткән мәсьәләләр бик күп, шуңа да карамастан язучы әсәр конфликтын алар арасындагы килешмәүчәнлеккә генә кайтарып калдыруыбызны, пьесаның төп фикерен тарайтып аңлавыбызны теләми һәм төп герой Газиздән болай дип әйттерә: «Бу

кычкырышлар, бу тавышлар безнең белән этиләр арасында түгел. Аңлыймсың? Түгел. Бу тавышлар — иске тормыш белән яңа тормыш арасында. Безне, балалары булганга күрә, этиләр сөяләр; безнең өчен, үз белүләренчә, иң якын яхшылык теләүче булганга күрә, без аларны сөябез. Шулай да алар безне сүгәләр, без аларны гаеплибез... Ник? Чөнки алар тормышы безгә, безнең тормыш аларга ошамый».

Җәмгыять алга бара, театрлар туа, яңа эчтәлектәге китаплар басыла. Алар татарның катып калган акылын сискәндереп җибәрә. Олы буынның моңа кадәр күнеккән тормышына һөҗүм ясалгандай була. Курыкмаслык та түгел, яңача белем алган Гали европача киемгә күчә, сөйләменә рус сүзләре күп кыстыра, әти-әнисеннән узып сүз әйтә. Гасырлар дәвамында үзен аклаган, ныгыган традицияләр җимерелер һәм татар тормышына зур зыян килер дип уйлый алар. Әлбәттә, бу караштa да берникадәр хаклылык бар, әмма, ничек кенә булмасын, яңалык көннән-көн зур көч ала, һәр гаиләгә, һәр кеше аңына үтеп керә.

Газизләр белән еш ачуланышса да, Хөсәен абзый да элекке Хөсәен түгел инде, кияве Рәхимҗаннан күпкә алдынгырак карашлы ул: төрле җәмгыятьләргә дә йөри, балаларына да яңача белем бирүдән баш тартмаган, аның дин белән каршылыкка кермәвен аңлаган. Ул хәтта киявенә, син — ысулы кадим, дигән гаеп ташлый. Чагыштырмача яшьрәк булганнар арасыннан да тискәре типларны сайлау Ф. Әмирханга яңалык белән искелек көрәшенең ике буын арасында гына бармавын, аның иҗтимагый асылын аңлатырга ярдәм иткән.

Искелек басымына азрак эләккән яшьрәкләргә яңалыкны кабул итү җиңелрәк булган, һәм алар үзләре дә шуны тарату юлына басканнар. Әле кайчан гына абыйсына каршы төшкәләгән Йосыфның, учительгә йөри башлагач, дөньяга карашы тәмам үзгәргән.

Хатын-кызлар аңына яңалык акрынрак үтә. Дини-милли традицияләрдән ныграк басылганга, «гаилә морале» ныграк сеңгәнгә, ата-анадан курку, аны хөрмәтләү көчлерәк булганга, бу төркем үзгәрешләрне тиз генә кабул итә алмый.

Яңалык нәрсәдә чагыла соң дигән сорау туа. Киемдә, үз-үзеңне тоту әдәбендә, белемгә, ата-ана, кеше фикеренә, милли сәнгать, әдәбият, тәрәккыят, халыкның яшәү дәрәҗәсенә һәм башкаларга мөнәсәбәттә... Алдынгы яшьләр тормышның һәр өлкәсенә үзгәрешләр керүне яклый, чөнки алар ирекле шәхес тәрбияләргә, катып калган традицияләр коллыгыннан чыгарга ярдәм итәр дип саный.

Әдәпсезрәк, туры сүзле Газиз һәм Йосыф кебекләрнең үз-үзләрен тотышы «Көфер почмагы» калдыкларының, фәхешханәгә йөрүенә карамастан, урамда кызлар белән аралашкан Газизләрнең гайбәтен тараткан ике-йөзле Мөхәммәтҗаннарның әхлагыннан югарырак бәяләнерлек. Хөсәен абыйның: «Намаз укымагач, мин сезнең фәхеш артыннан йөрмәвегез белән нишлим?!» — дигәне дә аның ялган тәкъвалыкка ризалыгын күрсәтеп тора.

Дин, шәригать, милләт байрагын күтәргәнгә салынып, акыл өйрәтүче Рәхимҗаннарга дини дә, дөньяви да белем алган яшьләрнең җавабы әзер. «Син — шәригатьнең нәрсә икәнен ата-бабаңнан гына ишетеп белгән кеше, миңа, унбер ел голуме диния тәхсил иткән кешегә, шәригатьтән дәрес бирергә тотындыңмы? Оят кирәк! Сукырның күзлене җитәкләве бу!» — ди Газиз җизнәсенә.. Бу сүзләр тагын бер кат конфликтның аталар һәм балалар арасында бармыйча, наданлык һәм белемлелек арасында тууын күрсәтә. Шул ук вакытта искелек тарафдарларының күпчелеген олы буын тәшкил иткәч, җәдитчеләр, нигездә, яшьләр булгач, без аны бик шартлы рәвештә аталар һәм балалар арасындагы көрәш дип тә атый алабыз.

## Ф. Әмирханның «Яшьләр» пьесасында халыкчылык мәсьәләсе

Ф. Әмирхан — үз чорының иң алдынгы карашлы язучыларыннан. Рус, Европа мәдәниятен белү аңа әдәбият мәйданының алдынгылары сафына басарга ярдәм иткән. Иҗтимагый вакыйгаларга актив катнашу, рус язучылары иҗаты белән танышу аның карашларын, иҗат офыгын киңәйткән.

«Яшьләр» пьесасының төп герое Газиз үзенең туган-

нарын яңа фикерләр уздырган русча китаплар белән таныштырып бара. Сеңлесе Зәйнәпнең дә күзен шулар ачар дип өметләнә ул. Без әлеге китаплар арасында Тургеневның «Отцы и дети» әсәре булуын күрәбез.

«Отцы и дети» романында XIX гасырның илленче елларыннан соң Рәсәйдә төрле юнәлештәге иҗтимагый көчләр, карашлар формалашу процессы күрсәтелә. Аның төп герое Базаров олы буынга бераз хөрмәтсезрәк, аларны кискен тәнкыйть итүчәнрәк, элекке традицияләрне кире кагып, тормышта яңача яшәүне алга сөрә.

Без Ф. Әмирханның «Яшьләр» пьесасында да шундыйлар белән үк очрашабыз. Монда милләтчеләр, халыкны агартырга алынган интеллигентлар, иске карашлы руханилар, башкалар бар. Рус һәм татар прозаигы тудырган геройларны билгеле бер янәшәлектә карап булыр иде, шул ук вакытта татар романындагы яшьләрнең һәрберсендә дә Базаров холкындагы аерым сыйфатларны, аңа хас карашларны күрергә мөмкин. Йосыфның тотышындагы кычкырып торган дорфалык, Ибраһимдагы кебек «денсезлек», Галидәге халыкны аңларга тырышу, аны агартып булуга өмет итү, шул ук вакытта Ибраһимның җәмгыятьне үзгәртеп кенә, халыкны бәхетле итеп була дип ышануы...

Кайбер рус тәнкыйтьчеләре Базаровны эзлексез образ, катлаулы дип бәяләгән. Ф. Әмирхан карашлары белән бер-берсеннән ачык аерылган, яшәү рәвешләре, «аталар»га каршы чыгулары белән охшаган геройлар галереясе тудырган.

Ф. Әмирхан әсәренең үзәгенә халыкны тәрәккыяткә илтү мәсьәләсе куела, һәм аерым иҗтимагый катлам вәкилләренең һәрберсе аның чишелешен үзенчә күрә. Мәдрәсә гыйлемле, яңача укырга өйрәнгән Хөсәен абзыйны борынгыларның яшәү рәвешеннән артык ераклаштырмаган кечкенә генә үзгәрешләр дә канәгатьләндерсә, аның дөньявирак белем алган балалары иҗтимагый үзгәрешләргә өметләнә.

Әсәрнең илдә барган мәдәни-иҗтимагый хәрәкәт белән бәйләнеше шактый зур. Бу вакытта бигрәк тә руслардагы халыкчылык (народниклык) хәрәкәте, аның идеологиясе, шул идеологияне уздырган әсәрләр (шул

исәптән Тургенев иҗаты) йогынтысында татар әдәбиятында да халык арасында аңлату алып барган разночинец образлары тудырыла. Ф. Әмирхан пьесасындагы яшьләрнең күпчелеге халыкчыларны тәшкил итә дип уйларга кирәк. Болар: Гали, Газиз, Йосыф.

Гали киләчәктә барасы көрәшләр өчен хәзерлек эшләре башкарырга, искелек калдыкларына каршы кискен фикри сугыш ачарга, халыкка аңлату эшләре алып барырга кирәк дип саный.

Йосыф Думада утыручы консерватив карашлы дворяннарга өмет багламый, аның төп ачуы төрле доносчыларга, карагруһчыларга, милләтче битлеге астына яшеренгәннәргә юнәлтелгән. Әтисенең әйтүенә караганда да, ул Газиз юлыннан бара.

Газиз исә — «Отцы и дети» кебек әсәрләрнең идеяләре белән коралланууда. Хәер, ул укыган китаплар арасында Тургеневның башка әсәрләре дә булырга охшый. Беренчедән, бу пьесага рус әдибе иҗат иткән башка китапларның да тәэсире бик нык сизелә. Икенчедән, иптәше Гали дә: «Без Рудиннар, Базаровлар була алсак, халыкка бертуктамый искене җимерү идеясен сөйләсәк, киләчәктә чын эш эшләрлек кешеләр җитешерләр, яки без үзебез үк күп тәҗрибәләр белән эшләрлек кешеләр булып чыгармыз», - дип белдерә.

Гали халыкчыларны «переходный типлар» (күчеш типлары) дип атый. Аның карашынча, алардан артык актив хәрәкәт көтеп булмый, чөнки хәзерлекләре җитми.

Әсәрдән без халыкчыларның барысының да, Базаров кебек үк, дини идеалларга исе китмәвен күрәбез. Газиз, безнең яңалыкны яклап көрәш идеалымыз дини идеаллардан югарырак, руханирак, дип белдерә.

Халыкчыларның хыяллары тормышка ашачагына өмет бармы соң? Юк, әлбәттә. Моны авылга китеп укыткан, халык тарафыннан куып җибәрелгән Зәкәрия мисалында раслап булыр иде. Без Тургенев иҗат иткән Базаровны да гади халыкның аңламавын, кабул итмәвен күрәбез. Халык арасына көчләп керергә кирәк, дигән иптәшләренә дә Зәкәрия моның мөмкин түгеллеген белдерә. Димәк, әсәрдә халыкчылыктан ваз кичү ал-

дында торган геройлар да бар, яшьләр арасында аны тәмам кабул итмәүчеләр дә юк түгел.

Социал-демократик карашлы Әхмәт, хезмәт халкын, сыйнфый аң кертеп, социаль гаделсезлекләрнең асылын аңлатып кына, көрәшкә күтәреп була дип саный, мәктәпләр ачуның гына милләтне алга җибәрмәячәген әйтә. Зыя белән Гали икесе берьюлы: «Бу сүзләрдән 1905 нче ел исе килә. Грамотность — сознаниенең башы», — диләр. Аларның җавабында бераз өркеп калу да, үз карашларын яклау да бар.

Төп герой исемен йөрткән «Рудин» әсәре Тургеневның студент еллары истәлекләренә таянып язылган була. Ул Станкевич түгәрәгенә йөри, милләтне алга җибәрү хакында бәхәсләрнең үзәгендә була. Ф. Әмирхан иҗат иткән геройлар да — русча укучы яшьләр, гимназистлар, алар максатлар уртаклыгында җыелган бер төркемне хәтерләтә, һәм әлеге төркемнең үзәгендә Гали тора шикелле. Ул Тургеневның Рудинына аеруча охшаган: аның шикелле үк югары идеаллар белән яши, аларның тормышка ашасына ышана, шул ук вакытта моның өчен гамәли адымнар эшләгәне дә юк.

Иҗатында әллә никадәр халыкчылар тудырган Тургенев үзе әлеге хәрәкәтнең нәтиҗәләренә ышанганмы соң? Белгечләр, юк, диләр, һәм моны әсәрләренә салынган эчтәлек белән үк раслыйлар. Ф. Әмирхан да аның кебек үк уйлаган. Милли тәрәккыят мәсьәләсендә Әхмәт әйткәннәргә өстенлек бирүе әнә шуны күрсәтә. Алайса ни өчен бу ике талантлы язучы иҗатларында халыкчылык карашларына шул дәрәҗәдә урын биргән? Минемчә, тормышчанлыкны алга сөргән әдипләр җәмгыятьтә урын алган, киң таралган күренешләрдән кача алмый, аларны чынбарлыктагыча сурәтли, мөмкин булганда, аларга үз мөнәсәбәтен дә белдерә.

## Ф. Әмирханның «Яшьләр» пьесасында яңача яшәү идеалы

«Яшьләр» пьесасында катнашкан геройларның күпчелеген милләткә хезмәт итү, аны алга җибәрү уе берләштерә. Тәрәккыятнең юлларын да, яңача яшәүне дә яшьләр төрлечәрәк аңлый шикелле, әмма шунысы ачык: ата-бабалары барган юлдан китмәячәкләр һәм

аларча яшәмәячәкләр. Без моны Газиз мисалында расларбыз.

Газиз, Йосыф белән чагыштырганда, йомшаграк, әти-әнисенә хөрмәтлерәк, нечкә күңеллерәк күренә. Моны, беренчедән, аның яше, тормыш тәҗрибәсенең зуррак булуы белән бәйләп карарга кирәк. Икенчедән, ул иске карашлы апасының, хәзрәт әтисенең үзләренең дә гореф-гадәтләрнең, милли яшәеш дәрәҗәсенең корбаннары булуын таный һәм шуның өчен аларны бик кызгана.

Дөрес, кайчак Газиз дә чыгырыннан чыккалый һәм якын кешеләренә кискен сүзләр әйтеп ташлый, әмма ул, әтисе кергәндә, башына кәләпүш кияргә, сеңлесе елаганда, юатырга тырыша. Апасының да яшь чагында бөтенләй башка булуын исенә төшерә, гаилә басымы, мәгънәсез ир, ирекне бууачы дини-милли гадәтләрнең аны никадәр үзгәрткәнлеген күреп, бик нык борчыла.

Газиз тормышны бик дөрес күзаллый, ул әтисе белән ике арада туган каршылыкны искелек һәм яңалык арасындагы конфликт чагылышы икәнлеген аңлау дәрәҗәсенә үк күтәрелгән. Гимназиягә укырга керү аннан бөтенләй башка кеше ясаган, һәм Хөсәен абзыйларның гаиләсен дә умарта күчедәй болгаткан, җәмгыятьтәге үзгәрешләр аларга башкалардан алдарак үтеп кергән. Гали үзен ирекле тота, заманча киенә башлаган, әмма ул моның бары тик тышкы форма гына икәнлеген дә белә. Егет эсседә калын киенүне, йөзеңне кояштан яшерүне аңлый алмый.

Газизне барыннан да бигрәк кешенең шәхси иреге мәсьәләсе борчый. Ул кешеләрнең бер-берсенең эчке дөньясына тыкшынуын кабул итә алмый, хатын-кызлар аеруча кыерсытылган дип саный, аларны көрәшчеләр рәтендә күрергә тели: «Сез, хатыннар, бу сугышта — искелек һәм яңалык сугышларында безнең тарафта булырга, яңалар тарафында булырга тиешләрсез». Зәйнәпне тирәлек фикере белән йөргән ата тәэсиреннән, ул хәзерләячәк язмыштан саклап калырга теләсә дә, бөтен татар галәмен үзгәртми торып, сеңлесе кебекләрне ата-ана коллыгыннан коткарып булмаслыгын аңлый.

Газизне маржалар белән дуслашуда гаеплиләр, ләкин рухы белән чын мәгънәсендә милләтче егет алдынгы карашлы Сараны үз итә. Шул ук вакытта Газиз алдынгырак милләтләрдән саналган рус тормышын яхшы белә, бигрәк тә искелек белән көрәштә алардан үрнәк алырга кирәк дип саный. Ә бит чит әдәбият аңа бигрәк тә халыкчылык идеяләре белән коралланырга булышлык иткән.

Газиз «толпа» аерым бер кешегә каршы тора дигән карашта һәм аны «үзенә законодатель танырга теләми». Аны сыраханәләрнең байлыгы татарлардан җыелу, фәхешханәләрнең чәчәк атуы, зәкятләрнең яртысы гына бирелү борчый. Хәтта Коръән хәрам дип санаган бозыклыкка каршы төшмәгән динчеләр эчке дөньялары пакь яшьләр белән сугыша. Газиз аңлылык, эчке чисталык белемгә бәйле дип уйлый, университет тәмамлау турында хыяллана.

Ф. Әмирхан Газиз образы аркылы татар җәмгыятендә туып килгән яңа тенденцияләрне, проблемаларны, типларны күрсәтә, шәхеснең кыйммәте, аның рухи ireккә лаеклыгы концепцияләрен уздыра.

## М. Гафури поэзиясе — «чорның күзе һәм колагы»

> Бер-бер әһәмиятлерәк вакыйга яки мәсьәлә күренсә, ул аларны эләктереп алды да үз фикерләре һәм тойгылары белән җылытып әдәбиләштерде.
>
> *Әхәт Нигъмәтуллин*

М. Гафури заман тудырган шагыйрь, заман идеяләре һәм тойгылары җырчысы иде. Аның идея-эстетик яктан үзгәрүе аерым бер чорларда бөтен татар әдәбияты кичергәннәргә аваздаш булды. Шагыйрь гомер буе милләтне тәрәккыят юлыннан ничек алып барырга соравына җавап эзләде сыман.

Әле беренче шигырьләрендә ул, татар хезмәт ияләрен мәгърифәтле итеп, хәерчелектән, рухи коллыктан коткарырга өметләнде. Тора-бара аның әсәрләрендә самодержавие тәртипләренә, дини фанатизмга ризасызлык көчәйде, ул инде бар көченә фәкыйрь халыкны кайгыртырга, татар мәдәниятен алдынгы халыкларныкы дәрәҗәсенә күтәрү юлында көч түгәргә тотынды.

Беренче рус революциясе елларында М. Гафуриның шигъри авазы меңнәр колагына барып иреште. Ул аларда заманның бөтен төсләрен чагылдырырга, вакыйгаларын теркәп калырга, халыкның уй-максатларын чагылдырырга ашыкты.

1905 елның октябрендә язылган «Алмашыну» шигырен алыйк. Анда илдә барган түнтәрелеш, көчәеп киткән иҗтимагый хәрәкәтләр, фиркаләр, алар тоткан мәсьләкләрнең үтә төрлелеге турында сөйләнелә. Шул ук вакытта шагыйрь, зур мөмкинлекләр ачылуга карамастан, халыкның битарафлык йокысында булуына борчыла:

Караңгылык барсы бетеп, таңнар атар,
Ни сәбәпле безнең халык гафил ятар...

Бер ай да узмый, М. Гафури заманга «хөррият дәвере» дигән мөһер суга, шул ирекләрне чагылдырып, шигырьләр иҗат итә:

Ватылды хәзинәнең йозаклары,
Өзелде аяктагы тозаклары.
Хәзинәнең эч ягына күзне салсаң,
Күзгә төшәр һәр милләтнең үз хаклары.

*(«Хөррият дәверендә»)*

М. Гафурины халыкның һаман да шуны аңламавы, тарихи бер чорда хакын дауламавы, алдынгы милләтләр рәтенә күтәрелә алмавы аптырата.

М. Гафуриның инкыйлаб елында иҗат иткән шигырьләре арасында хәрәкәткә әйдәгән, аңа вакыт җиткәнлекне ассызыклаганнары үзәктә тора: «Вакыт җитте», «Алга китү»... Ул кеше башкаларга аңсыз иярмәскә, үз фикерен булдырырга тиеш дигән караштa тора.

Шул вакытта иярүдән файда тияр, —

ди ул бу хакта «Вакыт җитте»дә.

Революцион күтәрелеш еллары булса да, М. Гафури әле мәгърифәтчелек карашларыннан ваз кичми, халыкка аң-белем бирүне һаман да тәрәккыятнең бер юлы дип карый:

Я татар! Вакыт җитте тырышырга,
Мәгариф шәмнәрен кулга алырга,

Уйламыйча, гафил булып карап ятмый,
Вакыт җитте гыйлем, һөнәр кулланырга.

1905 елгы революциягә сөенеп, «Шатлык» шигырендә М. Гафури:

Алынды авырлыклар кулымыздан,
Манигъ юк бара торган юлымызда, —

дип яза. Патшаның хезмәт халкына биргән җир һәм ирек хакындагы вәгъдәсенә ышана, милләтен дә үзенә фикердәш хис итә:

Тәбрик итеп, милләтемә язам шигырь,
Фикремез бер-берсенә кушылганга.

*(«Шатлык» шигыре)*

Беренче рус инкыйлабы шагыйрьне рухи үстерә, талантының ачылып китүенә булыша, аның дөньяга күзе дә ныграк ачылгандай була, һәм ул үзе күргәннәрне, ишеткәнне, аңлаганны башкаларга да образлы тасвир, аһәңле яңгыраган сүз аша җиткерә.

## Рус шигъриятенең Г. Тукайга тәэсире

Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов әгәр булса кояш,
Ай кеби, нурны алардан икътибас иткән бу баш.

*Г. Тукай*

Теләсә кайсы каләм иясе ниндидер әдәби традицияләрдә тәрбияләнә, аның таланты укыган әсәрләренең шифалы йогынтысында ачыла. Кайвакыт, әйтик, шагыйрь, кемгә дә булса иярүне үзмаксат итмәс, әмма язганнары табигый тәэсирләр аркасында башка бер иҗатчыныкына охшар. Әнә шулай бик күп укучыларын, тулы бер мәктәпләрен тудырган каләм ияләре бар.

Татар шигърияте хакында сөйләгәндә, без Тукайлар, Такташлар мәктәбе... дибез. Ә бит алар укыган, яраткан, язганнарына табынган шагыйрьләр дә булган. XX йөз башы татар әдәбияты, европачалыкка йөз тоткан-да, рус классикасын үзенә кыйбла иткән.

Тукайның Пушкинны, Лермонтовны яратуы, аларны поэзия йолдызлары итеп санавы мәгълүм. Югарыда китерелгән эпиграф та әнә шул хакта сөйли.

Башка әдәбиятларны өйрәнүнең кирәклеген һәм инде

гадәтилегән шагыйрь түбәндәге юллар аша җиткерә:

Бездә ят, чит телдәге изге фикерне тәрҗемә
Биш вакытта намаз күк керде инде фарзыма.

Тәрҗемә серләренә Тукай аеруча Жуковскийдан, ияреп язуда Пушкиннан өйрәнә. Шул ук вакытта тәрҗемә принципларын әдәби традицияләргә нигезләнеп эшли. Аның хәтта оригиналга якын саналырлык тәрҗемәләрендә дә Тукайның үзен, шул чор татар шигърриятенең яңгырашын, үзенчәлекләрен тою кыен түгел. Кирәк санаганда, ул әдәби үрнәккә яңа юллар өсти, андагы фикерне үзгәртеп җибәрә яисә, авторның төп идеясен ала да, шуңа нигезләнеп, инде бөтенләй икенче бер шигырь иҗат итә. Мондый әсәрләрне ияреп язылган шигырь — тәкълид, нәзыйрә дип атарга мөмкин.

Тукайның рус әдәбиятыннан тәрҗемәләре татар шигърриятен үстерүгә, аны тел ягыннан баетуга хезмәт итә.

Тукай рус шагыйрьләреннән Лермонтов белән Пушкинны бигрәк тә үз күрә. Алардан шигъри сүз һәм фикер нәфислегенә өйрәнә.

Мин Тукайның Лермонтовтан үзгәртеп язган мәхәббәт шигырьләрен яратам. Үз алдыма ул ни өчен, нәкъ менә Лермонтовка ияреп, «Хур кызына» шигырен язган соранып куйдым һәм җавабын да таптым: «К деве небесной»да сурәтләнгән мәгъшука татар кызына, үткән мирасыбызда тасвирланган образларга охшаган икән ләбаса! Ул — «Кыйссаи Йосыф»тагы Зөләйха кебек, ул — җәннәттә генә була торган хур кызы инде менә! Аның һәр сүзе, тавышы, йөрешләре җанга рәхәт:

Синең һәрбер сүзең җанга рәхәт,
Синең һәрбер сүзеңнән күңел ял итә.

Синең гәүдәң яратылган күк өчен,
Телең — зикер-тәсбих өчен, мактау өчен...

Тукай, әлбәттә, Пушкин белән Лермонтов иҗатының киңлеген, тирәнлеген, бер мәхәббәт шигырьләреннән генә тормавын белә һәм алардан төрле яктан өйрәнә дә. Ул бик хаклы рәвештә бу зур ике шигърриятне — «олуг саф диңгез»гә, аларны тудыручыларның үзләрен

йолдызга тиңли. Татар шагыйре үз урынын исә рус шагыйрьләренең янәшәсендә күрә.

Тукай, Пушкин, Лермонтов... Мине таңга калдырган өч шагыйрь.

# XI сыйныф

ГҮЗӘЛ ГАМЬ

### Яңа әсәр укыгач

Әхәт Гаффар — шактый үзенчәлекле язучы. Аның әсәрләре тел-сурәтләү ягыннан да, үзәккә куелган вакыйгалары белән дә башкаларныкыннан нык аерылып тора. Һәр яңа китабын укыган саен, мин аннан аңа хас оригинальлек көтәм, үзенчәлекле булса да, әсәре озын яисә кыска гомерле булыр микән дип уйланам.

«Язлар моңы» пьесасы да минем өчен яңа иде әле. Ә. Гаффар аны формалаштыруны ук «могезле» итә: прозага ияреп булса кирәк, пьесаны бүлекләргә бүлә һәм исемли, әйтерсең, сәхнәдә бу атамаларны күрсәтеп, чагылдырып була. Драматургның мин элегрәк укыган кайбер пьесаларында да күзәтелә ич бу сыйфат! «Соңгы ләкләк»тә ул әсәр өлешләрен — кисәк, ә менә «Чатта»-да, «Җиләк вакыты бер генә»дә пәрдә дип билгеләгән һәм соңгы пьесада бүлекләрне «Зөфаф кичәсе», «Дөнья җылысы» дип исемләгән кебек хәтердә сакланган. Оригиналь яңгырашлы әлеге атамалар мәгънә тирәнәйтү вазифасын башкармый, беренчесе артык турыдан-туры әйтелгән, икенчесе эчтәлеккә туры ук килеп бетми шикелле.

Җыентыкка кергән пьесаларның сюжетлары, үзенчәлекле булса да, бик үк тормышчан һәм укырга кызыклы тоелмады миңа. «Язлар моңы»н аңлау өчен дә, бормалы юллар узарга кирәк. Автор фикерне буталчыкландыручы диалоглар куллана. Аның прозасында да укучыны аптыратырга, шаккатырырга тырышу бар бит.

Ә. Гаффар геройларыннан, авылның бер башында үлем булганда, икенче башында туй итәргә ярамый, дигән ырым бар дибрәк әйттерә. Әлбәттә, татар кешесе кемгәдер хәсрәт килгәндә шатланганны өнәми, әмма ул

аны начар фал дәрәҗәсенә җиткерми һәм туй кадәр туйны өзми. Илдә, зур шәһәрдә үлем-җитем, туй булмаган көн бармы?! Фәрдәнәнең тарих дәвамында авылда үлем белән туйның бергә килмәвен әйтүе ышандырмый. Хәсән Сарьянның; автобиографик җирлекле «Бер ананың биш улы»нда егетнең абыйсы үлгән көнне туй ясыйлар. Тормышта без шул хәлләрнең ничә мәртәбәләр шаһиты булмаган! Шул ук вакытта пьесада да туйга каршы төшүдә чын сәбәп хорафатта гына да түгел кебек. Геройларның үз-ләрен кирле-мырлы тотуы, берсе ризалашса, икенчесе-нең каршы килүе теләкләренең ачык түгеллеген күр-сәтмимени?

Язучы урынлы-урынсыз Тукай сүзләрен кыстыра, аны халык исеменнән дә җиткерә. Кайсы герой нәрсә тели, нәрсә сөйли — һич аңламассың. Сара ниндидер бер ка-рачкы урынына кулланылган образдай кабул ителә башлый: башкаларны бертуктаусыз өркетә, яманлык-яхшылык турында фәлсәфә сата. Әллә хатын-кызлар хәтер яңарта, әллә үлгәннәрнең рухы кайта: Ярми-Сәгыйдуллалар кереп чыгып, сөйләшкәләп йөри.

Син нәрсә дә аңларга белми торганда, туй башлана. Фәрдәнә карчык, туйда катнашмыйча, балан ашап уты-ра. Башында яңарган хатирәләрнең буталчыклыгы! Кемне ярата ул, кем белән яшәгән... — кайсын төшенә-сең, кайсын чамалыйсың, кайсын юк. Түрдә генә уты-расы геройлар да — үз эшләрендә, гел тыш өйгә чыкка—лап йөриләр. Геройларның күтәренкелек белән югарьх материяләр турында сөйләүләре, бертуктаусыз афоризм-нар атулары, татарча төзелмәгән җөмләләре, җирле сүзләр пьесаны чиктән тыш ясалмаландыра, кызыксыз итә. «Кешеләрнең дә борынына боҗра кидерелгән, Сәгыйдулла», — ди Фәрдәнә. Ә. Гаффар өчен (үз як сөйләшеннәндер инде) балан тәлгәше дә — бөрчегән.

«Сагыш җыры» дигән бүлекнең вакыйгаларын чор-ларга салу кыен, бер үк геройларның төрле яшьтәге чакларын, тиз аралашканда, ничек сәхнәләштерергә? Драманың композициясе турында да бик нык уйлана-сы бар. Әсәрнең конфликтын табу минем өчен бик авыр тоелды. Әллә ул һәр кеше күңелендәге эчке конфликт кына микән? Мөгаен, кеше, мин ничек яшәргә тиеш,

дигән сорауга җавап эзлидер. Сәгыйдулла, Фәрдәнә, Ярми, Сара кебекләр намуслары кушканча яши, минемчә.

Әллә пьеса конфликтын яшәү һәм үлем арасындагы бәхәс дип аңларга кирәк микән? Җыр да үлемгә дучар ителә бит, шул ук вакытта яшәргә хокукын да раслый. Бу конфликт та бик таркау, йомшак шул.

Әсәрнең миңа охшаган ягы: геройлар арасындагы дуслык хисе бар нәрсәдән дә өстен булып чыга. Авырлыклардан соң килгән шатлык кешегә чын бәхет кебек тоела.

Әдәби геройларның уңайлардан гына торуы да үзара бәхәсләрне йомшак итә. Аларның бер-берсеннән нык аерылмавы — фикер сөрешләре, сөйләм, яшәү рәвеше охшашлыгы да — пьесаның җитешсез ягы. Персонажлар күп, характерлар муллыгы күзәтелми.

Кыскасы, Ә. Гаффарга шактый уйланырга, тормышка якынаерга кирәк әле.

## Ә. Гаффарның «Язлар моңы» драмасының идея-тематик эчтәлеге

Ә. Гаффар — һичшиксез, талантлы язучы. Әдәбият мәйданына прозабызның нык үскән бер чорында — җитмешенче елларда килгән ул. Шул чакта ук бик үзенчәлекле язучы буларак танылган. Сиксәненче елларда әсәрләре русчага тәрҗемә ителү аны бөтен СССР га таныткан. Утызар, иллешәр мең тираж белән чыккан бит аның китаплары! Минемчә, Ә. Гаффар русчада бигрәк тә укылышлы, телендә кайчак тоемланган ясалмалылык, уйлап чыгарган үз сүзләре калмый.

Кызганыч ки, драматургия жанрында бик актив эшләсә дә, бүгенге көндә аның пьесалары зур театрларыбызда сәхнәләштерелми. Ә бит аларның искиткеч уңыш белән барган чаклары булган!

Әдипнең көндәлек тормышыбызга һәм заманның үзенә хас проблемаларын күтәргән, метафора, символмәгънә синтезына корылган драмалары арасында «Язлар моңы» пьесасы да бар. Анда әлеге алымнар геройларның фәлсәфи фикер йөртүче акыллы кешеләр икәнлекләрен күрсәтүгә ярдәм итә, ә алар, үз чиратында, безгә, Ватан сугышындагы җиңү миллионнарча корбаннар хакына килде, дигән фикерне җиткерергә булыша.

Пьесада катнашкан һәрбер герой йөрәге аша узган сугыш ул, аларның шәхси бәхетен җимергән афәт.

«Язлар моңы»нда символик мәгънәгә ия детальләр бик күп. Кыңгырау чыңы, пычак кадалган гармун, кисмәктәге су, өзелгән җыр... Юк, җыр гына да түгел ул, тормыш җыры. Өзелә язган, әмма яңа сулыш: белән башкалар күтәреп алырга тиешле җыр.

Сәхнә күренешләренең еш алмашынуы, аларда хәтердә сакланган вакыйгалар белән бүгенге хәлләрнең үзара керешүе дә аерым бер максаттан чыгып эшләнгән. Кеше үткәннәр белән яши, узган гомер гыйбрәтләр алырга өйрәтә һәм бер ясаган хаталарны кабатламаска булыша. Язучы әнә шулай дип әйтә шикелле. Чынбарлыкның иллюзияләр белән кушылуы кешенең иллюзияләргә бирелүчән күңелен дә аңлата түгелме? Кыскасы, бу әсәрдә шартлылыкка урын җитәрлек. Иҗатчының абстракт фикер йөртүгә, иҗади уйланмалылыкка сәләтен, шигъри җанын күрсәтеп тора ул шартлылык. Мин Ә. Гаффар иҗатын шуның өчен яратам да!

Үзәккә «тормыш җыры», «сагыш җыры», гомумән, җыр куелган әсәрләр татар прозасында җитәрлек. Алар драматургиядә дә очрый. Ә. Гаффарның «Язлар моңы» пьесасы шуның бер мисалы.

Туу бар җирдә үлем бар, ди язучы. Туйлар — тууга бер адым. Алар шатлык, бәхет китерә. Үлем яшәү мәгънәсе турында уйлата. Кеше гомеренең ике башында торган бу вакыйга — һәрвакыт үзара көрәштә. Туйның кызган мәлендә геройларның берсе — авылда үлек бар көнне туйның яхшыга булмавын әйткән Фәрдәнә карчыкның да үлеп китүе шушы хакта тагын да искәртә. Шул ук вакытта яшәү дәртен, аның тәмен, тантанасын, яшәүнең кыскалыгын искәрткән вакыйгалар да, үткән гомергә бәйле сагышлар да һәм хәтта «язлар моңы» да баса алмый. Юк, язлар моңлы булырга тиеш түгел. Ул яшьлекнең үзе кебек дәртле булырга тиеш! Язлар — тамыр, бөре шыткан чак.

Язучы әсәргә куйган атамасы белән мин алда язган фикерләрне җиткерергә теләгәнме? Әллә шатлыклы булырга тиеш язны «моңлы» итеп, тормышның көтелмәгәнлегенә ишарәләгәнме? Шартлылыкка, метафоралар-

га корылган әсәр синең үзеңә дә уйларлык мөмкинлек калдыра. Әнә шул уйландырган, фикерне уятканы өчен укыйм да инде мин Ә. Гаффар пьесаларын. Алар нигезенә салынган тирән мәгънәне эзләп укыйм.

## Бүгенге әдәбиятта милли проблемалар

Язучы, шагыйрь иҗаты, милли проблемалар белән сугарылмаса, милли аһәңнәргә ия булмаса, җирдән, чынбарлыктан тәмам аерылса, кыска гомерледер дип уйлыйм. Мәхәббәт шигырьләре генә язып та, мәңге онытылмаска мөмкин. Бу очракта да халыкка синең язганнарыңның якынлыгы, аңлаешлылыгы кирәк. Укучы, бит нәкъ минем турында, дип укысын!

Милләт мәнфәгатьләрен кайгырткан, аның үткәнен, бүгенгесен бөтен хәсрәте-шатлыгы белән чагылдырган иҗатчы алдында үзен шул милләт баласы дип тойганнар баш ия.

Бүгенге әдәбиятта милли проблемалар хакында сөйләгән инша бик гомуми планда булыр иде. Мин аның бер талантлы вәкиле — Роберт Әхмәтҗанов иҗатына тукталырга һәм аның «Тургай тәрәзәсе» китабы мисалында инша язарга телим.

Р. Әхмәтҗанов — тасвирлар шагыйре. Ул синнән бөек булып кыланмый, сиңа акыл сатмый, әмма аның ни әйтергә теләгәне йөрәгеңә үзе бәреп керә. Менә «Иделдә җәй» шигыре. Кемдер шунда ук пейзаж шигыре икән дип тә уйлап куйгандыр. Әйе, эченә үтә алмаганнарга пейзаж тасвиры гына булып калган бу шигырьгә тирән мәгънә яшеренгән. Шагыйрь анда «Җил һәм Кояш Республикасы» дип атаган табигатьнең үзеннән, аерым бер кешедән торган дәүләтләр турында сүз алып бара. Анда сугышлар, үзара кыерсытышулар юк. Ирексездән үз тарихың, танылмаган дәүләтең турында уйланасың. Ә бит шигырь инде 1966 елда ук язылган.

Шагыйрь белән бер үк төсле уйлавыңны искәрткәндәй, тояк тавышлары ишетелә. Бу — бөек дәүләтләре булган һун бабаларыбызның, империя хуҗалары Чыңгыз атларының тояк тавышы. Мөстәкыйльлек юк, илебез юк, димичә генә, шагыйрь сине әнә шундый фикерләргә алып килә.

«Төп йорт» шигырендә әлеге гыйбарә белән Р. Әхмәтҗанов Татарстанны, Идел-йортны атый. Туган илдә яшәүнең, ана телендә сөйләшүнең бәхет икәнлеген әйтә.

Р. Әхмәтҗановның бик күп шигырьләре үткәнгә алып китә. «Болгар фрагментлары»н гына алыйк. Аннан бабаларыбыз гомер сөргән җирләрдә хәрабәләр генә калган өчен көчле үкенү хисе саркый.

«Җир астына күмеләме Хаклык?» —

дип сорау куя шагыйрь. Бу үз тарихыбызны ачарга әйдәү дә, аннан гыйбрәт алырга чакыру да булып яңгырый, ә юкса әлеге юлның үзендә бернинди боерыклар, өндәү билгеләре юк.

Кайбер шигырьләрендә шагыйрь милли иҗатчы нинди булырга тиеш соравына җавап бирә, чын иҗатчы гына халык исеменнән сөйләргә хаклы булуны әйтә («...Күпме патроннарны яндырдым мин»). «Тукайны эзлим» әсәрендә милли шигырьдә, халык күңелендә Тукай яшәргә тиешлекне белдерә. «Сәхипҗамал» дастан-поэмасында халык өчен яшәгән сәхнә йолдызына мәдхия укый ул. С. Г. Волжская кебек артисткаларыбызның яшәү рәвешен, әйтерсең лә, бүгенге милли зыялыларга үрнәк итеп куя.

Р. Әхмәтҗанов кыска шигырьләр аз яза. «Киресенчә» дип аталган бер икестрофалыгында ул кайбер татарларга хас милли сукырлык турында сүз алып бара. Ана телен онытканнарның башка милләтләр кубызында биюен, үз халкын да сатуын сөйли шагыйрь.

Минемчә, телне саклау проблемасы Р. Әхмәтҗанов иҗатында беренче урынга чыгарыла.

«Җирдә телсез ил булмый», —

шагыйрьнең «Туган телем» шигырендә әйткән бу сүзләре — бик гадел хакыйкать. Һәм, әлбәттә, үз илеңдә үз телеңдә сөйләшү күркәмрәк.

Р. Әхмәтҗанов күтәргән милли проблемаларны тел, милләт, милли иҗат ирегең саклауга гына калдырсак, милләт яшәешенең билгеләре бик тарайтылыр иде. Ул башка халыклар өстенә төшкән яман чирләрнең татар халкына да килүенә борчыла. Татар кешесеннән дә Иман

качкан көннәр килде дип саный («Чорым — иркен»).

Әйе, без халкыбызга ирек таләп итәбез. Ул ирек динне алмаштыруга хокук, тән азгынлыгы, сихерчеләргә табыну, кайнар нокталарга сугышка китү булып килә. Аптыраган шагыйрь:

Инде, иншалла,
без мөселман бәндәләргә
мәсҗедләр дә бардыр имди, —

дип куя.

Шагыйрьнең «Мәскәү әйтте» әсәрендә халкыбызның, Мәскәү әмеренә буйсынып, күп югалтулар кичерүе хакында сүз бара. Р. Әхмәтҗановның «Итил-су монологы»нда төрки халыкларның тарих дәвамында бүленүе турында сөйләнә. Алдагы шигырьләрдәге фикерне инде син үзең тулыландырасың. Югалтуларыбызның башы әнә кайда икән дисең...

Иншамны күпләргә билгеле «Колшәриф монологы»ннан шагыйрьнең изге теләген чагылдырган юллар китереп тәмамлыйсым килә:

Мадәт бирсен изге гамәлләрдә,
тапсын татар имин үз кыйбласын.

## Сәхнә әдәбиятыбыз турында уйлануларым

Милли драматургиябезнең тарихы бик озын булмаса да, шактый бай. Аның чишмә башында Ф. Халиди, Г. Камал, Г. Исхакый кебек талант ияләре тора. Мине бүгенге сәхнә әсәрләрендә алар кулланган алымнар бармы, традиция буларак үстереләме, пьесаларыбыз, аларның әсәрләре кебек, милли аңны ныгытуга хезмәт итәме кебегрәк сораулар борчый.

Соңгы елларда театрда караган, укыган әсәрләрнең шактые, әгәр ялгышмасам, татар сәхнә сәнгате традицияләрендә шикелле. Дөрес, спектакль һәм пьесаның үзе тудырган тәэсир, фикерләр еш кына бераз аерыла да. Драматургларыбыз вакыйгалардан килеп чыккан идеягә зуррак игътибар бирсәләр, режиссерлар геройлар сөйләмендәге көлкеле гыйбарәләрне ассызыклауны, артистларның көлдерергә тырышып уйнауларын

хуп күрәләр, автор уйлаган мәгънә тәэсирен киметәләр.

Безнең драматургиябез, һичшиксез, милли юлдан барырга, үзенең асыл сыйфатларын үстерергә тиеш. Бу ноктадан караганда, мин Туфан Миңнуллинга тиңнәр бар дип санамыйм. Заман яшьләрен иҗат итсә дә («Илгизәр+Вера»), иҗат зыялылары хакында сүз йөртсә дә («Хушыгыз»), хайваннар тормышы турында язса да («Акбай һәм Сарык малае»), ул, беренче чиратта, милләтебезгә, аның аерым катламнарына хас заман чирләрен читләтеп үтми, милләтне, аның телен, моңын саклау мәсьәләләрен күтәрә.

Т. Миңнуллин геройлары, нинди генә яшьтә булсалар да, тәрбияләре, дөньяга карашлары белән аерылсалар да, хәтта милли йолалардан ваз кичкән кебек булсалар да, аларның тамырларында татар каны ага, гадәтләрендә ата-бабадан күчкән сыйфатлар бетмәгән әле. Олы буын уңай сыйфатларның калкуына, онытыла барганнарының терелүенә булыша, яшьләргә үрнәк булып тора («Миләүшәнең туган көне»ндә).

Т. Миңнуллин Г. Исхакый кебек тетрәндерә («Ай булмаса, йолдыз бар»), Г. Камал кебек, беренче чиратта, геройлар сөйләмен файдаланып, тормышчан көлдерә («Баҗа мал түгел, кәҗә туган түгел»). Аның әсәрләре, М. Фәйзи драмаларындагыча, уен-көлкеле, җырлы («Гөргөри кияүләре»).

Т. Миңнуллин драматургиясе төрле жанрларга һәм жанр формаларына бик бай, шунлыктан ул үзеннән алда аерым жанрларда танылган һәр язучының осталыгын үзләштергән, табигый таланты белән баеткан. Шулай да бигрәк тә аның комедияләрен гасыр башында үткен сатирасы белән безнең яшәешебезнең бөтен серләрен ачып биргән Г. Камалныкына тиңлим мин. Кечкенә генә вакыйгалардан да зур мәгънә чыгара алар икесе дә.

Хет ела, хет көл, дисең, Г. Камал иҗат иткән әсәрләр буенча спектакль караганда. «Беренче театр»дагы аңгырарак күренгән Бибидән, төпкә утыртылган Хәмзә байдан көлгәндә, милләтнең артталыгына күңел сыкранмыймыни? Т. Миңнуллинның бераз алдагырак елларда язылган «Әниләр һәм бәбиләр»е дә бер елата, бер көлдерә бит.

ХХ йөзгә аяк баскач, Г. Исхакый чукындырылган татар хатын-кызын үзәккә куеп, татарның үткәндәге язмышының бөтен фаҗигасен ачкан. XXI йөзне тәмамлаганда, марҗага «кияүгә чыккан» татар егете турында иҗат итеп, Т. Миңнуллин андыйларның бүгенге хатасын һәм шул хата китерәчәк киләчәк фаҗигаләрне бөтен тирәнлеге белән күрсәтте, бер гаилә эчендә туган драманың милләт трагедиясенә әйләнү мөмкинлеген искәртте.

Сөенәм: бүгенге татар сәхнәсен дөньякүләм театрларныкы дәрәҗәсендә тотарлык әсәрләр языла. Көенәм: Т. Миңнуллинны алмаштырырлык яңа буын тәрбияләнми шикелле.

**Бүгенге татар драматургиясе турында уйлануларым**

Татар театрларының игъланнарын карасаң, яңа исемнәр күплегенә хәйран каласың. Ф. Яруллин, Ю. Сафиуллин, Т. Миңнуллин, Р. Хәмид, Р. Мингалим кебек төрле яшьтәге язучыларыбыз янәшәсендә тулы бер буын драматурглар үсеп чыкты.

Зөлфәт Хәким. Безгә «Кишер басуы», «Күрәзәче» кебек трагикомедияләре, «Мин төш күрдем» трагедиясе белән билгеле ул.

Тамашачы Д. Салиховның «Микүләй дәдәйнең бөер ташы», «Бәйрәмгалинең сыер тышавы», «Яшьлек хатам — йөрәк ярам» әсәрләрен яратты.

Р. Зәйдулланы «Саташкан сандугач» әсәре, ниһаять, драматург та итеп танытты.

М. Гыйләҗевне татар укучысы «Казан егетләре», «Бичура» пьесалары аша белә.

Болар — һич кенә дә бер-берсенә охшамаган, язу манераларын кабатламаган драматурглар. Шул ук вакытта алар иҗатын совет гражданнарының черек әхлагын фаш итү үзара якынайта. Данил Салиховның «Микүләй дәдәйнең бөер ташы»нда байлыкка табынган, кыйммәтле таш өчен бер-берсе белән чәйнәшкән, бугазлашкан гарип рухлы адәмнәр тасвирлана.

М. Гыйләҗевнең «Бичура»сында ата-анага, туган нигезгә хөрмәтсез балалар белән очрашабыз. Драматург туган нигезне генә түгел, авылны, гореф-гадәтләрне,

кешенең рухи дөньясын, буыннар арасында бәйләнешне саклау проблемасын күтәрә.

3. Хәкимнең «Кишер басуы» бер системадан икенчесенә күчеш чорында җәмгыятькә хас җитешсезлекләрне күрсәтеп бирә. Кешеләрне уйланырга, башкача яшәү рәвешен сайларга чакыра сыман.

Г. Исхакыйның «Зөләйха»сы, инде узган гасырда язылган булса да, бүгенге драматургиябезгә яңа сулыш өрде сыман. Ул каләм ияләренә иҗтимагый, милли проблемаларны тасвирлаган әсәрләрнең дә, сәнгатьчә эшләнеше камил булганда, тамашачыны театрларыбызга тарта алуын күрсәтте. Шул ук вакытта бүгенге көндә иҗат итүче драматургларыбызның бер генә пьесасының да «Зөләйха» дәрәҗәсендә иҗтимагый яңгыраш алганы юк әле. Ул урыслаштыру сәясәтенең татар халкына, аерым бер шәхескә китергән фаҗигасен бөтен тирәнлеге белән ача. Мин «Зөләйха»ны драматургиябезнең трагедия жанрының киләчәктә ирешергә тиеш биеклеге дип саныйм.

Мине татар әдәбиятында комедия жанрының күләм һәм билгеле бер дәрәҗәдә сыйфат ягыннан да үсүе, аның тематикасы киңәю сөендерсә дә, халкыбызның нигездә шушы жанрга юнәлтелгән ихтыяҗы борчый. Көлке-тамаша артыннан куып, проблемаларны җитди рәвештә күтәрүдән качуыбыз драма һәм трагедия жанрларының берникадәр артта калуына китерер дип куркам.

Татар драма һәм трагедия мирасының күләме, эчтәлеге турында күзаллау да кыенрак, чөнки язылган әсәрләр китап мәйданына чыгарылмый, барысы да сәхнәгә менми. Шулай икән, бүгенге драматургиябез турында ничек итеп объектив фикер йөртәсең?!

## «Остаз»

> Татар авылында туып-үскән гап-гади адәм баласы галәм шагыйре дәрәҗәсендә фикер йөртә, бу бөек, серле, тылсымлы фикерләр гүзәл бер аһәңле хикәяләү барлыкка китерәләр...
>
> *Флера Сафиуллина*

Кулымда — М. Галиев чыгарган күптомлыкларның беренче кисәге. Аның «Гомер шәме» дип аталган кере-

шендә әлеге томлыкка шигырьләр, балладалар тупланганлык хакында әйтелгән.

«Остаз» әсәрен, беренче күз ташлауга, чәчмә төр үрнәге дип фикер йөртәсең һәм ни өчен шигырьләр арасына кертелгән дип аптырап каласың. Укый барган саен, әлеге уйларыңның хата икәнлегенә төшенәсең.

«Остаз»да эчке рифмалар бар икән дигәнсездер инде. Юк, ялгышасыз. Җөмлә, абзац эчендә бернинди рифмаларга да юлыкмадым мин, ә менә һәрбер абзацның шактый охшаш яңгырашлы иҗекләргә тәмамлануына игътибар иттем: керде, көнне, бирде, торды... Шушы эзлеклелектә әсәр ахырына таба барсак, рифманың арттан икенче абзацның уртасында булуына игътибар итәрбез. Ни өчен шагыйрь шулай эшләгән? Алдагы абзацлардагы кебек туры сөйләм аша җиткерелгән уйны яңа юлдан башламаган икән... Күздән ычкындырылган, ахрысы. Соңгы абзацның яңгырашны бозыбрак торган күплек кушымчасын алып атып, ахыргы сүзне «булды» дип калдырсак, рифмаларыбыз тәмам җайга киләр. Шулай итеп, шигырьнең тышкы билгеләренең берсе булу инде бөтенләй шик тудырмас.

Тезмә әсәрнең ритмикасы да бар бит әле. Хәер, Марсель Галиевнең прозаик әсәрләре дә еш кына «җырлап тора». Юкка гына танылган галимә Флера Сафиуллина: «Татар теле соңгы елларда прозабызда бу дәрәҗәдә затлы, нәзакәтле, аһәңле яңгыраган!» — дип язмаган лабаса!

«Остаз»ның образлылыгы бернинди бәхәс уятмаслык. «Кулыннан тотып, шәкертен ул шигъри матурлык иленә алып керде», — дип башлана ул. Әйтерсең, без әлеге шәкерт янәшәсендә үзебез дә серле бер дөньяга, татар әдәбиятында инде күпләргә остаз саналырлык Марсель Галиев тудырган дөньяга атлыйбыз.

Йолдыз тавышы... «Көндезге күктән өзелгән йолдыз тавышы», — ди шагыйрь. Бу мөмкин эш тә түгел кебек, әмма син әлеге йолдызның серле тавышың ишетәсең. Ишетәсең бит?!

Бер караганда, кечкенә генә күләмдәге бу әсәр көнчыгыш притчаларын, хикмәтләрен хәтерләтә. Мәгънәсенә тирән үтмәсәң, аның бүгенге белән бәйләнешен аңла-

мыйсың да. Вакыйга ерак бер тарихи чорда барадыр шикелле. Остазның кулъязмаларын учакка ташлаганда әйткән сүзләре сине үткән гасырлардан бүгенгегә күчерә:

«Яшьлек гөнаһлары. Мин алардан ваз кичәм. Син гаҗәпләнмә, заманы шундый иде».

Репрессия елларының корбанымы бу остаз? Яшьлегендә хаталанганны әллә яңа гына аңлаган бер җанмы? Әгәр алай түгел икән... остаз булырлыкмы ул шәкерткә?

Ул юлларга тулы бер буын, ил, милләт, халык, аерым бер шәхес трагедиясе салынган. Остазның иҗатын һич икеләнүләрсез сызып ташлавы укучы күңелендә аның иҗатына бәядә, аның үзенә мөнәсәбәтендә икеләнүләр тудырырга тиешле. Антитезаның икенче ягы бу...

Яшьлеккә хаталану хас дибез. Мәхәббәттә, хисләрдә алдану гына булса икән ул... «Учакта бөгәрләнеп янган кәгазьләр, кара бармакларга охшап, кемгәдер янаган кебек булдылар», — «Остаз»ның соңгы юллары яшь кешенең дә иманы нык булырга тиешлекне искәртә.

Бу әсәр, көнчыгышның гыйбрәтле хикәятләренә, шигъри хикмәтләренә тартым булса да, анда бернинди вәгазь, акыл сату күзәтелми.

«Төнлә атылган йолдызны һәркем күрә ала, ә менә син көндезге күктән өзелгән йолдыз тавышын ишетергә өйрән», — диярга яраткан остаз, шигъри матурлыкны тоярга өйрәткән остаз... Син әле гаделлек җырчысы да булырга тиеш икәнсең. Син урман эчләрендә кошлар тавышын тыңлап хозурланганда, айлы кичләрдә шигырьләр язганда, кемнәрдер ямьсез көндәлекнең корбаннары булган. М. Галиевнең бу әсәре миңа әнә шуны аңлатты. Иң татлы сүзләр белән иң ачы хакыйкатьне ачты ул.

## «Үлемнәре белән үлемсезлек яулап ала безнең шагыйрьләр» (I)

*(Р. Фәйзуллин)*

Шигъри сүзне, образлы сүзне үз иткән, дөньяга яңгыраткан өчен генә дә дәһрилектә гаепләнеп, үлем җәзасына хөкем ителгәннәр булган. Халыкка мәгърифәт таратып йөргәндә, вәхшиләр кулыннан гомере киселгән Акмуллабыз бар. Иленә хезмәт итеп тә бәяләнмәвеннән

йөрәгенә кан сауган яисә тугры сүзе өчен концлагерьларда гомер сызыгын үтеп чыкканнарның санын кем исәпләгән дә, бөтен көчен милли бәйсезлек көрәшенә биреп, саулыгын югалтканнан соң, үлем түшәгенә егылганнарның хисабын кем алган?!

Бөек Ватан сугышы шагыйрь һәм әдипләребезне зур сынау алдына куйган. «Ирек сөюең хакында иҗатыңда яңгыраган сүзләрне кулыңа корал алып расларлыкмы син, язганың — ихлас, әйткәннәрең чын йөрәктән идеме?» — дигән ул.

Сугышның беренче көннәреннән үк үз халкы белән Ватан бәйсезлеген яклап көрәшкә күтәрелгән татар шагыйре. М. Җәлил, К. Нәҗми һәм башкалар, изге сугышка әйдәп, «Ватан өчен» исемле җыентык бастырып чыгарганнар, халык арасында агитация эшенә керешкәннәр. Аларның шушы юнәлештәге эшләре генә дә халык рухын күтәргән, аны уртак идея-максатлар белән коралландырган булыр иде, әмма чын кеше, Ватанына авырлык килгәндә, тылдагы изге гамәлләре, башкалар артына яшеренәмени: татар шагыйрьләре дә бер-бер артлы сугышка китеп барган. Барган һәм кире кайтмаган...

Сугыш елларында Ватаныбыз өчен гомерләрен биргән шагыйрьләр арасында Ф. Кәрим, М. Җәлил, Г. Кутуй, Н. Баян кебек искиткеч талантлы каләм ияләребез бар. Аларның сугыш чорларында иҗат иткән ялкынлы шигырьләре бөек җиңүгә хезмәт иткән, шул җиңү килгәннән соң, кабат илне төзешкән. Халык өчен бирелгән гомерне үлем дип атап буламы соң?!

### «Үлемнәре белән үлемсезлек яулап ала безнең шагыйрьләр» (II)

*(Р. Фәйзуллин)*

Бөек Ватан сугышы поэзиясенә патриотик хисләр, романтик дәртлелек хас иде. Сугыш заманы нинди генә авыр булуга карамастан, шагыйрьләр язуыннан туктамады, шигъри сүзне тагын да куәтлерәк яңгыратты.

Бу чор әдәбиятының үзәгендә Ватан язмышы өчен гомерен дә кызганмаучы совет солдаты, җиңү көнен якынлаштыру өчен, соңгы көченә кадәр тырышкан тыл хезмәтчәне булды.

Ф. Кәримнең:

Үзең турында уйлама,
Илең турында уйла.
Илең турында уйласаң,
Гомерең озын була», —

дигән гыйбрәтле сүзләре меңнәрнең, миллионнарның йөрәгенә барып җитте.

Һәр иҗатчы Ватан өчен гомереңне бирүне изге бер эш итеп күрсәтеп калырга тырышты. Алар язганнар шагыйрьләрнең үзләрен дә туган халкы хакына олы көрәшләргә әйдәде, рухларын ныгытты булса кирәк. Бу чор шигырьләрендә Яшәү һәм Үлем янәшә йөрде, әмма совет кешесенең үлемнән куркуын тасвирлау юк дәрәҗәсендә иде. Җир шарын фашизм коллыгыннан коткарганда үлүне кеше исемен мәңгеләштерүче адым дип күрсәтү ешайды.

Шигъриятьтә ант, саубуллашу мотивлары киң таралды. Алар үзара үрелеп тә килделәр. Еш кына сугышка китеп баручы шагыйрь корал һәм җыр белән көрәшергә ант итте. Шулай итеп, М. Җәлил, Ф. Кәрим иҗатларында көрәшче җыр образы туды. Ул сугыш кырларының байрагы төсен алды.

М. Җәлил «Ышанма» шигырендә әле сугыш бетәргә бик озак бер чакта түбәндәге юлларны язды:

Туфрак күмәр тәнне, күмә алмас
Ялкынлы җыр тулы күңелне.
«Үлем» диеп әйтеп буламы соң
Җиңеп үлгән мондый үлемне?

Бу шигырьдә җиңүнең килү-килмәве турында сүз дә юк. Әйтерсең, шагыйрь өчен ул бәхәс уятмый. Һәм шул ук вакытта иҗатының киләчәктәге үлемсезлеге дә шик тудырмый шикелле.

Шагыйрьләр башкаларга үрнәк булырлык гомер яшәп калырга омтылды. Алар өчен киләчәк буыннарның бәясе бик мөһим иде:

Чикләнсә дә гомер, яшьлек безнең
Эзсез сүнә, диеп уйлама!
Әйтсен яшьләр: менә шулай яшәп,
Шулай үлсәң иде дөньяда!

148

## «Үлемнәре белән үлемсезлек яулап ала безнең шагыйрьләр» (III)

*(Р. Фәйзуллин)*

Ф. Кәрим — әдәбиятыбызның горурлыгы. Аның соңгы иҗат чоры Ватан сугышы белән башлана һәм тәмамлана. Ул шул елларда үзенә үлемсезлек алып килгән шигырьләр иҗат итә һәм үзенең ялкынлы сүзе белән халык йөрәгенә үтә.

Шагыйрьнең әле 1942 елда язган «Кереш җыр»ында көндезен иптәшләре белән бергә утка-суга кергән, төннәрен иҗат шатлыгы кичереп яшәгән шагыйрь образы үзәктә тора. Ул окопларда язган шигырьләре дусларында хөрмәт хисе уятыр дип өметләнә.

Ф. Кәримнең теләкләре бер юнәлештә үсә. Аңа шигыренең кешеләр тарафыннан укылуы, үзенең искә алынуы, исеменең җыр булып калуы кирәк:

Дошманга ялкын сибүче
Җил булып барсам иде,
Тәвәккәллек, батырлыкта
Җыр булып калсам иде.
*(«Теләк», 1942)*

Дөрес, шагыйрь исән-имин илгә кайтасына да өметләнә:

Тагын барам, мин сугышка барам,
Паровозның моңсу тавышы:
— Кайтырсың! — ди; димәк, алда әле
Көтә мине тагын кавышу.
*( «Юл», 1942)*

Бу кайту, дошман җиңелмәсә, булмаска да мөмкин, шуңа күрә бөтен көчне көрәшкә тупларга кирәк.

Ф. Кәримнең «Мин — гуманист» (1942) шигырендә нәкъ менә фашистларны күбрәк кырган кешенең Туган илендә макталуы, данының җырга күчеп кабатлануы хакында фикер бар.

Шул ук елны язган «Исә җил»дә Туган ил өчен яну идеясе ассызыкланган, тыл һәм фронт берлеге концепциясе дә чагылып үтә.

«Умырзая»ның (1943) лирик мине хатын-кыз булып тоемлана. Ул шагыйрьгә «туган илнең туфрагында

үскән умырзая чәчәген» салган, шуның белән аны шатландырырга тели. Кыз үзе дә аннан өмет яңартучы җырлар көтә.

Шагыйрь җыр белән көрәшү китергән бәхет хакында гына язмый, чөнки лирик герое һәрвакыт каләм тоткан шагыйрь генә түгел. Аныңча, гади солдат өчен дә көрәшнең якты шатлыклары хас. Гади солдат та үлеме белән совет кешесенең героизмын раслый, үз исемен мәңгеләштерә. Ф. Кәрим әнә шуңа күрә аның күңелендә дә өмет чаткыларын кабызырга, булганнарын көчәйтергә теләп иҗат итә, оптимистик рухлы совет кешесенең калку образын тудыра:

Корал тотып, халык бәхете өчен
Көрәшүнең якты шатлыгын
Бөтен көче белән татый күңел,
Бизи аны кояш аклыгы.

*(«Өмет йолдызы», 1944)*

ӘДӘБИЯТ

## М. Җәлилнең «Юллар» шигыре

Кыска гына вакытны үз эченә алган Бөек Ватан сугышы еллары М. Җәлил иҗатында аерым бер этап дип бәяләнә. Шагыйрь көрәш елларында халык күрсәткән героик рухны чагылдырып иҗат итә. Туган илгә соңлап булса да кайтып ирешкән «Моабит дәфтәрләре» — М. Җәлилнең сугыш чоры шигъриятенең йөзек кашы.

1943 елда язылган «Юллар» — инде зур фаҗигаләр кичергән талант иясенең каләменнән төшкән шигырь. Ул анда кеше тормышында кайгы һәм шатлыкларның бергә үрелеп килүен күрсәтә.

«Юллар, юллар!» дип кабатланган эндәш шигырьне ике кисәккә бүлә. Беренче кисәк туган илдән аеручы юллар мотивына нигезләнә, саубуллашу күренешләрен тасвирлый. Лирик мин сөеклесе, туган җире белән аерылышкан көннәрен искә ала, ике вакыт үзара якынайгандай була, шул ук вакытта юл образы аларның ераклыгына да ишарәләп тора.

Без шигырьнең сугыш елларында язылуын беләбез, әмма анда көрәшкә, тоткынлыкка бәйле детальләр юк.

Минемчә, шагыйрь биографиясеннән хәбәрсез кешеләр шигырь, гомумән, тыныч шартларда язылган, бер ир кайчандыр авылыннан шәһәргә чыгып китү вакытларын исенә төшерә дип уйлар иде. Андыйлар асмәгънәле «озак кунак булдым» дигән юлларны да үзенчәрәк аңлар иде. Шигырьнең гомумирәк планда язылуы аның киләчәк укучылар тарафыннан укылышлы булуына китерә.

Шагыйрь еракта калган туган ягын нинди предметлар аркылы исендә саклый соң? Әлбәттә, ул үзе китеп барганда караш ташлаган әйберләрен беркайчан да онытмаячак. Бу — таныш кырлар, урман. Авылга алып килүче күпер башы, аның янында басып торган нечкә билле кыз. Без аның тышкы кыяфәтен шагыйрь тудырган детальләр аша күзаллыйбыз: кара каш, боек чырай, яшьле керфекләр, назлы караш...

Лирик миндә сөю һәм ихтыяр көче бергә нык үрелгән, шуңа күрә генә ул саубуллашу вакытларын кичерә ала:

Читен дә соң читкә киткән чакта,
Ярты җаның калса өзелеп!
Ярый әле, сөю белән бергә
Бар йөрәктә корыч түземлек.

Хис-кичерешләр үзәккә куелган әсәрдә ничек инде җан, йөрәк кебек образларны кулланмыйсың?! М. Җәлил дә шулай эшли.

Шагыйрь юлларга каты гаепләү ташлый, әйтерсең, ул аларны үзе сайлап алмаган. Бу — әлбәттә, образлы фикерләү генә. Юлларга аяусызлык, катылык эпитетлары тагыла.

Шигырьнең икенче кисәгендә шагыйрь тормыш юллары хакында фәлсәфи уйларга бирелә. Кемнәр, кайдан башлап салган аларны? Кешелек, милләт, аерым кеше узган тарих турында уйландыра ул. Юл образына салынган мәгънә киңәеп киткәндәй була.

Лирик мин хәзер атлаган юллар — яшьлек юллары, шуңа күрә дә йөгерек, дәртле, өмет уятучан алар.

Сезне, юллар, аяк эзе түгел,
Йөрәк хисе салган бу җиргә, —

дип яза М. Җәлил. Әлбәттә, лирик мин атлаган юл күрше авыл кибетенә генә илтми, ул юлларга аны йөрәк

дәрте әйдәгән. Кемдер — яңаны төзү омтылышы белән, кемдер — белем алу, кемдер — илне фашистлардан азат итү өчен, авылдан алып китүче тузанлы олы юллардан атлаган.

Юллар аерып кына калмый, кавыштыра да. Хәтердә эзе булган сукмаклар да туган якларга илтергә сәләтле. Шагыйрь кырлар аша салынган реаль юлларның кайчан да бер сөеклесе яшәгән якларга алып чыгасына аеруча ышана.

Юллар, Юллар! Мине, илкәемнән
Аерып, ерак алып киттегез.
Яңа дәртләр, яңа хисләр белән
Сөйгәнемә кире илтегез, —

дигән үтенеч белән тәмамлый ул шигырен, юлларны үзен аңлаучы тере җан итеп күргәндәй.

### Г. Әпсәләмов иҗатында батырлык темасы

Г. Әпсәләмов татар әдәбиятында «Мәңгелек кеше», «Сүнмәс утлар», «Газинур» кебек зур күләмле әсәрләре белән урын алды. Аерым бер тарихи чорларны бөтен катлаулылыгы белән тудыру иҗатчыдан — зур осталык, аны укучы игътибарына, аның кырыс хөкеменә тәкъдим итү кыюлык сорый.

Бу иншаны язу өчен, мин бик озак хәзерләндем. Китапханәләргә барып, материал тупладым, аларда әйтелгән фикерләрне үзара чагыштырдым, һәм үзем дә аерым бер нәтиҗәләргә килдем, шулай да аны башкалар фикереннән формалаштырырга тырыштым.

Г. Әпсәләмов — кеше батырлыгын калку итеп сурәтләүне алга куйган язучы. Әдәби тәнкыйть тә, беренче чиратта, әнә шуңа игътибар иткән икән. Вакытлы матбугатта басылып чыккан мәкалә исемнәре дә әнә шул хакта сөйли. Фәрит Хатипов үз язмасын — «Ил батыры турында роман» (Совет Татарстаны, 1954), Газиз Иделле — «Онытылмаслык батырлык» (Совет әдәбияты, 1952) дип атаса, Гази Кашшаф «Безнең заман геройлары» (Совет әдәбияты, 1950) дип исемли.

Югарыда телгә алынган мәкалә атамалары Г. Әпсәләмовның кайсы да булса батырлыкны мәңгеләштерергә теләвен дә күрсәтә булса кирәк.

Мин әдәби тәнкыйтьтә без сыйныфта укыган әсәрләр хакында әйтелгән фикерләргә аеруча игътибар иттем. Г. Мөхәммәдова, И. Ахунҗанов, Гази Кашшафлар «Алтын йолдыз» романында батырлык темасының үзәккә куелуын билгелиләр. Г. Кашшаф аның төп образларының «илебезнең йөзен тамырыннан үзгәрткән гаять зур үзгәрешләр нәтиҗәсендә безнең заман геройлары булып тәрбияләнгән батырлар» булуын әйтә.

Мине танылган язучы А. Гыйләҗевнең без укыган романнарга гына түгел, гомумән, Г. Әпсәләмов иҗатына тискәре бәяләмәсе гаҗәпкә калдырды («Имән чикләвеге»// Шәһри Казан, 1990). Ул аның әсәрләре тормышчанлыктан ерак тора дип исәпли. Ә бит, бер уйлаганда, шулай фикер йөртүнең реаль җирлеге бар. Совет чорында язылган әсәрләрдә тормышны бөтен тулылыгы белән, начар, җитешсез якларын да тирән ачып, бигрәк тә хөкүмәт һәм партиягә тел-теш тидереп язу мөмкин бер эш түгел иде. Тоталитар система шартларында иҗат иткән һәр язучы нindидер күләмдә тормыш дөреслегенә хилафлык китергәндер.

Бу уңайдан соңгы еллар тәнкыйтенең иң кызыклы мәкаләләреннән булган, танылган әдәбият белгече С. Хафизов язган «Әдәбиятта базар заманы»ннан (Казан утлары, 1998) бер өзек китереп узасы килә: «Татар язучыларын ... бәяләүдә анык заман, шартлар, язучы активлыгы күздә тотылырга тиеш. Г. Әпсәләмов зур иҗатка аяк баскан, сугыш беткән елларда сталинизмның хөр фикергә яңа һөҗүм дулкыны башлану белән бергә, татар халкы, аның мәдәнияте һәм әдәбиятына өстәмә каршылыклар тудырыла /.../

Мондый чакта татарны ничек сурәтләргә мөмкин? Әлбәттә, батыр итеп, матур итеп һәм уртак Ватанга тугрылыклы итеп кенә... Һәм Г. Әпсәләмовның үз халкының соклангыч, хәтта героик улларын, кызларын сурәтләгән романнары бер-бер артлы дөнья күрә башлый...»

Гариф ага Ахунов та шулайрак фикер йөртә: «Габдрахман абый татар халкының ике сыйфатын — хезмәт ратуын һәм батырларча сугыша белүен «Сүнмәс утлар», «Алтын йолдыз», «Газинур», «Мәңгелек кеше» романнарында ... калку итеп чагылдыра... Аның ро-

ман һәм повестьларында яшьлек сулышы, романтик пафос бөркелеп торыр. Тормыш авырлыкларыннан, үлемнәрдән, фаҗигаләрдән гарык булган халыкка — укучыларга нәкъ менә шул кирәк иде» (М. Гәрәев белән әңгәмә. «Әпсәләмов ун ел татар халкын татар теле янында тотып торды»// Шәһри Казан, 1977).

Кыскасы, тәнкыйтьчеләр, әдипләр, язмаларында Г. Әпсәләмовка хас җитешсезлекләрне күрсәткәндә дә, аның татар кешесе батырлыгына дан җырлавын таныйлар. Шуның өчен рәхмәт әйтәләр. Әйе, Г. Әпсәләмовның «Алтын йолдыз», «Газинур» кебек романнары — кеше батырлыгына һәйкәл ул.

## Кеше китә — җыры кала

*(Мөхәммәт Мәһдиев иҗаты буенча)*

Татар әдәбияты тарихыннан мәңге җуелмас исемнәр һәм әсәрләр бар. Мин аларга М. Мәһдиевне һәм аның үз авылы кешеләрен чиксез ярату белән тасвирлаган «Кеше китә — җыры кала», «Торналар төшкән җирдә» әсәрләрен кертер идем. Беренче повестьта сурәтләнгән вакыйгалар Кара Чыршы исемле гадәти бер авылда бара. Табигатьнең матур җиренә урнашкан татар авылының кешеләре дә искиткеч матур. Ил кичергән ачы язмыш та начарлатмый, үзгәртми аларны.

«Кеше китә — җыры кала»ның каһарманнары бик тормышчан, моңа аларның гадәти җирлектә, гаиләэчендә, үзара мөнәсәбәтләрдә ачылуы булышлык иткән.

Сугыш чоры авылы да кайгы-хәсрәттә генә, күңелсезлек көтеп кенә яшәми, ди автор. Бу яшәешнең эчке матурлыгы бар. Иген үстерә, бала тәрбияли, үз телендә җырлый, шатлыгын бүлешә, хәсрәтен тарата ул.

Сугыш авырлыклары кешеләрне үзара бик нык якынайткан да, кемнәрнедер авыл кешеләреннән ерагайткан да. Берәү, Җиңү көнен якынайту өчен, сәламәтлеген бирергә әзер булган елларда үлемнән башкалар артына качып калырга тырышучылар да юк түгел. Үлем каршысында бар кеше — бертигез. Язучы шулай ди һәм очрашырга теләсәң дә, әҗәлнең барыбер куып тотачагы хакында искәртә.

Кеше китә — җыры кала. Күпчелек авыл кешеләре хакында якты җырлар — якты уйлар кала.

«Торналар төшкән җирдә» алдагы әсәргә бик нык береккән. Анда да язучы гадәти бер татар авылында туып-үскән кешеләр хакында сөйли. Зур сулар, иркен болыннар, биек таулар белән уратылмаган Казан арты авылы ул. Повесть һәрберсе үзәгенә бер кеше язмышы куелган аерым-аерым новеллалардан тора. Новеллалар үзәгенә Симет, Масра, Казиле ... авылларында туып-үскән киленнәр, ир-егетләр куелган. Алар — авылның әхлагын, гореф-гадәтләрен саклаучылар. Бүген матур йолалар, әхлак нормалары югала, бозыла, чөнки аның ияләре бер-бер артлы якты дөнья белән хушлаша...

Кеше китә — җыры кала. Авылдашларын һәрберсе хакында язучы күңелендә туган сагышлы җыр да ул, шул ук сагыш белән өртелгән көлке вакыйгалар да...

Элекке яктылык урынына үкенеч кенә калды, ди язучы. Үзе яңа заманда күргән вакыйгалардан элеккенең кайтавазларын эзләү белән мавыга. Тагын үкенеч хисләре көчәя, чөнки модалар, гадәтләр яңарышында узган заманнар кайткан кебек булса да, аларның эчтәлеге башка, чөнки бүгенге кешеләрнең табынганнары, изгеләштергәннәре башка.

Кешенең аулаграк җиргә төшкән торналар белән хозурланырга вакыты юк. Булса да, ул аннан тәм тапмый. Һөнәрле Казан арты гына түгел, татар халкы, татар иле әкренләп үзенең матур сыйфатларын югалта бара.

Аның җырлары, уеннары онытыла. Уен җырлары тарих сәхнәсеннән төшкәнгә уфтана язучы. Әллә кешедән җыр да калмасмы? Әдип шуңа күрә үз күңелендә сакланганнарын мәңгеләштерергә ашыгамы?

М. Мәһдиев басу өстендә туган җире белән хушлаша. Әйтерсең, соңгы торна алар авылыннан кайтмаска очып китә. Ул басу түре, шигърият чыганагы булып, аның күңеленә, безнең хәтеребезгә уела.

## Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр»ендә реаль һәм шартлы образларның үзара мөнәсәбәте

Т. Миңнуллин татар драматургиясе тарихында шартлылык һәм реальлекне, әсәр тормышчанлыгына зыян китермичә, оста үрүче сирәк художникларның берсе сыйфатында кереп калыр төсле тоела. Иҗади уйлан-

малылыкны тормышка нигезләү аның шартлы образларын да реаль персонажлардай кабул итүебезгә булыша.

«Әлдермештән Әлмәндәр» комедиясендә символик образлар бирәү генә түгел, шуңа да карамастан алар әсәрнең эчке тукымасына зыян салмый, реаль вакыйгалардан чыккан фәлсәфи фикерне тирәнәйтәләр, конфликт тудыруда катнашалар.

Әгәр пьесаның конфликты мификмы, диниме затлар белән кешеләр арасында барса, аның көлке ягы басып китәр, тәэсире кимер, һәм ул тормышчан булудан бигрәк, фантастик жанрда язылган бер әсәргә әйләнеп калыр иде. Әҗәл һәм Әлмәндәр тарткалашулары — минемчә, ул тирәндә яткан конфликтны, кеше күңелендәге эчке конфликтны ачуның бер юлы гына. Бу шул ук вакытта — гасырлар дәвамында яшәгән Үлем һәм Яшәү арасындагы бәхәс. Әлеге ноктадан караганда, Әҗәл Үлем ягын белдерсә, Әлмәндәр Яшәүне аңлата шикелле. Икенче яктан, Әҗәл үзе дә — Әлмәндәр күңелендә бәхәсләшкән ике теләкнең, фикернең берсе. Менә ни өчен безгә кайбер вакытта Әлмәндәр образы Әҗәл белән керешеп китә кебек!

Кеше күңелендә туган фикерләрне персонажлаштыру алымы татар әдәбиятында Г. Коләхмәтовтан ук килә. «Ике фикер» драмасыннан башланган традицияләрне Т. Миңнуллин бу әсәрендә бик уңышлы дәвам итә. Хәтерләсәгез, соңыннан аның да үзәк герое яшәү мәгънәсен аңлаткан уңай фикер белән килешә.

Пьесада үлем төшенчәсен гәүдәләндерүче персонажлар берничә, әмма Әҗәл — шуларның үзәгендә. Тормышта да әҗәл сүзе еш кына үлем мәгънәсенә тиңләштерелә, аның урынына кулланыла бит.

Мәңгелектән килгәннәр барысы да билгеле бер дәрәҗәдә аерым тип кешеләргә охшаган, тәкәбберлеккә дә, мәрхәмәткә дә, кушканны үтәүчәнлеккә дә, ялагайлануга, астыртынлыкка да ия алар. Без әле әнә шул сәбәпле дә мифик затларны реаль геройлар кебек кабул итәбез. Хәер, ничек охшамасыннар ди: Атабыз Адәм үзе дә күктән куылган лабаса! Дини мифологиябезгә дә күкнең, җирнең һәр заты үз сыйфаты, үз шөгыле белән кергән. Т. Миңнуллин, вакыт-вакыт аерым бер персо-

нажлардагы тискәре сыйфатларны калкуландырып, кешеләрдән көлү өчен файдаланган.

Драматург тудырган җир кешеләре алайса нәрсә белән үзенчәлекле, күктән безне күзәткәннәрдән нәрсә белән аерыла? Әлбәттә, яшәү теләге, үлемнән артык курыкмау, көчле рух. Ни өчен? Күк затларының сыйфатлары алдан билгеләнгән. Аларга Җирдә яшәү өчен аерым бер гомер бирелмәгән. Әҗәл дә, фәрештәләр дә үлемгә хәзерләнми, шул вакыйга белән сыналмый. Ул үлем аларны куркыта да алмый, чөнки болай да Аллаһе Тәгалә каршында кылган һәр гамәлләре өчен шул вакытта ук җавап тоталар. Димәк, аларга инде куркуның башкачарак хисе хас булырга тиеш.

Кешеләрдәге яшәү теләгенә Әҗәл булып Әҗәл таң кала. Ни кызганыч: мондый сыйфатлар теләсә кемгә бирелми. Ул, беренчедән, кешенең табигатенә салынган була, икенчедән, авыр сынаулар аша ныгытыла. Бер караганда, рухи гомере мәңгеләшкән кеше Әҗәлнең үзенә дә охшый төшә.

Адәм гомерен кисү уе белән күктән төшкән затны икенче хыяллар били: аның кешеләрчә яшәп карыйсы, алар кичергән хисләрне кичерәсе килә башлый. Язмышны әҗәл дә үзгәртә алмый! Аның да яшәү мәгънәсе алдан һәм башкача билгеләнгән. Ул кешеләрдәге иң бәһале сыйфатны һәм аның үзен дә үтерергә тиешле. Бу — Әҗәлнең драмасы. Бу бит — яшәргә теләп тә үлемгә хөкем ителгән Әлмәндәр картның да драмасы.

Пьесада реаль һәм шартлы образларның үзара мөнәсәбәте гаять җентекле эшләнгән. Әйдәгез, Әлмәндәр карт белән Әҗәлне чагыштырыйк. Алар бер-берсенә охшаган да, охшамаган да. Икесе дә озын гомерле, тик татар картыныкы — чагыштырмача гына. Ул барыбер үләчәк, Әҗәл исә бер генә төрле мәңгелек гомер кичерәчәк. Икесе дә кылган һәм кылмаган эшләре өчен — Бөек көч каршысында җаваплылар.

Әҗәл бер үк вазифаларны башкарудан туя, ул гөнаһлы яшәүнең дә үз кызыгын таба, хәтта аның өчен җавап бирергә дә хәзер кебек. Ә андый гөнаһларны эзләп, ерак барасы юк... Шартлы символлар аркылы автор реаль күренешләрне тәнкыйтьләргә алына: тормышыбызда киң таралган эчкечелек, байлыкка сатылучанлык, рухи

ярлылыктан комедиячел рәвештә көлә. Моңа зур батырлык кирәк. Без илаһилаштырган дөнья аркылы бүгенге көн күренешләрен күрсәтү — гадәтилектән читкә чыгу ул.

Әгәр әсәрнең теле шаян булмаса, көлкеле хәлләр кулланылмаса, ул фаҗигагә әйләнер иде. Шул ук вакытта ярымкомедиячел фонда яшәү һәм үлем турында фәлсәфә болай да фаҗига тәэсире ясый.

Җор телле, халыкчан юморга ия Әлмәндәрнең үлемгә дә мөнәсәбәте милли, дини этика таләп иткәнчә. Татар карты үлемнең котылгысызлыгын белгәнгә, үкенерлек итеп яшәми.

Улына караганда да сәламәтрәк, рухи таза Әлмәндәрнең үлемен кабул итү авыр, әмма ул үзе, гадел яшәгәнгә, кешеләр һәм ил өчен файдалы эшләр эшләгәнгә генә бу дөнья белән җиңелрәк саубуллаша.

Комедиядә проблеманы җитди иткән нәрсәләрнең берсе — нәкъ менә мәҗбүрият һәм теләк-омтылышларның үзара каршылыкка керүе, картның аңлы рәвештә торабара үз язмышына буйсынуы. Әйтерсең, ул үлем алдыннан да һич югы Әҗәл белән шаярмыйча кала алмаган. Бу аның холык сыйфатларыннан эзлекле килеп чыга.

Без, Әлмәндәр карт — үлемсез, дибез икән, монда сүз аның рухи үлемсезлеге, эшләгән эшләренең мәңгелеге турында бара. Физик үлем алып килгән Әҗәлдән ул әнә шул сыйфатлары белән өстен. Т. Миңнуллин, үлемсезлекнең үлемнән дә көчлерәк булуын раслар өчен, шуны гәүдәләндергән дини образ Әҗәл белән йөзьяшәр Әлмәндәр картны очраштыра.

## Татар әдәбиятында җитәкче образы

*(Гариф Ахунов иҗаты буенча)*

Г. Ахунов исемен белмәгән, аның әсәрләрен укымаган кеше татар укучысы арасында юктыр. Аның иҗаты хакында мәкаләләр үзе исән чагында һәрдаим республика матбугатында дөнья күргән. Төрле язмалары, иҗаты аркылы ул безнең күз алдыбызга актуаль проблемалар күтәреп чыккан, яңа темаларны тасвирларга алынган язучы буларак килеп баса.

Г. Ахуновның «Гомер юлы» китабы — үзгәрешләргә таба атлаганда дөнья күргән тәүге җыентыгы. Анда

үзәккә хезмәт кешесе, җитәкче образы куелган. Ул татар әдәбиятының һәрвакыт игътибар үзәгендә булган авыл тормышын яктырта, аның тирәнгә яшерелгән яисә һәркемгә ачык күренеп торган актуаль проблемаларын күтәрә.

Яңа тип җитәкчеләрне хәзерләү Совет иле яшәгән һәр чорда хөкүмәтебез тарафыннан хәл ителәсе мәсьәлә булып килде. Ул бүген дә шулай. Иҗтимагый хәлләрнең һәрвакыт үзәгендә кайнаган Гариф Ахунов аны читләп үтә алмый иде. Иҗатының теләсә кайсы чорын күздән кичерсәк тә, без үзәккә җитәкче образлар куйган әсәрләрнең барлыгын күрербез.

«Гомер юлы» романында җитәкчеләрнең төрле урыннардагысы, төрле типтагысы тасвирланган, без аларга аерым-аерым тукталмабыз, әмма шулар аркылы Г. Ахунов идеалда күзаллаган җитәкче образының гомуми сурәтен тудырырбыз.

Илне алга илтәчәк бүгенге көн җитәкчесе бик күп уңай сыйфатларны бергә туплаган, акыллы, сәләтле, сабыр зат булырга тиеш — язучының төп фикере әнә шундый. Әлеге җитәкче үз алдына башкалар турында кайгырту максатын куя. Аерым бер кешенең матди, рухи тормышы баемый торып, кечкенә генә колхозның, районның, илнең икътисады алга китмәячәген аңлый.

«Гомер юлы»нда автор, колхоз рәисе узган тормыш юлын сурәтләп, аның белән бергә халык кичергәннәрне дә тасвирлый, чөнки аларның иңгә-иң яшәвен, авырлыкларны бергә җиңүен белә.

Колхоз җитәкчесе — игенче дә, терлекче дә, төзүче дә ул. Үзең белмәгән өлкәдә җитәкчелек итү мөмкин түгел. Беренчедән, рәис шул тармакларны алга җибәрергә, икенчедән, анда хезмәт итүчеләрнең тормышын яхшыртырга тиеш.

Г. Ахунов бу әсәрендә дә үзенең иҗат принципларына тугры калган:

— үзәккә уңай җитәкче образын куйган, аны калку тасвирлаган;

— тискәре геройлар арасында да җитәкче образлар бар;

— төп образлар кешеләр һәм үзләре кылган гамәлләрне анализларга, бәяләргә ярата;

— җитәкчеләрнең гаилә эчендәге мөнәсәбәтләренә зур

урын бирә, бер җитәкченең гаиләсен уртага чыгара;

— җитәкчеләрне гаилә, мәхәббәт, эштәге элемтәләр үзара бәйли.

«Гомер юлы»ның уңай герое — татар әдәбиятының җитәкче образын алгы планга чыгарган кайбер әсәрләрендәге образлардан аермалы буларак, алдынгы социалистик җәмгыять төзүче, гади хезмәткә дә турыдан-туры көч куючы, аны кабул итмәүчеләр белән бугазга-бугаз көрәшүче түгел. Ул — социалистик система кысаларында да авылдашларын яхшы яшәтергә омтылучы бер фидакарь. Кыскасы, җитәкче образлар аркылы автор тоталитар системада да ирекле хезмәт, хезмәттә шәхси үрнәк яшәргә тиеш дигән фикерне уздыра. Кадрлар тәрбияләү, авылны яшәтү, яшәртү, башка мәсьәләләр әнә шундыйларның үз кулына тапшырылса, хөр фикер, алдынгы идеяләр булса, авыл хезмәтчәннәренең киләчәге өметле.

Бу әсәрдә авылны, крестьянны саклап калу проблемасы колхоз аша хәл ителә, ул аңа чын хуҗа булмау аркасында да туган кебек күрсәтелә. Җитәкче крестьянның буыннан-буынга килгән хезмәт сөючәнлеген колхозны яшәтү, илне, аерым бер хуҗалыкның матди тормышын баету максатларында файдаланса иде, дип әйтә шикелле Г. Ахунов. Таза һәм нык әхлаклы крестьян гаиләсе колхозның бер күзәнәген тәшкил итәргә, колхоз җитәкчесенең гаиләсе исә шуның бер моделе, үрнәге булырга тиеш. Бу — язучы уздырган үзенчәлекле фикерләрнең чираттагысы.

Г. Ахунов, үзгәртеп коруның башлангыч чорында авыл хуҗалыгы йөген тартучы, төрле биеклекләрдәге кәнәфиләрдә утыручы башлыкларның эшләү, яшәү принципларын өйрәнеп, аңа җавап таба һәм «Гомер юлы» романын иҗат итә.

### «Дала буйлап кылганнар йөгерә...»

*(Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәрендә дала күренеше башкарган вазифа)*

Башкорт даласында уйнап үскән, яшьлегендә аның кылганнарын җыйган, картлыгында да һавасыннан рәхәтләнгән карчык үлем түшәгенә ята. Бер гомер ахы-

рына килеп җиткән, ә вакыт дәвам итә, далада үскән кылганнар да йөгерүеннән туктап калмаган.

Акъәби язмышына, бәлки, бик күп ялгыз карт-карчыклар кызыгыр иде: аны башкалада зур урыннарда эшләгән балалары үз яннарына алып китә, кадер-хөрмәт күрсәтә, тәрбияли. Яшьтәшләре аз калу карчыкның Җир йөзендә аз яшәмәвен күрсәтә. Үлеме артык үкенечле булырга тиеш тә түгел кебек...

Алайса нигә безне һәрвакыт сагыш хисе озата? «Йомшак кына җәйге җил исә... Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә. Ефәк чукларын еш-еш кына селкеп, акрын гына кыштырдап, бик тырышып һәм бик кабаланып йөгерә кебек алар...» — ди автор. Нәрсәгә өлгерергә тиеш соң бу кылганнар? Кем нәрсә өчен кабалана? Кем күңелен тасвирлый бу кылганнар хәрәкәте?

«Колын буйлап уйнаклап, шул кылганнар артыннан чабасы да чабасы килә», — дип дәвам итә автор. Әлеге юллар сабый чакларны, уенчак яшьлекне искә төшерә. Рәхәт әле...«Ьәй, рәхәт тә соң!» Шулай дип укысак та, шомлы яңалык көтү көчәя генә. Җитмәсә, шагыйрь хисләрнең үзара һич ошамаганнарын янәшә куя башлый: «Һәм ямансу...» Һәр хисне кабат ассызыклап, көчәйтеп бара Ә. Еники: «Нигәдер бик ямансу да шул!» Күңел сизгерлеге куркыта безне, ниндидер бер сәер халәттә тота.

«Шагыйрь әйтмешли, йөгереп уйныйсы, ятып елыйсы килә бу тын, буш, моңсу башкорт даласында!» Кеше, табигать, авыл, милләт фаҗигасенең авазларымы әлеге юллар?

Хиссилеге, эпик зурлыгы белән сирәк очрый торган талантлар гына иҗат итә алырлык күренеш икән башламда. Без башта — кемнеңдер, инде тора-бара Акъәбинең дала белән, гомере, балачагы, яшьлеге узган дала белән саубуллашуын чагылдырган пейзаж икәнлеген аңлыйбыз. Йөрәккә үтәрлек язылган башлам тулы бер әсәрнең төп аһәңнәрен билгели.

Ни өчен беренче абзацта тудырылган далага, аннан әбигә Миңлебай карт янәшә куела? Монысы да аңлашыла: аңа инде күп яшь, далага яшәгән гомер буенча аннан да якынрак торган кеше юк. Ул кайчандыр шушы

далада бүре суккан, кызлар белән дә очрашкандыр... Миңлебай карт кебек гаярь ирләр юк инде, кеше табигатьтән ерагая бара. Карт рухына машиналарга төялеп ауга чыккан ир-атлар якын түгел, ул да үз заманы кешеләре, үз чорының даласы, тормыш белән саубуллаша шикелле.

Кылганнар нихәтле генә йөгерсәләр дә, туган туфракларында басып калалар. Акъәби никадәр генә теләсә дә, ул кылганнарны куып тота алмас инде... Дала карчыгының шәһәрдә бәхет тапкан балалары туган туфрактан гына түгел, күкрәк сөтен имезгән әнкәләреннән дә ераклаша баралар. Аларны тормыш җилләре башка якларга йөгертә.

Юлкотлы авылының далаларында барган вакыйгалар хәзерге заман кешеләренең драмасын сөйли. Авыл, кайчандыр, юлларыгыз котлы булсын, дип теләп, үз балаларын, дала балаларын зур тормышка озаткан. Дала кылганнары алга да, артка да йөгерә. Юлкотлы сукмаклары берьяклы гына булып чыга...

«Әйтелмәгән васыять»тәге дала күренеше кешенең эчке драмасын, аның аша халык, милләт драмасын ачып бирүдә, шул драманың тирәнлеген күрсәтүдә искиткеч зур роль уйный. Ул вакытның мәңгелеге, безгә бирелгәненең бик кыскалыгы турында фәлсәфәне җиткерә.

## А. Гыйләҗев — драматург

А. Гыйләҗев — берничә дистә пьеса авторы. Алтмышынчы еллардан башлап иҗатының соңгы көннәренә кадәр ул бер-бер артлы әллә ничә җыентык чыгара, шулай да бу әле каләм иясенең драматургия өлкәсендәге юлы җиңел булган дигән сүз түгел. Әсәрләре тамашалылык юлыннан китмәгәнгә, символларга, сүзнең күпмәгънәлелегенә һәм асмәгънәлелеккә корылганга, фикерләре өстә ятмаганга, аларны теләсә кайсы труппа уңышлы рәвештә сәхнәләштерә алмаган.

Мин үзем А. Гыйләҗевнең кайбер пьесалары куелышлы булмаса да, укылышлы дип саныйм. Тормышның төрле якларын яктырткан әсәрләренең сәнгатьчә эшләнгәнлеге, әлбәттә, төрле дәрәҗәдә, шуңа да карамастан алар арасында укучы зәвыгына, бүгенгебез таләпләренә җавап бирерлекләре аз түгел.

А. Гыйләҗевнең прозасы юморга саран иде, драматургиясе хакында да шул ук фикерләрне әйтергә мөмкин. Болардан тыш, кайбер пьесаларының укучыга таныш уңышлы проза үрнәкләрен сәхнәләштерү аша язылганнарын да онытырга ярамый.

Драматург еш кына комедия жанрына да мөрәҗәгать итте. Тәнкыйть билгеләвенә караганда, аларны язу өчен, яңа материал таба алса да, образлары белән башка авторларны кабатламаса да, үзенең рухы, композициясе, юмор-сатира алымнары белән, алар, нигездә, традицион калыптагы әсәрләр иде. Комедияләренең татар драматургиясенә керткән өлеше шушы ук авторның драмалары керткән өлештән шактый калышты.

А. Гыйләҗев прозасы психологик кичерешләргә һәрвакыт бай булды. Драматургиясе дә шулай ук. Димәк, кире кагып булмаслык һәм жанрларга бәйсез иҗат стиле бар иде.

Драматург замандашлар арасыннан кызыклы характерлар тапты. Уңай геройларны алтмышынчы елларга хас схемачылыктан коткара алды. Инде җитмешенче елларга кергәч, зур иҗат тәҗрибәсе туплагач, аеруча үзәк геройларны тагын да тормышчанрак тасвирлады.

Авторның сәхнәдә куелган иң беренче пьесасы «Җиз кыңгырау» драмасы икән. Аның сюжет нигезен колхозга ярдәм итү һәм зыян салу юлында йөргән геройлар арасындагы конфликт тәшкил итә. Әлеге әсәрдән «торгынлык еллары»ның бик күп фикерләрен табарга мөмкин. Шунысын да әйтергә кирәк: проза әсәрләреннән аермалы буларак, драматургиядә А. Гыйләҗев чор идеологиясенә ныграк бирелде.

Җитмешенче елларда А. Гыйләҗевнең сәхнәдә зур уңыш белән барган пьесаларының берсе «Сары чәчәк ата көнбагыш» булгандыр. Тарихи драма жанры формасында иҗат ителгән әлеге әсәр революция һәм гражданнар сугышы елларын яктырта. Вакыйгалары 1918 елда Зөя һәм Паратск ярымутравында бара. Каршы як көчләр арасындагы конфликтның кискен куелышы, берьяклы хәл ителеше шул чорның эстетик һәм идеологик нормалары белән бәйле. Образларның калку булуы һәм нәкъ менә шул көчле дра-

матик конфликт тамашачыны аңа тарткандыр да инде.

Соңгы елларда А. Гыйләҗев «Өч аршын җир» повесте буенча шул ук исемдәге пьеса язган иде, ул да аңа зур уңышлар алып килде. Күмәкләштерү елларын бөтен катлаулылыгы белән тасвирлавы, шул чор күренешләренә гадел бәя бирүе белән аерылып торды ул әсәр.

А. Гыйләҗевның халык мәхәббәтен яулаган сәхнә әсәрләре болар белән генә чикләнми. Алар арасында «Әткәй җырлый да, елый да», «Әгәр бик сагынсаң», «Җан җылысы» кебек гыйбрәтле язмышларны үзәккә куйган, вөҗдан каршында җаваплылык мәсьәләләрен күтәргән пьесалар бар.

Драматург иҗат иткән әсәрләргә куелган атамаларның яңгырашы, аларның пьесага салынган идея эчтәлеген шактый тулы ачуы, кайчак киңәйтеп һәм үткенәйтеп җибәрүе сокландыра мине. Бу уңайдан әдипнең бер китабына И. Бәширова язган рецензия күңелгә килә. «Әсәргә баш кую җиңелме?» — дип атала ул. Чынлыкта да, күпләр өчен чишелмәстәй бу проблеманы А. Гыйләҗев бик җиңел хәл итә шикелле. Күпчелек очракта символик мәгънәле әлеге атамалар аның абстракт фикер йөртү сәләтен күрсәтеп тора. Мин, теләсә, Аяз Гыйләҗев шагыйрь дә булыр иде дип саныйм.

А. Гыйләҗевнең сәхнә мирасы — кеше күңеленең иң тирән катламнарына төшкән, кырыс чынбарлыкны заманына күрә шактый тормышчан тасвирлаган драматургия ул.

СОЧИНЕНИЕ ЯЗАРГА ӨЙРӘНӘБЕЗ

## Сочинение язу җиңелме?

Соңгы сүзне әнә шундый сорау белән башларга булдым. Җавабым: җиңел түгел, әлбәттә. Ни өчен? Сәбәбе безнең сөйләм телебез ярлылыгында, булган сүзлек байлыгыбыз белән әйтәсе килгән фикерне җиткерә белмәвебездә генә түгел, беренче чиратта, әдәби әсәрне анализлауның авырлыгында.

Тәнкыйть мәкаләләрендә дә, дәреслекләрдә дә нинди дә булса бер әсәргә тулы анализга очраганым юк. Бу мөмкин дә түгел кебек. Урын кыса, балаларның яшь үзенчәлекләре кабул итү мөмкинлеген чикли...

Ә бит хәтта кайчагында шактый күләмле махсус фәнни хезмәтләрдә дә аерым бер әдәби үрнәкне җентекле итеп, бер үзенчәлеген дә игътибардан төшереп калдырмыйча аңлатуга ирешмибез. Монысы да табигый кебек. Югыйсә, гасырлар дәвамында яшәгән, анализланган классик әдәбият турында һаман да яңа сүз әйтү мөмкинлеге калыр идемени?! Заман шартларына бәйсез рәвештә дә, Пушкин, Чехов, Тургеневлар прозасы, мәшһүр «Илиада», үзебезнең «Кыйссаи Йосыф» хакында да кешенекен кабатламаган фикерләрне гел язып торабыз. Һәм язачакбыз да!

Аерым бер әсәргә тулы анализ бирү үрнәген укучыга җиткерү минем үземне гомер буе алгысытып торды. Ә бит тел-стиль чараларының теләсә кайсы оясын файдаланган, образлар системасы катлаулылыгы, байлыгы белән аерылып торган тезмә һәм чәчмә төр мисаллары шактый. Шулар арасында иң кызыклысы — һичшиксез, әлеге дә баягы «Кыйссаи Йосыф».

Хәзерлек бүлегендә укучыларга теләсә кайсы билгеләмәне аңлатканда, мин нәкъ әлеге әсәргә таянам. Карагыз сез аның образлар системасын! Монда без кешеләр белән дә, дини-мифологик геройлар белән дә очрашабыз. Предмет образларның персонажлаштырылганы, персонажлаштырылмаганы бар. Космогоник образлар, безне чорнаган табигатьтән алынганнары, саннар... Об-

раз дәрәҗәсендә тудырылган хис-кичереш, күренешләр... Аларны үз эчендә төркемләргә, әсәрдә башкарган вазифаларын ачыкларга мөмкин.

«Кыйссаи Йосыф»та синонимнарга байлык! Башка лексик чараларның муллыгы! Шуларның ук сәбәбен күрсәтеп узарга була. Без сезнең белән поэма авторы кулланган чыганакларга барып чыгачакбыз.

Әсәргә куелган атама буенча гына да озаклап фикер алышырга мөмкин. Ни өчен «Йосыф - Зөләйха» дастаны «Зөләйха» кыйссасы дип аталмый? Шул соравыбызга җавап табып кына да, без үзәк геройга киләбез һәм сюжет сызыкларының берсенә өстенлек бирә алабыз.

Бигрәк тә дастанда кулланылган саннар буенча күзәтүләр кызыклы. Ни өчен Йосыф 360 күлмәк кия? Чөнки аның күлмәген көн саен алмаштырганнар. Ни өчен Йосыф әллә никадәр тел белә? Бу, билгеле, аерым бер региондагы телләр саны белән дә бәйле, әмма сәбәбе ерактарак: Алла атабыз Адәмне үк 70 телне белүче итеп яраткан. Шул өстенлеге өчен аны Иблис күрә алмаган. Без исә бу фактны укучыларда миллилек идеясен ныгытуда куллана алабыз. Телләр төрлелеген хәтта Бөек көч яклаган!

Әсәрнең актуальлеген ачуда да файдалы ул безгә. Телләрне белү, саклау кирәклеге, аларның үзара тигезлеге инде Бөек көч тарафыннан ук билгеләнгән икән дигән нәтиҗә чыгарып була.

Бу дастан безне төрлелектә, тышкы киемдә, эчке дөньяда, тирәлектә, үзара мөнәсәбәтләрдә, хисләрдә матурлык күрергә өйрәтә. Диалектика кануниятенә буйсынган яшәештә һәр нәрсәнең капма-каршысы да бар. Без әнә шуларны да ача алабыз.

«Кыйссаи Йосыф»тан тарихи фактларны аерып күрсәтергә була. Җәмгыять үсешенә, идарә итү сәясәтенә бәйле карашларны ачыкларга мөмкин. Шулай икән, бу әсәр төрле фәннәр арасына ниндидер күпер суза. Димәк, аны анализлау яссылыклары да бер генә түгел.

«Кыйссаи Йосыф»ның композициясе, анда шул заман традицияләренең чагылышы, үзенә генә хас үзенчәлекләр турында сүз йөртү аермачык кирәк. Кыскасы, шушы әсәрне анализлау мөмкинлекләрен күрсәтү

өчен генә дә, аерым бер китап язу сорала. Программада күрсәтелгән исемлек шактый зур, без моны һәр әсәргә карата башкара алмас идек. Әле бит, фәнни хезмәтнең үзен өйрәнү өчен дә шактый көч түгәргә кирәк булачак.

Шул ук вакытта әдәбият дәресләрендә теләсә кайсы әсәрне билгеле бер дәрәҗәдә һәрьяклы анализлап була. Аның кабул ителгән структурасы бар. Галимнәр күпчелек очракта эпик һәм драматик әсәрләрне тикшерүнең түбәндәге эзлеклелеген тәкъдим итәләр.

1. Әсәрнең язылу тарихы.
2. Жанры, күләм үзенчәлекләре.
3. Сурәтләнгән вакыйгалар.
4. Тематикасы.
5. Проблематикасы.
6. Образлар системасы.
7. Конфликт, төрләре.
8. Идея-эчтәлеге.
9. Әсәрнең композициясен өйрәнү.
10. Образлы сөйләм үзенчәлекләре.
11. Әсәр турында әдәби тәнкыйть, бәхәсләр.

Роман, повесть, хикәяне шул рәвешчә тикшергәннән соң, башта бер әдәби бөтен буларак бәялибез һәм кызыклырак якларын, яшеренебрәк торган үзенчәлекләрен табабыз. Бу безгә сочинение темасын ачыклау, сайланма анализны билгеләү өчен кирәк.

Аерым бер иҗат буенча теманы ачыклау өчен генә дә, иң элек аны гомуми күзаллау, аңа хас үзенчәлекләрне аз булса да тою мөһим. Әйтик, контрастлылык - сәнгать әсәрләренең төп һәм мәңгелек принципларыннан. Теләсә кайсы шагыйрь яисә язучы иҗатыннан аңа мисаллар китерергә мөмкин. Әмма социаль-иҗтимагый эчтәлекле әсәрләрдә ул тагын да активрак кулланышта.

Тукай шигърияте үз чорының проблемаларын кискен күтәрүе, калкуландыруы, иҗтимагый эчтәлеккә ия булуы белән мәгълүм. Шул ук вакытта Г. Тукай мәхәббәт лирикасында да, башка темаларга язганда да контраст күренешләр тудыру алымын башкаларга караганда да мулданрак куллана.

Әгәр без «Тукай иҗатында антонимнар», «Тукай шигырьләрендә антитеза алымы» яисә охшашрак мәгънәле

башка тема бирәбез икән, аны сайлавыбыз шагыйрь иҗаты белән билгеләнә.

Һәр әсәрдә, һәр темада контрастлылык принцибының үз функцияләре бар. Әйтик, Тукайның гашыйк мине, ир-ат һәм хатын-кыз мөнәсәбәтләренең, дөньяның катлаулылыгы ачысын кичергәнгә, ак һәм кара төсләр белән эш итә, яисә, сөйгәнен күкләргә күтәрер өчен, аны җир кызларына каршы куя. Шагыйрь кичерешләрне кискенләштерергә омтыла.

Тукай әдәби образ буларак тудырган хезмәт кешесенең яшәү шартлары аның хезмәтеннән үк лаексыз, паразитар файдаланган байларныкына каршы куела. Бу очракта инде шагыйрь бөтенләй башка детальләр белән эш итә, еш кына предметлы тасвир тудыра.

Әдәби әсәрне жанр, жанр формалары ягыннан анализлау мәктәп баласы өчен авыррак. Шулай да югары сыйныфларда аны да башкарып карарга, шул юл белән теоретик белемнәрне ныгытырга кирәк.

Контекстны өйрәнү — әдәби әсәр анализында иң мөһим эшләрнең берсе, шуңа да карамастан аңа беребезнең дә тиешле игътибар биргәне юк. Бигрәк тә борынгы мирасны, узган чор әдәбиятын өйрәнгәндә, һәр җөмләне нинди дә булса мәгълүмат эзләп, аерым бер фикерләргә илтерлек детальләр туплап укырга кирәк.

Контекстны өйрәнү шулай ук тема сайлауда ярдәмгә килә ала. Ул әдәбият һәм тел белеме ирешкәннәрне бергә, мөмкин кадәр тулырак файдаланырга мөмкинлек бирә.

Сочинение тар темаларга язылса да, теләсә кайсы әдәби анализ үзенең табигате белән үк бөтенлекне таләп итә. Бөтенлекне, әлбәттә, тар терминологик мәгънәдә аңлау хата булыр.

Әдәби анализ идеалда әсәрнең тирән укылышына китерергә тиеш. Шундый тикшерү вакытында гына без бөтенне өлешләргә бүләбез һәм кисәкләрне кабат ялгыйбыз. Болай эшләү тәртибе сәнгать үрнәгенең эчке бөтенлеген, закончалыклы бәйләнешләрен күрергә ярдәм итә.

Һәр жанр формасын анализлауның спецификасы бар. Әйтик, чынбарлык вакыйгалар чылбырында тудырылган эпосның күпланлылыгы безнең алдыбызда ана-

лизлауның зур мөмкинлекләрен тудыра. Андый очракларда автор карашларын, шул карашларны җиткерү алымнарын ачыклау аеруча мөһим. Бу юл белән без әсәрнең эчке мәгънәсен эзлибез. Күләмле эпик әсәрләрдә текстны өйрәнү, аңа һәрьяклы якын килү кызык та, авыр да.

Прозаны тикшерү өчен, без әдипкә хас стиль, иҗат методы турындагы алдан тупланган белемнәребезне дә эшкә җигәбез. Эпик әсәрләрдә язу алымнарын тотып алу җиңелрәк, алар күзгә ачыграк ташлана.

Һәр әдәби төр һәм жанрны тикшерүнең уртак яклары шактый күп. Әсәрнең язылу тарихын, тормыш материалын, аның сюжет һәм эчтәлек белән бәйләнешен, атама һәм эпиграфның мәгънәсен, үзәк фикерне чагылдыру дәрәҗәсен, образлар системасын, композиция алымнарын ачыклау да әнә шуларга керә ала.

Драма театр белән аерылгысыз бәйле, шунлыктан автор сәхнә сәнгате шартларына, мөмкинлекләренә, кагыйдәләренә бәйле. Пьесаларны өйрәнү вакытында персонажларны төркемләү эшен башкару бик уңышлы. Ул конфликтның асылын ачарга ярдәм итә. Өстә яткан үзенчәлекләргә генә таянмыйча, конфликт төрләрен күрсәтә белү безнең фәнни фикер йөртүгә шактый өлгергәнлегебезне дәлилли.

Драма әсәрендә хәрәкәтләрнең һәр төрен анализлау аеруча кирәк, чөнки ул әсәрнең пафосын күрсәтә, сюжет һәм композиция нигезе булып тора.

Балаларга драма әсәрендә кайбер сюжет элементларын табу авыр. Бигрәк экспозицияне. Инде геройларга бирелгән аңлатма һәм сәхнә бизәлешенең үк экспозицион белешмә булуын әйтеп бирсәгез иде.

Лирика эпостан да, драмадан да шактый нык аерыла. Анда шагыйрь, аның дөньяга субъектив карашлары, җәмгыятькә шәхси мөнәсәбәте, үз-үзенә бәяләмәсе тагын да ачыграк, калкурак чагыла. Тезмә әсәрне язучы объектив булу максатын куймый да, ул рухи кичерешләргә, күңел кичерешләрен бөтен тулылыгы белән җиткереп калырга омтыла.

Шигырьне анализлаганда, шагыйрьнең шәхесе, дөньяга карашлары безне аеруча кызыксындырырга тиеш.

Поэтик әсәрне тикшерү бигрәк тә авыр. Берьяктан,

артыгы белән социологик якын килүең бар. Икенче яктан, анализың үтә формаль булырга мөмкин.

Укучы шигъри фикерне еш кына тупасландырса, гадиләштерсә, галимнәр катлаулы фәнни нәтиҗәләр ясый, томанлы мәгънәле терминология куллана. Без, шагыйрьләр, үз әсәрләребезгә анализны укырга куркабыз да, чөнки ул чәчмәгә күчерелгән шигырь булып чыга.

Шигырь кабул итү өчен язылса да, анализлау, балаларны шул эшкә өйрәтү, тарту барыбер кирәк. Хис-кичерешләргә ярлы, поэтик сәнгать үзенчәлекләрен аңлаудан ерак торган кеше аны кабул да итә алмаска мөмкин ич әле!

Кыскасы, поэзияне анализлау — үзе бер сәнгать һәм шигырь язудан да авыррак.

Без шигърияткә кайсы ноктадан якын килергә тиеш соң? Минем карашымча, беренче чиратта, шагыйрьнең стиль үзенчәлекләрен ачарга омтылырга кирәк. Кечкенә күләмле әсәрләр турында бигрәк тә кыска, тулы, бөтен әйтү отышлы.

Аерым бер мирастан охшаш рухлы шигырьләрне бер ояга туплау кызык кына нәтиҗәләр ясауга этәргеч бирә. Иҗатны еллар аралыгында өйрәнү дә шагыйрь иҗатының һәм аның шәхес буларак эволюциясен ачарга ярдәм итә.

Шигъри сүзнең мәгънәви йөге бик зур. Зуррак контекст эчендә ул тагын да киңәя, яңа төсмерләр ала бара. Ритм, көй белән кушылып, шигырьнең һәр сүзе сергә төрелгәндәй була. Аны яисә аерым бер гыйбарәне строфадан аерып алдыңмы, ул без әле генә күргән матурлыкларын югалта да куя.

Шигъри әсәрләрне анализлаучы төрле ассоциацияләрне табарга, кайвакыт хәтта бер-ике сүз белән генә дә тудырылган бай картиналарны күзалларга тиеш.

Ни өчен бер үк шигырь төрле кешегә төрлечә тәэсир итә? Чөнки һәркемнең үз тормыш тәҗрибәсе бар. Хәтта син үзең дә бер үк әсәрне төрле вакытта төрлечә аңлыйсың, кабул итәсең. Димәк, шигырь — һәрвакыт шагыйрь һәм укучы арасында барган диалог ул.

Кәефеңә карап, кичерешләреңә бәйле рәвештә, аерым

бер вакыттагы тормыш вакыйгалары җирлегендә син шагыйрьне кабат-кабат ачасың. Кичә генә аңлашылмаган лирика бүген синең бөтен күңел дөньяңны айкарга мөмкин. Шуның нәкъ киресе дә була ала.

Шигъри анализ өчен укучыларга нинди темалар тәкъдим итәргә мөмкин? Безнеңчә, шигырьнең композициясен, образ-символларын, әйдәп баручы тел элементларын анализлау мәктәп балаларының көченнән килә.

Зур күләмле поэтик әсәрләрне анализлау күпкә җиңел. Вакыйгалылыкка нигезләнгән поэма, сюжетлы шигырьләрнең анализы проза әсәрләрен тикшерүгә тартым. Тәнкыйть хезмәтләрендә дә күбесенчә төп фикерне, темаларны аерып чыгару күзәтелә. Образлар системасын өйрәнү дә кулдан килмәслек эш түгел. Шулай да без җиңел юлдан гына китмәсәк һәм поэтик элементларны табуны, шәрехләүне күз уңыннан ычкындырмасак иде.

Сюжетлы әсәрләрне анализлау җиңелрәк булгангамы, татар әдәбияты тарихын чагылдырган хезмәтләрдә дә күләмле әсәрләргә зуррак игътибар бирелә. Кайчакта поэзия поэма жанры үсешенең тарихы кебегрәк тә күзаллана башлый. Ә бит кыска һәм оста әйтүнең авырлыгын һәр иҗатчы белә. Тел җәүһәрләребез бихисап шигырьләребезнең юлларына качкан.

Сочинениеләр язу буенча методик әсбапларда шигъри әсәрне анализлауның якынча түбәндәге схемасын бирәләр.

1. Язылу вакыты.
2. Социаль-тарихи һәм биографик комментарий.
3. Әсәрнең жанры.
4. Идея эчтәлеге.
5. Әйдәүче тема, төп фикер.
6. Эмоциональ яңгыраш һәм аның чаралары.
7. Шигырьнең структур өлешләре, композициясе.
8. Тел-сурәтләү чаралары: метафора, эпитет, аллегория, чагыштыру, метонимия, антитеза, гипербола, градация, сарказм, ирония, инверсия...
9. Ритмика һәм үлчәм: тоника, силлабика, силлаботоника, верлибр, ирекле шигырь, гаруз, бәет...
10. Рифма, аның төрләре.

Теләсә кайсы һөнәрнең үз техникасы була. Аңа әдәби анализ да ия. Әсәрне анализлауга керешкәнче, иң элек фәнни терминологияне белергә, әдәби текст белән эш итүнең элементар — аңа зыян салмый торган кагыйдәләренә өйрәнергә кирәк.

Шәхеснең эстетик эзләнүләре зуррак булган саен, әсәрне аңлавы да тирәнәя. Тәҗрибә күп китап уку, аларны тормыш белән чагыштыру, әйтелгән фикерләре турында уйлану нәтиҗәсендә килә.

Яшь укучының да тәҗрибәле мөгаллим янында үз өстенлеге бар. Аның кызыксынучан холкы игътибарын олы кеше бик күреп бетермәгән фактларга да юнәлтә. Ул язучыга күбрәк ышана, аның белән контактка җиңелрәк керә. Без исә еш кына, үз тәҗрибәбездән чыгып, башка кеше фикеренә шик белән дә карыйбыз.

## Сочинениенең төп төрләре

1. Сочинение-тасвир. Ул геройның портретын, холкын, күренешләрне ачкан язма эшләрдә кулланыла ала. Бу төр эш текстны игътибарлы укуны, аерым детальләрне, геройга, предметка хас үзенчәлекләрне туплауны таләп итә.

Әйтик, Г. Бәшировның «Намус» романы буенча укучыларга түбәндәге темаларны тәкъдим итәргә була:

«Әпипә образының бирелеше»;

«Намус» романында табигать күренешләренең идея-сәнгатьчә роле».

2. Сочинение-бәян. Нәрсә турында булса да хикәяләү укучының әсәрне эстетик кабул итү сәләтен үстерә. Укучының үз яшәеше буенча язылган кечкенә хикәячекләр дә бу төр сочинениеләргә карый. Әдәби әсәрнең эчтәлеген сөйләтү шулай ук хикәяләү күнекмәсе булып тора.

Сочинение-бәян өчен темалар:

«Идегәй» дастанында үзәк герой бантыннан кичкән хәлләр»;

«М. Хәсәновның «Язгы аҗаган» романында Иргалиның эчке инанулары».

3. Сочинение-хөкем (фикер йөртү).

Бу төр язма эшләр башкару бик киң таралган. Укучыга укыган әсәренә бәяләмә язарга кушарга була. Иҗатның, әсәрнең аерым үзенчәлекләрен ачу шулай ук әлеге төркем сочинениеләргә карый. Укытучы балалар алдына билгеле бер проблема куя һәм шуңа җавап табарга куша.

Әйтик, «М. Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»ндә тоткын рухының чагылышы», «Ә. Баянов прозасында шартлылык».

Проблеманы сорау рәвешендә дә куярга мөмкин. Тоталитар системаның милләткә, илгә китергән афәтен сурәтләгән әсәрләр буенча «Кеше һәрвакыт үз язмышының хуҗасымы?» дигән темага язма эш тәкъдим итәргә була.

Кайвакыт инде язма эшнең атамасында ук укучы бирәчәк җавап чагылыш таба ала:

«М. Әгъләмов — халыкчан шагыйрь»;

«Г. Ахуновның «Идел кызы» романы герое Габбас мулла — каршылыклы характер».

## Сочинениегә куелган кайбер таләпләр:

1. Темага туры килгәнлек.
2. Теманың тирән, дөрес ачылуы.
3. Фикернең дәлилләнүе.
4. Логик эзлеклелек.
5. Мөстәкыйль анализга сәләтлелек.
6. Фикернең үтемле җиткерелүе, тәэсирлелеге.
7. Эпиграф һәм цитаталарның урынлы, төгәл кулланылышы.
8. Грамматик-стилистик нормаларны белү, әдәби телдә фикер йөртү, сүзләрне урынлы, дөрес язу һ. б.

УКУЧЫЛАРЫБЫЗ, СӘҮДӘГӘРЛӘР ИГЪТИБАРЫНА!

«Юлдаш» газетасы каршындагы «Раннур» нәшриятында басылып чыккан «Һәр сыйныфта — сочинение. 5-11 **класслар** өчен сочинение үрнәкләре» (Язылу индексы — 01501) һәм «Татар телендә 100 сочинение» (Язылу индексы — 16276) китапларын почталар яки хат ташучылардан сатып ала аласыз. Әлеге китапларны күпләп сатып алырга теләүче сәүдәгәрләр, китап оешмалары, шәхси эшмәкәрләр түбәндәге адрес белән мөрәҗәгать итә алалар: Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт, 11 нче кат, 166 нчы бүлмә. **Телефон:** (8-8432) 43-70-91, **факс:** (8-8432) 43-25-62.

# Эчтәлек


АВТОРДАН ... 3

## Беренче бүлек

V сыйныф ... 7
ГҮЗӘЛ ГАМЬ ... 7
Безнең кенәри ... 7
Көнбагыш ... 7
Яраткан укытучым ... 8
Әбием ... 8
Пилмән ... 9
Мин чәчәкләр яратам ... 9
Якын дусларым ... 10
Габдулла Тукай һәйкәле янында ... 11
Туган ягым табигате ... 12
Мин шофер булырга телим! ... 12
Туган йортым бусагасы ... 13
Яз килде ... 13
ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ ... 14
Җиде — бәхет саны ... 14
Җиде кат үлчә, бер кат кис ... 14
Эш беткәч, уйнарга ярый ... 15
ӘДӘБИЯТ ... 15
Су анасы сабагы ... 15
Татар йорты ... 16
Кыр казы ... 17
Батырлыктан туган матурлык ... 18
Осталык — иң зур байлык ... 19
VI сыйныф ... 20
ГҮЗӘЛ ГАМЬ ... 20
Минем тормышымда матур әдәбият ... 20
«Китап укып елый алганнарның
Күңелендә булмый каралык» ... 21
«Кеше өчен иң әүвәле намус дигән...» ... 21
«Җир йөзе шундый киң, күңелле һәм якты» ... 22
Туган як ... 22
Туган авылым минем ... 23
ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ ... 24
«Сүз күңелдә очкын булып көйри,
Сүз арыслан итә йөрәкне» ... 24
Ай былбылым ... 25
«Күзге ачы җилләрдә»не укыгач ... 26
ӘДӘБИЯТ ... 26
Г. Камалның «Беренче театр» комедиясендә
Бибинең башкалар белән мөнәсәбәте ... 26
С. Рәмиев иҗатында авылга мәхәббәт ... 27
Татар әдәбиятында Тукай образы ... 28
Хәсән Туфан шигырьләрендә чор сулышы ... 29
Илсөяр миңа ни өчен ошады? ... 29

«Йолдыз кашка турында баллада»да конфликт 30
«Мәүлия нигә көлде?» әсәрен хикәяләүче 31
Өч Мәхмүт 32
«Наил һәм Фаил» повестенда хикәяләүче герой 32
Р. Миңнуллин шигырьләрендә лирик мин 33
Р. Миңнуллин шигырьләрендә юмор алымнары 33
Мин сезгә яраткан героем турында язарга телим 34
VII сыйныф 35
ГҮЗӘЛ ГАМЬ 35
«Җир шарын васыять итик балаларга!
Сакласыннар, олыларның ышанычын акласыннар!» 35
Мин сезгә яраткан шагыйрем турында сөйләргә телим 36
«Киләчәге бар милләт без,
Шәхесләргә бай милләт без» 37
Яшә, Казаным! 38
Мин сезгә үземнең яраткан әсәрем
турында язарга телим (I) 41
Мин сезгә үземнең яраткан әсәрем
турында язарга телим (II) 43
Мин сезгә үземнең яраткан
әсәрем турында язарга телим (III) 44
«Көйнең, телнең, гореф-гадәтләрнең
бар үз моңы, бар үз хисләре» 45
ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ 46
Сөембикә турында уйланулар 46
ӘДӘБИЯТ 48
«Каюм Насыйри үз халкының һәм
үз чорының улы булган» 48
Г. Тукайның «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш»
поэмасында Печән базары әһелләре 49
Дәрдмәнд лирикасында фәлсәфи уйланулар 50
Дәрдмәнднең «Видагъ» шигыренә салынган фәлсәфә 51
Гасырлар һәм минутлар 52
Татар әдәбиятында һәм сәнгатендә
Муса Җәлил образы 53
К. Насыйриның «Әбүгалисина»
кыйссасында фантастик элементлар 54
Фатих Хөснинең «Йөзек кашы» әсәрендә
Вәсиләнең тышкы портреты 56
Шулай үлде Ватан улы 57
«Сез — болгар бабалары,
Без — аның балалары» 58
Мин сезгә яраткан язучым турында сөйләргә телим 59
«Бер ананың биш улы» повестенда
эчкечелеккә китергән сәбәпләрне ачу 61
VIII сыйныф 62
ГҮЗӘЛ ГАМЬ 62
Сез «... кабызган утлар сүнми алар,
Сүнми алар хәтәр җилләрдә...» 62
Хаклык өчен көрәшчеләр сафында минем урыным 64
Халкымның күңел байлыгы 65

Бүгенге татар драматургиясендә замандашым 66
Нәкый Исәнбәт — фольклорчы 68
ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ 70
Тарихлардан килгән хакыйкать 70
«Идегәй» дастанында Туктамыш хан һәм Котлыкыя арасындагы вакыйгалар 71
ӘДӘБИЯТ 73
Фатих Кәриминең «Салих бабайның өйләнүе» хикәясендә табигать тасвиры 73
Ф. Кәриминең «Салих бабайның өйләнүе» әсәрендә үзәк геройга характеристика 75
һ. Такташның «Алсу» поэмасындагы төп фикер 76
А. Расихның «Дустым Мансур» әсәренә рецензия 78
М. Җәлилнең «Сандугач һәм Чишмә» әсәрендә яшәү мәгънәсе турында фикер 78

## Икенче бүлек

IX сыйныф 80
ГҮЗӘЛ ГАМЬ 80
«Киләчәге бар милләт без, Шәхесләргә бай милләт без» 80
Ил хәтере — вакыт күпере 81
Яңа гасыр башында милләтебезнең киләчәге турында уйлануларым 83
ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ 85
Мифлар — хыял тудырган дөнья 85
М. Кашгарыйның «Диван...»ында мәкальләр 87
ӘДӘБИЯТ 88
Алтын Урда чоры — татар әдәбиятының Яңарыш чоры 88
С. Сараи иҗатында чагылыш тапкан әхлакый-этик таләпләр җыелмасы 90
Утыз Имәни иҗатында гыйлем-мәгърифәт темасының чагылышы 92
Казан ханлыгы шигъриятендә суфичылык чагылышы 95
Татар поэзиясендә әхлак проблемасы 97
«Бичара кыз» һәм «Рәдде бичара кыз» пьесаларына чагыштырма анализ 100
«Бичара кыз» һәм «Рәдде бичара кыз» драмаларының жанр үзенчәлекләре 101
«Бичара кыз» һәм «Рәдде бичара кыз» драмаларын үзара чагыштыру 103
X сыйныф 105
ГҮЗӘЛ ГАМЬ 105
Яраткан әсәрем турында язарга телим 105
Г. Бәширов әсәрләрендә Туган як образы 107
ӘДӘБИЯТ 109
Әдәбият мәйданына алып килгән әсәр 109
Г. Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт...» әсәрендә уздырылган карашлар 111

Г. Исхакыйның беренче әсәрләрендә
яманлык белән яхшылык көрәше 114
Гаяз Исхакыйның башлангыч чор әсәрләрендә гыйффәтлелек
мәсьәләсе 117
Әдәби әсәрләрдә бетем турында уйлануларым 119
Г. Исхакыйның башлангыч чор әсәрләрендә бетем 121
Ф. Әмирханның «Яшьләр» пьесасында аталар һәм
балалар каршылыгы 123
Ф. Әмирханның «Яшьләр» пьесасында
халыкчылык мәсьәләсе 125
Ф. Әмирханның «Яшьләр» пьесасында
яңача яшәү идеалы 128
М. Гафури поэзиясе — «чорның күзе һәм колагы» 130
Рус шигъриятенең Г. Тукайга тәэсире 132
XI сыйныф 134
ГҮЗӘЛ ГАМЬ 134
Яңа әсәр укыгач 134
Ә. Гаффарның «Язлар моңы» драмасының
идея-тематик эчтәлеге 136
Бүгенге әдәбиятта милли проблемалар 138
Сәхнә әдәбиятыбыз турында уйлануларым 140
Бүгенге татар драматургиясе турында уйлануларым 142
«Остаз» 143
«Үлемнәре белән үлемсезлек яулап ала
безнең шагыйрьләр» (I) 145
«Үлемнәре белән үлемсезлек яулап ала
безнең шагыйрьләр» (II) 146
«Үлемнәре белән үлемсезлек яулап ала
безнең шагыйрьләр» (III) 148
ӘДӘБИЯТ 149
М. Җәлилнең «Юллар» шигыре 149
Г. Әпсәләмов иҗатында батырлык темасы 151
Кеше китә — җыры кала 153
Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр»ендә
реаль һәм шартлы образларның үзара мөнәсәбәте 154
Татар әдәбиятында җитәкче образы 157
«Дала буйлап кылганнар йөгерә...» 159
А. Гыйләҗев — драматург 161

## Өченче бүлек

Сочинение язарга өйрәнәбез 164
Сочинение язу җиңелме? 164
Сочиненниенең төп төрләре 171
Сочинениегә куелган кайбер таләпләр 172

**© «Раннур» нәшрияты, 2003**